ЯҢӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№12 (383)
ДЕКАБРЬ 2023

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

МАТУРЛЫК ҺӘМ МИЛЛИЛЕККӘ ЙӨЗ ТОТЫП

№12 (383)
ДЕКАБРЬ 2023

16+

Редакция:
420066, Россия, ТР,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

РЕДАКЦИЯДӘН

БЕРГӘ БУЛЫЙК!

Тагын бер ел узып бара. «Татарстан» журналы, кыйбласына тугры калып, быел да акыллы гамәлләр, игелекле эшләр һәм мәңгелек кыйммәтләрне барлауны дәвам итте. Басмабызда тормыштагы проблемалар, республикадагы төзелешләр, авыл хуҗалыгы, икътисад һәм социаль өлкәләрдәге уңышлар, ә иң мөһиме – әлеге күркәм эшләрне башкаручылар турында саллы язмаларыбыз дөнья күрде. Тел сөйләр дә ўтәр, каләм аны язып саклар, диләр. Журналистларыбыз укучыларны төбәгебездә яшәүче кызыклы, булдыклы кешеләр, күркәм гаиләләр, алар башкарган игелекле эшләр белән таныштырды.

«Татарстан» журналын быел үзе өчен яңадан ачкан укучыларыбыз саны да артты. Бу буш сүзләр генә түгел, бик күпләр басмабызны яратып укулары турында җылы сүзләрен ирештереп тора. Безнең өчен бу бик зур бәя дә, тагын да камилләшергә этәргеч тә.

Гыйлем – күңелнең зиннәте, ди халык. Гыйлемле, белемле, мәгълүматлы булыйк! Киләсе елда да журналыбыз битләрендә очрашырга язсын! Хәерле, имин ел килсен!

Сезнең ихлас теләкле редакциягез.

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов,
Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Олеся Бондаревская, Илдус Зәһидуллин,
Әхмәт Шакиров, Айдар Шәйхин, Луиза Янсуар
Фотографлар: Анна Арахамия, Александр Ефремов,
Нурислам Исмәгыйлев, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова, Игорь Глушков
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: «Сөембикә» салоннар челтәре җитәкчесе
Алина Хәмидуллина
Анна Арахамия **фотосы**

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Россия, ТР, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: С-3271
Басарга кул куелды: 14.12.2023
Чыгу көне: 20.12.2023

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
420097, Россия, ТР, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2024 елның яртыеллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1212 сум 00 тиен китерел бирешле,
1175 сум 40 тиен соратып алганда.
2024 елга ТР буенча язылу бәясе:
2423 сум 92 тиен китереп бирешле,
2350 сум 66 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

ТАТАРСТАННЫҢ 100 ҖӘҮҺӘРЕ

БАРЫ ТИК ТАТАРСТАНДА

СССР ЧОРЫНДАГЫ КАЗАНЫШЛАРЫБЫЗ

Беренче тапкыр Татарстан павильоны (ул вакытта ТАССР) Мәскәүдә 1939 елда Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә (БАХК) ачыла. «Татарстан АССР» павильоны Колхозлар мәйданыннан «Механизация» павильонына илтүче аллея буенча барганда, «Таҗикстан ССР» һәм «Кыргызстан ССР» павильоннары арасында урнашкан, – дип хәбәр итә ул вакыттагы БАХК юл күрсәткече. – Татар халкы төзелеш корылмаларына хас эчке ишегалды павильонның үзенчәлеге булып тора... Төп залга керү урыны милли орнаментлар һәм Ленин орденын сурәтләгән барельеф белән бизәлгән. Әлеге бүләккә ТАССР 1934 елда авыл хуҗалыгында ирешкән казанышлары өчен лаек булды». ТАССР павильоны күргәзмә аренасын ике дистә ел бизәп тора. Ләкин БАХК Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе (ХХКК) итеп үзгәртелгәннән соң сүтелә. Ул вакытта башкалада үз казанышларын күрсәтү хокукына союздаш республикалар һәм аерым тармаклар гына ия була.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Агробизнес парта артына утыра
Авыл өчен кадрларны ничек әзерлиләр

10. Яңа елда безне яңа юллар көтә
Татарстанда нинди магистральләр төзелде

22. Газлы кешеләр өчен «бер тәрәзә» хезмәте
Цифрлаштыру кулланучы тормышын ни рәвешле җиңеләйтәчәк

игелекле эшләр

26. Туган Батыр дөньясы
Яңа эпосның көче нәрсәдә

28. Безнең кунакханәдә
Илгиз Зәйниев белән гамьле әңгәмә

33. Каз өмәсе
Бәйрәм нинди үзгәрешләр кичергән

38. Портмаськон
Удмуртлар бәйрәмдәниләр эшли

40. Сурхури
Чуваш бәйрәменә ничек әзерләнергә

42. Шорыкйол
«Сарык аягы»ннан ниләр көтәргә

44. Могҗизаларга ышанырга ашыгыгыз
Яшь талантлар ничек кино дөньясын сайлый

58. Телеңне йотарлык!
Кытай пилмәннәренең тәме нәрсәдә

мәңгелек кыйммәтләр

64 Тарих битләре
Беренче татар марксист әдибе Гафур Коләхмәтов

72. Яшьләр вакыты
«Йолдызлы көн вакыйгасы»

76. Онытылмас исемнәр
Остазлар остазы

80. Татар авыллары
Җылы Күзкәй

86. Афиша
СССРда нинди курчаклар белән уйнаганнар

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: **protatarstan.ru**

Фото: 100tatarstan.100tatarstan.ru

Акыллы гамәлләр

14.11

Дмитрий Чернышенко, РФ вице-премьеры, – Казанда «Киләчәк уеннары»ның ачылышына 100 көн калуны бәйрәм итү тантанасыннан соң:

– «Уеннар»ның миссиясе – киберспорт һәм классик спортны берләштерү. Нәкъ менә шундый берләшүдә гармонияле яңа шәхес туа да. Чыннан да, киләчәкнең гармониягә ия кешеләре – яшьләребез. Бу бәйсез яңа халыкара хәрәкәт яшьләргә юнәлтелгән, ул бөтен дөнья буенча миллионлаган балага гаджет һәм электрон җайланмаларда гына түгел, ә уеннарда, чын спортта гармония табарга мөмкинлек бирәчәк.

14.11

Васил Шәйхразыев, ТР вице-премьеры, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура җитәкчесе, – Казанда узган Бөтенроссия туган тел форумында:

– Сез – милли хәрәкәт вәкилләре, сез – халкыбызның әйдәп баручы көче. Татар теле укытучылары – милләтне саклаучы һәм яклаучы була ала торган катлам. Яңа буынны, киләчәктә бу бурычны кабул итүчеләрне тәрбияләү – туган телгә мәхәббәт тәрбияләү ул.

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр



17.11

Алинә Заһитова, фигуралы шуу буенча Олимпия чемпионкасы, телевидениедә алып баручы, – үзенең шәхси кием коллекциясен күрсәткәннән соң биргән әңгәмәсендә:

– Кызганычка, хәзер битлек кигән, башкалар ролен уйнаучы һәм аннан соң газап чигүче кешеләр бик күп. Минемчә, иң яхшысы – һәрвакыт үзең булып калу һәм тормыштан ләззәт алу.

Фото: tatar-inform.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр/

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Цифрлы чор белгечләре агросәнәгать комплексын **ничек** үзгәртә

Россия картасында татар атамаларын **ничек** табарга

Әстерханда Татар урамы **ничек** пәйда булган

Ни өчен Ижевскиның Татарбазары бөтенләй базар түгел

Оренбург татарлары **кайсы** театрга йөри

Евразия белән Сахалин арасында татар эзе **каян** килгән

МАРАТ ҖӘББАРОВ: КӨНДӘШЛЕК ШУЛКАДӘР ЗУР: ГЕЛ УКЫРГА, ӨЙРӘНЕРГӘ КИРӘК

Әскәр Сабиров

Авыл хуҗалыгында цифрлаштыру кадрлар мәсьәләсенә ничек йогынты ясый? Цифрлы чор белгечләре агросәнәгать тармагына нинди үзгәрешләр кертә? Югары уку йортларын тәмамлаучыларны яңадан укытырга кирәкме? Фермер яңа технологияләргә кайда өйрәнергә тиеш? Авыл хуҗалыгында профессионаллар күпме хезмәт хакы ала?

Әлеге һәм башка сорауларга Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Азат улы Җәббаров җавап бирә.

КАДРЛАР ҺӘМ ЦИФРЛЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ТУРЫНДА

– Марат Азатович, агросәнәгать комплексы бик тиз үзгәрә, хәзер хәтта авылда да цифрлы технологияләр шаккатыра торган нәрсә түгел. Ә кадрлар мәсьәләсе ни хәлдә? Аларның осталык, белем дәрәҗәсе агросәнәгать тармагындагы бүгенге һәм киләчәктәге үзгәрешләргә туры киләме?

– Башта бер мисал китерим. Быел республикада бөртеклеләрнең тулаем җыемы буенча «Август-Агро» агрохолдингы беренче урынга чыкты – алар 320 мең тонна ашлык җыеп алды, гәрчә мәйданнар ягыннан иң зур

Фото: agro.tatarstan.ru, Марат Хафизов

компания булмаса да. Уңышның сере – актив рәвештә гамәлгә кертелә һәм кулланыла торган заманча технологияләрдә. Тәтешлеләр дә шул ук сәбәп нәтиҗәсендә уңдырышлылык буенча муниципаль берәмлекләр арасында алдынгылар рәтенә чыкты – районда технологик яктан алга киткән компанияләр күп. Ә заманча технологияләр, аңлавыгызча, хезмәткәрләрнең сыйфат ягыннан башка югарылыкта булуын күздә тота. Сезнең сорауга җавап та әнә шунда: яңалыклар кертү хезмәткәрләрнең квалификациясен арттыруны күздә тота, һәм ул эшләнә дә – башкача мөмкин түгел. Авылда кадрлар кытлыгы барыбер бар, анысы – икенче мәсьәлә. Өстәвенә, сүз югары квалификацияле белгечләр турында гына бармый. Эш шунда ки, аграр секторда яңа технологияләр бертигез кертелми – кайсыдыр хуҗалыклар тулысынча автоматлаштырылган, ә кайдадыр, ни кызганыч, әлегә кадәр кул хезмәтенә өстенлек бирелә...

– Татарстанда республиканың агросәнәгать комплексын цифрлы үзгәртү юнәлешендә уникаль программа гамәлгә ашырыла. Яңа шартларда эшләү өчен белгечләрне ничек әзерлиләр?

– Бюджеттан бүлеп бирелгән акча хисабына агропредприятиеләргә автоматлаштыруда ярдәм күрсәтүне күздә тоткан программа эшләнде һәм гамәлгә кертелә башлады. Аның беренче этабында җитәкчеләр «Агросәнәгать комплексын цифрлы трансформацияләү» курсында белем туплый. Предприятиене комплекслы автоматлаштыру проекты курсларның нәтиҗәсе булып тора. Әлеге проект, үз чиратында, тармакны компьютер программалары белән тәэмин итү планын, программа буенча эшләргә тиешле белгечләрне укытуны, предприятиегә консультация ярдәме күрсәтүне һ.б.ны үз эченә ала. Алга таба, икенче этапта, авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре югарыда телгә алынган программаларны турыдан-туры гамәлгә кертергә тиеш, бу исә, әлбәттә, махсус курсларда әзерлек үтүне күздә тота.

НӘТИҖӘЛЕ БЕЛЕМНӘР ТУРЫНДА

– Цифрлы үзгәреш буенча уку-укыту программаларына ихтыяҗ зурмы һәм белем бирү нәтиҗәләре нинди?

– 2022 елда 138 предприятиедән 276 белгеч белем алды. Комплекслы автоматлаштыруны, финанс ярдәме белән, бары тик 30 предприятие генә кертте. Проект бәясенең яртысына якынын алар үзләре түләде, ә калган сумманы министрлык бүлеп бирде. Быел программа буенча 106 предприятиедән 212 белгеч укыды. Нәтиҗәдә аларның 33е, гомумән алганда, 247 млн сум сарыф итеп, комплекслы автоматлаштыру эшенә керешә, әлеге акчаларның 109 млн сумы – предприятиеләрнең үзләренеке, 138 млн сумы – «Республика мәгълүмат-хисап үзәге» АҖнең үз һәм кредит акчалары.

Агросәнәгать комплексын цифрлы үзгәртү курсы дәресләре, кагыйдә буларак, тренинглар формасында уздырыла – тыңлаучылар конкрет

предприятиеләр үрнәгендә цифрлы технологияләр куллану ысулларын өйрәнә. Мондый методика кирәкле белемнәрне җиңелрәк үзләштерергә ярдәм итә.

– Агросәнәгать комплексын цифрлы үзгәртү өчен кадрлар әзерләү программасының нәтиҗәләре бармы?

– Һичшиксез. Без моны комплекслы автоматлаштыруны инде гамәлгә кerткән хуҗалыклар мисалында яхшы күрәбез. Аларда мал көтүе, терлекләрне ашату процессы белән идарә итү, сыерларның сәламәтлеген һәм үгез соравын контрольдә тоту системалары кулланыла. Мәсәлән, Балтач муниципаль районының «Дуслык» хуҗалыгында заманча технологияләр, шул исәптән цифрлы идарә программалары кертү бу елның 8 аенда сөт җитештерү күләмен, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 337 тоннага арттырырга мөмкинлек бирде.

– Авылда цифрлаштыруның төп максаты – агросәнәгать комплексында җитештерүчәнлекне җитди үстерү. Нәтиҗәдә кадрларның бер өлеше эшсез калмасмы? Алар белән нишләргә?

– Әйткәнемчә, аграр секторда кадрларга кытлык күзәтелә. Димәк, авыл хезмәтчәннәренә эшсезлек янамый, хәтта ерак киләчәктә дә. Әмма һәр үзгәреш яңа белем һәм күнекмәләр таләп итә. Белгечләр яңадан укырга һәм квалификацияләрен күтәрергә туры киләчәгенә әзер булырга тиеш. Дөресен әйткәндә, аграр секторда да икътисадның башка тармакларына хас тенденцияләр күзәтелә, без монда Америка ачмыйбыз. Өстәп әйтәм, яңа технологияләр – башкаручыларның гына үзгәрүен түгел, яңача идарә итүне, заманча фикерләүне дә таләп итә. Югарылыкка күтәрелү һәм шул биеклектә калу үз белемнәреңне даими камилләштереп торганда гына мөмкин хәл. Югыйсә куып җитә алмаслык артта калачаксың.

ДИПЛОМЛЫ ҺӨНӘРМӘНДЛӘРНЕ НИЧЕК ӘЗЕРЛӘРГӘ

– Ә югары уку йортларында авыл хуҗалыгы өчен кадрлар әзерләү сыйфаты агропредприятиеләрнең реаль ихтыяҗларына никадәр туры килә? Вуз тәмамлаучыларга яңадан укырга туры килмиме?

– Белгечләргә, хәтта иң квалификациялеләренә дә, үсәргә урын бар, яңа эшкә килгән инженер, зоотехник, ветеринарлар турында әйтәсе дә юк. Ләкин бер нәрсәне ышанып әйтә алам: Казан аграр университеты да, Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе дә кирәкле белемнәре һәм күнекмәләре булган кадрлар әзерли, шуңа күрә аларга ихтыяҗ һәрчак югары. Бу югары уку йортларында белем бирү чын мәгънәсендә гамәли юнәлештә алып барыла. Аерым алганда, ветеринария академиясе һәм аграр университет студентлары, өченче курстан башлап, безнең алдынгы предприятиеләрдә практика уза.

Әлеге схеманы без югары уку йортлары һәм авыл хуҗалыгы белгечләре белән берлектә эшләдек. Егетләр һәм кызлар теорияне үзләштерә, ә аннары практика вакытында, тармакта барган үзгәрешләрне исәпкә алып, алдынгы хуҗалыкта җитештерү процессларын өйрәнә. Ә аграр университетның үз агробиотехнопаркы да бар. Биредә студентлар, икътисадның реаль секторында эшләп, үз осталыкларын һәм белемнәрен практикада сынап карый ала. Өстәвенә, студентлар чәчү һәм урып-җыю эшләрендә актив катнаша – моның өчен күпләр трактор һәм комбайн йөртергә махсус өйрәнә.

Нәтиҗәләр күзгә күренеп тора: яшь белгечләр студент чагында практика узган предприя-

тиеләренә елдан-ел күбрәк кайта. «Август-Агро» агрохолдингы, мәсәлән, шул рәвешле егерме яшь белгечне үзенә эшкә алды, «Азык-төлек программасы» агросәнәгать компаниясенә дә дипломлы яшьләр килде, эре фермер хуҗалыкларына да кайталар. Әлбәттә, югары уку йорты белән килешү нигезендә үз студентларын максатчан рәвештә түләп укыта торган предприятиеләр дә бар.

– Татарстанда авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре өчен даими рәвештә зона семинар-киңәшмәләре, «Кыр көннәре» уздырыла. Аралашуның мондый формалары да үзенә күрә уку-укыту булып торамы?

– Теләсә нинди аралашу, үз эшенең профессионаллары белән тәҗрибә уртаклашу – үйлану өчен бер нигез ул, үз мөмкинлекләреңне бәяләү һәм практикада кулланырга мөмкин булган яңа белемнәр дигән сүз. Ә шул ук «Кыр көннәре»ндә үз тармакларының чын алдынгыларын һәрвакыт очратырга мөмкин, алардан өйрәнерлек, үрнәк алырлык нәрсәләр булганына шик юк. Ул гына да түгел, мондый форумнарны алдынгы технология казанышларын күрсәтү, шунда ук сатып алу мөмкинлеге тудырылган заманча техника күргәзмәсе дип тә карарга кирәк. Бер мисал китерәм. Быел Татарстанда узган «Бөтенроссия кыр көне» мәйданчыгына үсемлекчелек, терлекчелек, эшкәртү, фән, технологияләр, банк секторы һәм авыл хуҗалыгы машиналары төзү тармагының абруйлы компанияләре җыелган иде. 235 компания 300 берәмлектән артык авыл хуҗалыгы техникасы һәм илебез селекционерлары чыгарган 250 дән артык сорт үсемлек тәкъдим итте. Авыл хуҗалыгы тармагына кагылышлы казанышлар белән Россиянең 57 төбәгеннән, шулай ук Беларусь, Иран, Казахстан, Кыргызстаннан 80 мең кеше таныша алды. Бай эчтәлекле, эшлекле программа профессиональ элемтәләрне, аралашуны яхшыртырга, якынайтырга ярдәм итте, бу вакытта тармакны үстерүнең төп казанышлары һәм юнәлешләре турында сүз барды.

Һичшиксез, үзәк вакыйга илебезнең авыл хуҗалыгы министры Дмитрий Патрушев рәислегендә узган пленар утырыш, шулай ук Россия Федерациясе Дәүләт Советының «Авыл хуҗалыгы» юнәлеше буенча комиссиясе утырышы булды.

ФЕРМЕРЛАР МӘКТӘБЕ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ХАКЫ ТУРЫНДА

– Эре агрохолдинглар өчен кадрлар әзерләү – шактый оешкан процесс. Ә фермерларга, кече хуҗалыкларга нишләргә? Монда профессиональ үсеш өчен мөмкинлекләр бармы?

– Бүген аграр секторда көндәшлек шулкадәр югары ки, кече фермер хуҗалыклары өчен һөнәри үсеш зур ихтыяҗга әверелә. Укымыйлар икән, аяк сузачаклар. Әлбәттә, без фермерларга кирәкле ярдәмне күрсәтәбез. Республикада «Фермер мәктәбе» эшли – Россельхозбанк, Татарстан Авыл хуҗалыгы министрлыгы, югары уку йортлары, эре бизнес һәм фермерларның Россиядә беренче уртак уку-укыту проекты. Әлеге мәктәптә белем туплаучылар фермер хуҗалыгын алып баруның алдынгы ысул-алымнарын үзләштерәләр, финанс-икътисад өлкәсендә белемнәрен арттыралар, өр-яңа агротехнологияләр белән танышалар, республикадагы һәм Россия Федерациясенең башка төбәкләрендәге алдынгы агросәнәгать комплексы предприятиеләрендә һәм фермер хуҗалыкларында практика узалар. Ә югары уку йорты яки көллият тәмамлап, крестьян-фермер хуҗалыкларында эшләргә теләүчеләр, әлбәттә, республикада каралган барлык ярдәм чараларына өмет итә ала. Югары уку йортларын тәмамлаучылар өчен – 300 мең сум, көллиятне тәмамлаучылар өчен 150 мең сум ярдәм турында сүз бара. Ел дәвамында хезмәт хакына ай саен 7,5 мең сум да өстәлә.

Крестьян-фермер хуҗалыклары аграр юнәлешле югары уку йортларында һәм ветеринария вузында максатчан укыту программасы кысаларында да үзләре өчен белгечләр әзерләү мөмкинлегенә ия. Сүз уңаеннан, фермер хуҗалыклары, шулай ук агросәнәгать комплексының эре предприятиеләре цифрлы трансформация мәсьәләсендә «Республика мәгълүмат-хисап үзәге» АҖ белән хезмәттәшлек итә.

– Бәлки, күпләр өчен төп сораудыр: авыл хуҗалыгы кадрларының квалификациясен күтәрү, аларның һөнәри үсеше хезмәт хакларында чагыламы?

– Бүген аграр секторның иң кирәкле һәм төпле белемгә ия белгечләре аена 150 мең сумга кадәр акча ала. Болар – ветеринарлар, агрономнар, зоотехниклар. Автоматлаштыру дәрәҗәсе югары булган һәм хезмәткәрләре цифрлы технологияләр белән дуслашкан эре агрохолдингларда хезмәт хакы 60 мең сумнан артып китә, бу тармактагы уртача хезмәт хакының, тугыз ай нәтиҗәләре буенча, 43 мең сум тәшкил иткәнен дә исәпкә алыгыз. Шулай булгач, нәтиҗәне үзегез ясагыз.

«ЭССЕН ПРОДАКШН АГ»: ЮБИЛЕЙ ЕЛЫ – ЯҢА УҢЫШЛАР ЕЛЫ

25 еллыгын бәйрәм иткән компания ирешелгәннәр белән канәгатьләнеп туктап калырга җыенмый.

«Махеевъ» Россиянең иң атаклы, танылган азык-төлек брендларыннан берсе. Бу брендны инде чирек гасыр дәвамында Алабугада үстерәләр – сентябрьдә компаниянең 25 еллык юбилеен билгеләп үттеләр. Экспорт ассортименты һәм географиясе даими киңәя, үсә, җитештерү күләме арта. Предприятиенең алыштыргысыз генераль директоры Леонид Барышев «Махеевъ»ны киң таралган ретробренд дип саный. Бу майонез һәм кетчупларны кулланган тулы бер буын үсеп җиткән. Тора-бара предприятие Россиядә табигый җиләк-җимешләрдән джем җитештерүче иң эре компанияләрнең берсенә әйләнә. Инде 11 ел Чаллыда «Эссен Продакшн АГ» компаниясенең кондитерлык проекты – ESSEN фабрикасы эшли. 2023 ел да компания өчен уңышлы үтте дип, теркәп куярга мөмкин. Үсеш дәвам итә, алда – яңа үрләр. Безнең язмада – компаниянең ел йомгакларына кыскача күзәтү.

КОМПАНИЯНЕҢ 25 ЕЛЛЫГЫ ҺӘМ ЮГАРЫ БҮЛӘКЛӘР

Сентябрьдә «Эссен Продакшн АГ» АҖ «Махеевъ» брендының 25 еллык юбилеен билгеләп үтте. Компания зур бәйрәм оештырды, анда бөтен Алабуга күңел ачты, ә тантаналар 80 мең тамашачы өчен искиткеч зур концерт белән тәмамланды. Бәйрәмнең хедлайнерлары буларак Баста һәм Полина Гагарина чыгыш ясады.

Компания, үзенең җитештерү тармагы хезмәткәрләрен котлап, хезмәт хакын 25 %ка арттырды. Бәйрәм көнендә холдингка 70 тән артык бүләк һәм рәхмәт хаты килде: республиканың азык-төлек сәнәгатен үстерүдә казанышлары өчен Татарстан Рәисеннән Рәхмәт хаты, ТР Дәүләт Советы Рәисе, РФ Дәүләт Думасы депутатлары, төрле төбәкләрдәге һәм федераль дәрәҗәдәге министрлардан һәм башка бик күпләрдән рәхмәт хатлары.

Компаниянең кайбер җитәкчеләре һәм белгечләре дәүләт һәм ведомство бүләкләренә лаек булды. Генераль директор, ТР Дәүләт Советы депутаты Леонид Барышевка «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены тапшырылды. Бу, сүз уңаеннан, аның гомер бәйрәме – 50 яшенә дә матур бүләк булды. Аның җитештерү буенча урынбасары Роман Есауловка «Татарстан Республикасының атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде. Генераль директорның тагын бер урынбасары – Илшат Шәйморатов Алабуганың мактаулы гражданы исемен алды. Компаниянең 14 хезмәткәренә Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының рәхмәт хатлары тапшырылды, предприятиенең 10 хезмәткәрен күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Алабуга муниципаль районы башлыгы Рөстәм Нуриев бүләкләде.

Фотолар «Эссен Продакшн АГ» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

КОНКУРСЛАРДА ҖИҢҮЛӘР

Компания продуктлары да гадәттәгечә дәрәҗәле бүләкләр һәм премияләр яулый: 25 ел эчендә кулланучылар «Махеевъ» майонез, кетчуп һәм джемнарын яратып өлгерде. ESSEN кондитер фабрикасы да калышмый, яшь булуы аңа халык мәхәббәте хит-парадында күп юнәлешләр буенча алдынгылар сафында барырга комачауламый. Бу «йолдызлар яңгыры» 2023 елда да дәвам итте.

Мәсәлән, 2023 елда «Россиялеләрнең яраткан брендлары» рейтингында «Махеевъ» бренды «майонезлар» категориясендә зур өстенлек белән җиңүче дип танылды. OMI компаниясе сораштырулары күрсәткәнчә, бу брендка россиялеләрнең 25,9 %ы өстенлек бирә. «Кетчуплар» категориясендә «Махеевъ» җанатарлары 28,3 % тәшкил итә, бу бәйгедә ул икенче урында баруын дәвам итә.

«Россиядә 1 нче марка – 2023» конкурсында компания «Кетчуплар һәм соуслар» белән «Джемнар, повидлолар» номинацияләрендә берсүзсез җиңүче дип табылды. Сүз Россиядәге бик күптән үткәрелеп килә торган конкурсларның берсе турында бара. Аның 1998 ел – «Махеевъ» бренды белән бер үк елда нигезләнгән булуы да символик мәгънәгә ия.

«Эссен Продакшн АГ» АҖнең кондитерлык брендлары да калышмый. «ДаЁжъ!» батончиклары һәм «Cho Ко-Те» шоколад продукциясе «Тинейджерлар сайлап алган һәм ышаныч белдергән» һәм «Шоколад» категориясендә әниләр ышаныч белдергән, илебездә җитештерелгән» номинацияләрендә «Ел товары – 2023» илкүләм премиясен яулады.

ESSEN кондитер фабрикасы даими рәвештә бу абруйлы премиянең «чемпионнар»ын җитештереп тора: «ДаЁжъ!» үз категориясендә менә инде дүртенче ел рәттән – 2020 елдан башлап әлеге премиянең алдынгысы булып таныла. «Cho Ко-Те» шоколад бренды беренче тапкыр 2021 елда лауреат булды һәм йолдызлы бүләкне хәзер өченче тапкыр алды.

ЯҢА ПРОДУКТЛАР ҺӘМ ЯҢА ИДЕЯЛӘР

Яңа продуктлар эшләү дәвам итә. Мәсәлән, 2023 елда базарга «Шикәрдә изелгән җиләк» категориясендә ике яңа татлы ризык: әфлисун катыш шикәрдә изелгән лимон, шикәрдә изелгән карамилә һәм лимон чыкты. Аларны кулланучылар бик тиз үз итте. Һәм бу гаҗәп тә түгел: витаминлы дару төймәләренә караганда, авитаминозны уңайлы савытка салынган табигый җиләк-җимешләр белән җиңү күпкә рәхәтрәк!

Һәрвакыттагыча, ESSEN кондитерлык фабрикасы яңа тәм-томнар белән сөендерә. Бер ел эчендә аның товар ассортиментында «Фрутченье» (абрикослы эчлек тутырылган, кетердәп торган «чикләвекләр»), помадка эчлекле, глазурьланган «Ажур» һәм «Дороти» конфетлары, үзе юка булса да, эчлек салынган «Шоколашки» шоколад плиткалары, «Белый мишка» сөтле конфеты һәм башка тәм-томнар барлыкка килде, аларның һәрберсе базарда хит ашамлык булырга мөмкин. «Cho Ко-Те» шоколад таякчыклары линейкасы үзенчәлекле яңа тәмнәр белән тулыланды: «Шартлавык карамельле маршмеллоу» һәм «Банан белән бакча җиләге». Ә россиялеләр яратып өлгергән «35» батончикларын хәзер кранчлар һәм тозлы карамель белән татып карарга мөмкин.

Соуслар һәм кондитер ашамлыклар җитештерү технологлары яңа идеяләр уйлап чыгарудан, эзләнүдән бер көнгә дә туктамый һәм таләпчән, зәвыклы кулланучыны һәрвакыт сөендереп тора!

МАВЫКТЫРГЫЧ СӘЯХӘТ ӘЛЕ БАШЛАНА ГЫНА

Ноябрьдә Леонид Барышевка 50 яшь тулды. Компаниягә ул 25 ел элек нигез сала һәм бөтен гомерен диярлек аны үстерүгә багышлый. Бер ел элек, бу зур чорга йомгак ясаганда, Леонид Анатольевич мөһим нәрсәләргә басым ясады:

– Икътисадта коронавирус аркасында зилзиләләр кубып, мәгълүм вакыйгалар башлангач, сатып алучы мондый вазгыятьтә үзен ничек тотар дип, барыбыз да бик борчылдык. Әмма базардагы урыныбызның һичнигә дә карамастан саклануы һәм безнең товарларны куллану дәрәҗәсе тотрыклы калуы ачыкланды, димәк, сәүдә маркасы буларак «Махеевъ» үз кулланучысын тапкан. Без үзебезне инде танылган бренд, ретробренд дип санныйбыз – сатып алучыны яулау өчен, безгә аны яңа нәрсәләр белән шаккатырырга кирәкми. Безнең продуктлар тотрыклы кулланыла торган товарның бер өлешенә әверелде. Кулланучыларның тулы бер буыны «Махеевъ» сәүдә маркасын белеп үсте. Бу бик кадерле нәрсә! Брендыбызның базарда дәрәҗәсе булуы бәхәссез. Безнең казанышның әһәмияте нәкъ менә шунда.

Инде барысына да ирешелгән кебек. Тик алай түгел икән шул. Җитәкченең күзе 25 ел электәге кебек янып тора. Тышкы шартлар фәлсәфә сатып утырырга ирек бирми. «Эссен Продакшн АГ» АҖ коронавирус пандемиясе вакытында икътисадның параличын да, 2022 елның февраленнән соң яңа рельсларга күчүне дә уңышлы җиңеп чыкты. Компания алга барудан туктамый.

Күрәсең, яңа сынаулар Леонид Барышевка дәрт кенә өстидер. Тышкы кризисларны уңышлы кичеп барган хәлдә, Татарстан Дәүләт Советында депутат вазыйфаларын да башкаруын дәвам итә. Ул көн кадагындагы проблемалар турында турысын әйтеп, кыю чыгышлар ясый. Аның һәм компаниясенең энтузиазмына, үҗәтлегенә, амбицияләренә караганда, яңа үрләргә мавыктыргыч сәяхәт әле башлана гына!

ЯҢА ЮЛЛАР

2023 ЕЛДА ТАТАРСТАНДА НИНДИ

«Куркынычсыз сыйфатлы юллар» илкүләм проекты буенча

Татарстанда **133** объектта эшләр төгәлләнгән

Реконструкциядән соң **31** күпердә хәрәкәт ачылды

Вознесение тракты.
Беренче этап

Казанда Гвардия урамыннан Җиңү проспектына кадәр сузылган яңа юл иң тыгыз участоктагы трафикны җиңеләйтергә тиеш.

Горький шоссесына дублер юл.
Беренче этап

Озынлыгы алты километрдан артык булган дүрт полосалы магистраль Несмелов урамыннан Аракчинодагы Барлык диннәр гыйбадәтханәсенә кадәр сузыла.

Назарбаев урамындагы күпер

ТР башкаласындагы Түбән Кабан күле ермагы аша салынган. Тирәнтен реконструкция уздырылган, асылда бу – яңа кичү. Юл өслеге 8 полосага җиткерелгән, җәяүлеләр йөри торган өлеше иркенрәк, велосипедчылар өчен сукмак ясалган.

ВАКЫТЫ

МАГИСТРАЛЬЛӘР ҺӘМ КҮПЕРЛӘР АЧЫЛДЫ

«Мәскәү – Түбән Новгород – Казан» «Көнчыгыш» М-12

Татарстан участогы – 143 км лы зур тизлекле яңа магистраль. Шул исәптән Идел аркылы күпер – М-12 трассасында иң озын ясалма корылма.

Дымка елгасы аша күпер

ТР Ютазы районы «Урыссу – Октябрьск – Әбсәләм – Уба» автомобиль юлында Әбсәләм авылы янында салынды. Кичү Ютазы районын «Урал» федераль трассасы һәм Башкортстан белән бәйли.

Зөя аша күпер

Яшел Үзән районында М-7 трассасы аша салынды. Реконструкциядән соң ул 100 тонналы күтәрергә сәләтле.

Гамәлгә ашыру стадиясендәге проектлар

- Казанда Горький шоссесын реконструкцияләү
- Кама аша күпере дә булган Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узу юлын төзү. Әлеге участок «Көнчыгыш» М-12 магистраленең Екатеринбургка кадәрге өлеше булырга тиеш
- Киләчәктә Шәле (М-7) – Баулы (М-5) түләүле магистраленең бер өлеше булырга тиешле 145 километрлы Алексеевск – Әлмәт юлын төзү

* Ачылышы декабрь ахырына планлаштырылган

ТАТАРСТАН ҮЗЕ. МӘГЪРИПТӘН МӘШРИКЪКА КАДӘР

Иксез-чиксез ватаныбызның кала-салалары буйлап сәяхәт иткәндә, «Татарстан» кайчак ниндидер җылылык бөркелгән, үзебезнекен, туган ягыбызны хәтерләткән нәрсәләргә тап була, ул атамалар, истәлекле урыннар, йортлар, алардагы бизәкләр булырга мөмкин. Бүген без сезгә шулар турында сөйләрбез. Һәм, әлбәттә, сүзебезне илебез башкаласы Мәскәүдән башлыйбыз...

Автор фотосы

МӘСКӘҮ. ТАТАРСТАН ЧЫРШЫСЫ

Дмитрий Сивков

Казан вокзалыннан туп-туры ВДНХга юл тотабыз. Монда ноябрь аенда «Россия» күргәзмә-форумына старт бирелде. Ул 2024 елның 12 апреленә кадәр дәвам итәчәк. Биредәге 89 төбәкнең һәрберсе көн саен үз гореф-гадәтләрен, традицияләрен күрсәтә.

2 декабрь Татарстан көне иде. Кунаклар чын татар туенда булдылар, милли ризыклар белән сыйландылар һәм Татарстан чыршысын күреп хәйран калдылар. Хәбәрчебез Дмитрий Сивков та, шунда булып, туйда сыйланып, чыршыны фотога төшереп, сезнең хозурыгызга шул мизгелләрне тәкъдим итә.

ВДНХдагы Татарстан чыршысы кулдан эшләнгән курчаклар һәм керамика белән бизәлгән. Бу безнең чыршының үзенчәлеге. «Россия чыршылары» проекты кысаларында ВДНХда утыртылган 90 зәңгәр чыршының 89ы – РФ төбәкләренеке, ә берсе – илнеке. Агачларны Мәскәү өлкәсендәге питомниктан алып кайтканнар. Яхшылап үсеп китсеннәр өчен, яңа урынга сак кына күчереп утыртканнар. Димәк, алар, еллар дәвамында күргәзмәне бизәп, халыклар һәм төбәкләрнең бердәмлеген хәтерләтеп торачак.

Татарстан чыршысы төп керү урыныннан сул якта, беренче рәттә урнашкан. Киеменә «Россия чыршылары» дип язылган кыз чыршы ботакларына кунган карларны төшерә.

– Кичә кар күп яуган иде, тыныч кына үтеп китә алмыйм, мондый матурлык күренсен өчен, чыршы ботакларын бераз селеккәләдем, кары төшсен, – ди проект декораторы Алена. – Курчакларыгыз бик ошады. Һәм, күрәм, башкалар да сокланып карый. Гомумән, төп бизәү әйберләрен төбәкләр үзләре бирде, һәркайсы үз фишкасын җибәрергә тырышкан. Курчакларыгыз искиткеч, керамикагыз да бик матур.

Мәскәүлеләр һәм башкала кунакларын сокландырган чыршы уенчыкларының авторлары кем соң? Осталарның берсе – «Ел һөнәрчесе – 2023» титулы иясе Гүзәл Шакирова белән дә таныштык.

– Мин «Болгарлар мирасы», «Татар лаләсе» серияләренә кергән тәлинкәләр бизәдем, – дип сөйләп китте Гүзәл. – Бәхет кошын ясадым. Бу җыелма образ, нигезенә «Алтын кош» татар халык әкияте салынган. Аны ясаганда, ике юнәлешне берләштерергә тырыштым: бәхеткә омтылышны һәм кош образын. Чөнки максатка омтылганда, безнең дә канатларыбыз үсә бит. Татар фольклорында, сүз уңаеннан, кош җиңел генә кешегә әйләнә, кеше үзе дә бик еш кына кошка әверелә. Минем «Алтын кош»ым – керамикадан, ул туганда ук, Феникс кебек, ут аша үтеп ныгый, сөрем белән каплана, анысы, образга үзенчәлекле төсмер өстәп, тигезсезлекләрне каплап, рельеф ясый. Бизәкләрне ирем Сергей белән бергә эшләдек, ул минем хезмәттәшем дә, автордашым та.

Татарстан чыршысын бизәгән алты искиткеч курчакны Альбина Нуретдинова ясаган. Нәкъ менә әлеге уенчыклар ВДНХга килүче ханым һәм туташларны аеруча сокландырган.

– Эшләрем традицион костюмны уен формасы белән бәйли, әмма бу күбрәк сувенир продукт, – дип аңлата Альбина. – Милли код яхшы «укылсын» өчен, курчак киемен чын костюмга мөмкин кадәр якынрак итеп ясадым. Бу минем максатым иде. 2007 елдан, әни булганнан бирле курчак ясау белән мавыгам, ә милли костюм белән ун елдан артык шөгыльләнәм. Бүген исә бу минем һөнәремә әверелде – курчакларым күп кенә бүләк кибетләрендә сатыла. Барысын да үз кулларым белән эшлим: уенчыкның каркасыннан, курчакның йөз чалымнарыннан алып, киеменең вак элементларына кадәр.

Сүз уңаеннан, Мәскәүдә тәкъдим ителгән курчаклар татар авыл костюмын кигән – җирлегенә вак чәчәк төшерелгән киҗе-мамык күлмәк, үсемлек орнаменты белән бизәлгән алъяпкыч (кулдан, тамбур чигеше), күн итекләр. Искиткеч! ВДНХ һәм «Россия» күргәзмәсенә килүчеләр телефоннарын кулдан төшерми – истәлеккә фотолар ясарга кирәк бит. Һәм алар, үзләре дә сизмәстән, милли мәдәни кодны укый, анда, инде аңлавыбызча, вак-төякләр нәрсәләр юк.

ӘСТЕРХАН. КАЗАН УРАМЫ



«Татарстан» журналистларының яртысы диярлек студент елларында төзелеш отряды составында Әстерханда булып кайткан. Әлбәттә, помидор плантацияләрендә уңыш җыюлар арасында шәһәрне күрергә дә өлгергәннәр. Алар шәһәрнең үзәк, тарихи өлешендә Казан урамын күреп гаҗәпләнүләрен хәтерлиләр әле.

Бу урамның тарихы без яратканча маҗаралы: исемен өч тапкыр үзгәрткәннәр. Башта, 1837 елга кадәр, урам Икенче Татар урамы дип аталган. Әмма Икенче Әрмән бистәсе дә булган. Экскурсоводлар сөйләвенә ышансак, Әстерханда ул вакытта ике генә «чит» бистә булган һәм икесе дә охшаш исемнәр белән аталган. Аннары, 1837 елда, «безнең» урамны Ак Мәчет урамы дип үзгәрткәннәр. Ә 1920 елда исә ул үзенең хәзерге исемен алган.

Казан урамы Әстерханда иң интернациональ урам санала. Ул Татар, Фарсы, Әрмән, Немец «этник» бистәләре кебек тарихи район буйлап сузылган. Анда архитектура һәйкәлләре дә шактый: Вагабия мәчете, Епифанов йорты (Изге Иоанн Златоуст хөрмәтенә чиркәүнең Икенче шәһәр мәхәллә училищесы), Гайсә хөрмәтенә евангелие-лютеран дине чиркәве пастораты бинасы, Кирха бинасы... Казан урамында транспорт йөрми, ул җәяүлеләр урамы санала.

Фотода – Әстерханның Казан урамындагы Кызыл мәчет. Халык бу иман йортын Казан мәчете дип йөртә. Эш шунда ки, аны сәүдәгәр Мөхәммәтшакир Казаков төзеткән. Ә аның этисе Мөхәммәт Казаков үз вакытында Казанда да мәчет салдырган булган.

Фото: Әскәр Сабиров, izhlife.ru

ИЖАУ. ТАТАРБАЗАР

Ижау (Ижевск) белән Казанны кайчандыр Казан юлы бәйләгән. Ижаудан көньякка таба чыгу юлын шулай дип атаганнар. Ләкин Гражданнар сугышыннан соң аны кызыл дивизия командиры Владимир Азин хөрмәтенә Азин урамы дип үзгәрткәннәр. Ә менә бу урамның революциягә кадәр Кызыл тау дип аталган районын, 1918 ел вакыйгаларыннан соң, Татарбазар дип йөртә башлаганнар. Ләкин базар урнашканга түгел, микрорайонның исеме шундый. XIX гасырда Ижауның әлеге районына якынтирә авыллардан татарлар корал җитештерүдә акча эшләп алырга дип килә торган булган, кайберәүләр шунда урнашып та калган.

Бүген бу район күп катлы төзелешкә каршы чыгышлары белән билгеле. Татарбазар – нигездә шәхси сектор. Һәм халык аз катлы төзелешне, шәхси йортларны ничек тә булса саклап калырга тырыша.

Фото: yandex.ru/maps

ОРЕНБУРГ. ТАТАР ТЕАТРЫ

Оренбургка баруга, театрны күрергә ашыгабыз. Кайсысына дип уйлыйсыз? Әлбәттә, Мирхәйдәр Фәйзи исемендәге Оренбург дәүләт татар драма театрына.

1905 елда ук бу шәһәрдә беренче татар театр труппасы пәйда була. Аны яшь һәм талантлы шәхес, соңрак татар театрының күренекле эшлеклеләренең берсенә әвереләчәк Ильясбәк Кудашев-Ашказарский оештыра.

1905 елның ноябре ахырында «Оренбург газетасы» болай дип яза: «Тиздән шәһәр театрында мөселман драма труппасы артистлары саф татар телендә спектакль куячак. Драма әдәбиятында саф татар теле яңалык. Билгеле булганча, татарларда театр үзе дә әлегә кадәр булмаган. Оренбургка, Россиянең барлык шәһәрләреннән беренче булып, әлегә кадәр үз эченә бикләнгән халыкның бу башлангычын күрергә һәм лаеклы бәя бирергә туры киләчәк. Мөселман хатын-кызы беренче тапкыр үз диненнән булган ир-ат каршында битен капламыйча күренәчәк».

3 декабрьдә (яңа стиль буенча 16 декабрьдә) «Оренбург газетасы»ның баш битендә чакыру да басылып чыга: «Бары тик бер генә гастроль. Шәһәр театры. Шәрык бәйрәме. Россиядә 1 нче тапкыр И.Б. Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге драма труппасы артистлары тарафыннан рус һәм татар телләрендә спектакльләр куелачак. Рус телендә: "Горе от ума" – А.С. Грибоедов комедиясе, «Ревизор» – Н.В. Гоголь комедиясе. Татар телендә: «Свет и тьма», яисә «Наданлык илә Галимлек». Милли костюмнар һәм яңа декорацияләр. Ахырда Синематограф – фотога төшерү буенча бертуган Люмьерлар фабрикасының иң камилләштерелгән аппараты. Антрактларда Г.Ф. Эстеррейх җитәкчелегендәге кыллы оркестр шәрык пьесаларын башкарачак. Шулай кирәк булганга, бельэтаж бары тик хатын-кызлар персоналы өчен генә билгеләнгән. Мөселман хатын-кызлары өчен урыннар вуаль пәрдәләр белән аерылып тора. Керү, коридор, зал һәм өске күлмәкне саклау өчен элгечләр бөтенләй читтә – ир-атлар керми торган урында. Хатын-кыз хезмәтче рус милләтеннән. Урын бәяләре бенефислы. Музыка – 8 сәгатьтә, ә спектакль кичке 8,5 сәгатьтә башлана».

Ләкин өметле афишаларга карамастан, спектакль булмый кала. Бу хакта «Красная Татария» газетасы 1935 елда болай дип яза: «Спектакль куюга рөхсәт алу Кудашевтан зур тырышлык таләп итә. Петербургка да барырга туры килә. Рус чиновниклары гына түгел, татар буржуазиясе, руханилары да каршы тора. Ниһаять, барлык бусагалар тапталганнан соң, спектакль куюга ризалык алына. Әмма соңгы минутта Оренбург губернаторы спектакльне тыя, чөнки «бу татар халкы арасында ызгыш-талаш китереп чыгарырга мөмкин».

Ике елдан соң, 1907 елда труппа А. Островскийның «В чужом пиру похмелье» пьесасын яңадан куя һәм, канцелярияләр буйлап озак йөргәннән соң, Оренбургта спектакль уйнарга рөхсәт ала. Әлеге спектакль белән труппа үзенең беренче гастрольләренә чыга. Гастроль юлы да авыр була: Бузулукта һәм Чистайда спектакльләр рөхсәт ителми. Ә менә Самарада, Сембердә, Түбән Новгородта, Касыймда Оренбург татар театры зур уңыш казана.

Оренбург өлкәсендә татар театры бармый калган бер генә төбәк тә юктыр – театр әле яшь, яңа чагында да, колхоз-совхоз күчмә театры статусындагы вакытында да, дәүләт филармониясенең драма коллективы саналганда да.

1990 елда татар дәүләт драма театры оештырыла. 1991 елда аңа якташлары, татар драматургиясе классигы Мирхәйдәр Фәйзи исеме бирелә. Шул ук елда театрга Оренбург өлкә филармониясе бинасы тапшырыла. 2008 елның 18 декабрендә, реконструкциядән соң, театр бинасы рәсми рәвештә ачыла. Күп еллар дәвамында театр өлкә буенча гына түгел, аннан читтә дә гастрольләрдә йөри: Самара, Сызрань, Тольятти, Әстерхан, Җаек (Уральск), Актюбинск, Екатеринбург, Төмән, Татарстан һәм Башкортстан шәһәр һәм авыллары. Ә «Татарстан» Оренбургта булганда, һәрвакыт «үз» театрына барырга тырыша. Декабрьдә биредә «Өйләнү түгел сөйләнү», «Сагынган чакларымда», ә балалар өчен «Алмаз тавының сере» сәхнәләштерелә. Һәм тагын – индивидуаль синхрон аудиотәрҗемә дә бар.

ЕВРАЗИЯ БЕЛӘН САХАЛИН АРАСЫНДА. ТАТАР БУГАЗЫ



Фото: russian-arctic.info

Татар бугазы Япон һәм Охот диңгезләрен тоташтыра. Татарстаннан аңа кадәр бик ерак, төгәлрәге – 8433 километр. Ләкин бернинди чакрымнар да, бозлы сулар да Татар бугазына булган кайнар мәхәббәтебезне суындыра алмый, чөнки ул «татар» сүзе белән бәйле.

Татарстанга шундый якын исемнең килеп чыгышын Европада X-XVIII гасырларда Уралдан көнчыгыштарак һәм көнбатыштарак, Камчатка һәм Сахалин җирләренә кадәр таралып яшәгән Евразиянең төрки халыкларының күпчелеген татарлар дип атаулары белән аңлаталар. Башта бу бугаз «Тартария култыгы» дип аталган, һәм әлеге атама 1851 елгы диңгезчеләр картасында сакланган – Strait of Tartary. Француз диңгезчесе Лаперуз аны шулай дип атаган, ул заманда «Тартарияне бөтен Төньяк Азияне колачлаган гаять зур мифологик ил буларак күзаллаган географик концепт киң таралган булган».

Һәм бары тик японнар гына Татар бугазын «Мамия Риндзо» дип атый – бугазны беренче булып ачкан япон һәм Сахалинны тикшерүче хөрмәтенә.

Элекке заманнарда ничек булгандыр, әмма безнең горурланырлык нәрсәләребез бар: Татар бугазы Төньяк ярымшарда иң озыны булып санала – аның озынлыгы 713 километр! Ә киңлеге – 40–328 км.

Гомумән, галимнәр Татар бугазын табигать могҗизасы дип атый. Аның тирәнлеге ярдан ике миль ераклыкта ук – 37 метр, ә Сахалин ярлары буенда, Лессепс борыны янында, тирәнлеге 50 дән 100 метрга кадәр. Ә менә Лазарев һәм Погиби борыннары арасында, имеш, утраудан материкка кадәр җир асты юлы уза, тирәнлеге 10 метр гына.

Бу суларда бөкрәч (горбуша) һәм чавыча, алабуга һәм кызыл балык (нерка) бар. Яр буенда яшәүчеләр кайвакыт җылы су яратучы ике метрлы акулаларны да тоталар, алар, күрәсең, салкын сулы урынга кызыксынучан булулары аркасында килеп чыга. Татар бугазында сельдь, чабак, терпуга балыкларын тоталар.

Суднолар хәрәкәте монда кыш көне дә тукталмый: бозваткыч акваторияне боз катламыннан даими чистартып тора. Тәүлек әйләнәсе 22 причал эшли.



БАРЛЫК ГАЗ КУЛЛАНУЧЫЛАР ӨЧЕН «БЕРДӘМ ТӘРӘЗӘ»

ТАТАРСТАНДА «ГАЗПРОМ ТРАНСГАЗ КАЗАН»ГА АБОНЕНТЛАР БЕЛӘН ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ИТҮНЕҢ ЯҢА ПЛАТФОРМАСЫ КЕРТЕЛГӘЧ ПӘЙДА БУЛДЫ

«Газпром трансгаз Казан» җәмгыяте «Газпром» Компанияләр төркеменең **уникаль предприятиесе** булып тора. Предприятие җаваплылыгы зонасына берьюлы бернича эш юнәлеше керә: магистраль һәм бүлү газүткәргечләре буенча табигый газны ташу, табигый газ кулланучыларның барлык категорияләрендәге газ үткәргечләрен һәм газ җиһазларын газ белән тәэмин итү һәм техник хезмәт күрсәтүне тәэмин итү, федераль һәм төбәк программаларын гамәлгә ашыру кысаларында газлаштыру буенча барлык эшләр, Татарстан Республикасы халкына табигый газны сату.

Көн саен бер миллион алты йөз меңнән артык абонент бу кыйммәтле ресурс байлыгыннан файдалана. Зәңгәр ягулык өйдә комфорт һәм уңайлыклар тудыра, һәм болар барысы да ышанычлы һәм өзеклекләрсез эш нәтиҗәсендә мөмкин.

Төбәкне табигый газ белән тәэмин итү дәрәҗәсе – 99,5 %тан артыкны, Татарстан Республикасы халкына еллык газ сату күләме 1,8 млрд кубометрны тәшкил итә. **Газ кулланучылар саны даими үсә.**

Газлаштырылган йорт һәм фатирлар санының ел саен интенсив үсеше, шулай ук кулланучыларга газ белән тәэмин итүдән алып газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлауга кадәр булган тулы спектрдагы хезмәт күрсәтүнең кирәклеге **Җәмгыятьтән** сервис сыйфатын яхшырту, клиентка юнәлү курсын сайлау һәм абонентлар белән хезмәттәшлеккә бәйле бизнес-процессларны максималь дәрәҗәдә цифрлаштыру буенча **радикаль чаралар күрүне таләп итте.**

2021 елда Җәмгыять тарафыннан, «Газпром» ГАҖ ярдәме белән, биллинг исәп-хисаплары һәм абонентлар белән эшләүнең **принципиаль яңа,** заманча системасына күчү турында карар кабул ителә. Базарны анализлау нәтиҗәсендә, кулланучылар онлайн режимда газ өчен түли һәм үз исәп-хисапларын күзәтеп бара алсын өчен, уңайлы платформа сайланды. Моннан тыш, дәүләт ТКХ мәгълүмат системасы белән турыдан-туры интеграциядә булуы, шулай ук үтәлешен закон таләп иткән һәм газ, күрсәтелгән хезмәтләр өчен түләүнең нәтиҗәләлеген яхшыртуга караган күпчелек операцияләрне автоматлаштыру мөмкинлеге әлеге платформаны моңа охшаш башка системалардан аерып тора.

Бизнес-процессларны проектка кадәр тикшереп, уңышлы эшләтеп карап, барысын да җайга салганнан соң, 2022 елның сентябрендә абонентлар белән исәп-хисап һәм үзара хезмәттәшлек платформасы файдалануга тапшырылды.

Платформаны финанс ыгы-зыгылары һәм дебиторлык бурычы тирбә-

Фото «Газпром трансгаз Казан» Җәмгыятеннән алынды. РЕКЛАМА

лешләреннән башка гына, уңышлы итеп эшләтеп җибәрү көчле команда ярдәменә таяну нәтиҗәсендә мөмкин булды. Бу командага Газпром компанияләре төркеме өчен терәк банк, яңа, югары технологияле продуктлар булдыруда технологик партнер «Газпромбанк» АҖ, тармак формалаштыручы эре предприятиеләр мәнфәгатендә катлаулы мәгълүмат системаларын җайлап һәм эшләтеп җибәрү буенча күпьеллык тәҗрибәгә ия «ЭТП ГПБ Консалтинг» ҖЧҖ һәм барлык дәрәҗәләрдә югары компетенцияле белгечләргә ия «Газпром трансгаз Казан» компаниясе керә. Нәтиҗәдә яңа платформага күчү процессы Җәмгыять өчен уңайлы һәм кулланучылар өчен сизелмичә диярлек узды.

Яңа универсаль платформа башта энергетика секторы абонентларына хезмәт күрсәтү өчен эшләнгән, ТКХ өлкәсе предприятиеләрендә уңышлы файдаланылган. Безнең республикада кертелгәнгә кадәр платформа **биш төбәк газ компаниясе** тарафыннан сәнәгать файдалануына кертелгән булган: Псков, Владимир, Новгород, Ярославль һәм Самара өлкәләрендә. Әмма безнең предприятиенең уникальлеген һәм үзенчәлеген исәпкә алып, **платформа берничә зур үзгәреш кичерде.**

Беренчедән, шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: без системаны **100% импортны алмаштырган җиһазлар белән тәэмин иттек,** бу яктан пионерлар булып торабыз. Платформа мәгълүмат базалары белән идарә итүнең илебездә эшләнгән системасы буенча эшли. Икенчедән, бу – платформаның уникаль версиясе. Анда һәр предприятиенең исәп-хисаплары бер урында тупланган: бу – газ өчен, халыктагы газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү, бер тапкыр һәм даими башкарылган ремонт эшләре, халык ихтыяҗлары өчен газ сатып алучы юридик затларның газ өчен түләүләре. Шулай ук ЖСК, ТСЖ кебек юридик затлар белән газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү өчен исәп-хисап тупланган бөтенләй яңа блок өстәлгән. Өченчедән, 1,6 миллионнан артык абонент – бүгенге көндә платформада берьюлы хезмәт күрсәтелә торган абонентларның иң зур саны.

Яңа платформаны кертү элек компания һәм абонентлар алдында торган **техник һәм методик чикләүләрне** кыска вакыт эчендә **җиңәргә мөмкинлек бирде.** Күп кенә таркау мәгълүмат базалары урынына бердәм, үзәкләштерелгән система пәйда булды. Аның мәгълүмат эшкәртү тизлеге элеккегесеннән күп тапкырга артыграк. Мәсәлән, **элек сигез сәгать таләп ителгән операция хәзер 30 минут эчендә башкарыла.** Ә 72 мәгълүмат базасыннан берничә эш көне эчендә җыела торган аналитик мәгълүматны хәзер бер тапкыр төймәгә басу белән алырга мөмкин. Заманча техник карарлар абонентның Шәхси кабинеты һәм Газлаштыру хезмәте буенча бердәм тәрәзә кебек тышкы клиент сервислары белән тулы канлы онлайн-интеграцияләнүне тормышка ашырырга мөмкинлек бирде. Бу исә хәзер эшләп бетерүнең соңгы этабындагы «Газ өчен түләү» мобиль кушымтасы эшләнгән.

«Газпром трансгаз Казан» Җәмгыяте абонентлары кулланучының шәхси кабинеты һәм **мобиль кушымта мөмкинлекләреннән теләсә кайсы җайланмаларда**: компьютерларда, планшетларда, смартфоннарда комплекслы файдалана алачак. Онлайн-хезмәтләр аша газ, техник хезмәт күрсәтү һәм газ җиһазларын ремонтлау өчен түләү хәзер кәрәзле элемтә хезмәтләре өчен түләү кебек үк уңайлы һәм тиз башкарыла. Сервисларда комиссия юк, ә уңайлылык өчен айлык автомат түләүне көйләргә мөмкин. Өстәмә рәвештә «GazpromPay» сервисы аша түләү функциясе интеграцияләнә ала.

«ГАЗ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ» МОБИЛЬ КУШЫМТАСЫ КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕ ӨЙДӘН ЧЫКМЫЙЧА ГЫНА ТАПШЫРЫРГА, БУРЫЧНЫ ТИЗ АРАДА ТҮЛӘРГӘ МӨМКИНЛЕК БИРӘ. ХӘЗЕР АБОНЕНТ ПУНКТЫНА ЯИСӘ БАНККА БАРУ ТАЛӘП ИТЕЛМИ, Ә ЭЛЕКТРОН ФОРМАТТАГЫ КВИТАНЦИЯНЕ СЕЗ ҺӘРВАКЫТ ТИЕШЛЕ БҮЛЕКТӘ ТАБА АЛАСЫЗ. КҮПМЕ ТҮЛӘРГӘ КИРӘКЛЕГЕ ҺӘМ ТҮЛӘНГӘН АКЧА ТУРЫНДАГЫ МӘГЪЛҮМАТ ҺӘРВАКЫТ КУЛ АСТЫНДА ГЫНА. БАРЫСЫ ДА БИК ҖИҢЕЛ. КУШЫМТАГА GOOGLE PLAY ҺӘМ APP STORE СЕРВИСЛАРЫНДА КЕРЕП БУЛА.

Газ һәм күрсәтелгән хезмәтләр өчен исәп-хисап платформасын кертүнең методик алшартларына килгәндә, хәзер абоненттан аналитик мәгълүматны алу, эшкәртү һәм дөрес интерпретацияләү ихтыяҗы беркайчан булмаганча югары. Платформа мәгълүматны алу, эшкәртү өчен бердәм бизнес-процесслар төзергә мөмкинлек бирде.

Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның халык һәм сәнәгать газ кулланучылары өчен төбәкләрне газ белән тәэмин итүне һәм газлаштыруны үстерүгә юнәлдерелгән **йөкләмәләрен тулы күләмдә үтәү мөмкинлеге** системаны кертүнең төп уңай нәтиҗәсе булып тора.

Платформа – югары технологияле цифрлы сервис, газ кулланучылар өчен «бердәм тәрәзә». Әлеге цифрлы чишелешнең бурычы – абонентларга газ һәм күрсәтелгән хезмәтләр өчен исәп-хисап процессын гадиләштерү, бу исә акчаларны җыюны арттыруга китерә. Моның өчен абонентның платформага тулысынча интеграцияләнгән Шәхси кабинеты **һәм хәзер эшләп бетерүнең соңгы этабындагы «Газ өчен түләү» мобиль кушымтасы эшләнгән**.

Әлеге онлайн-сервис кулланучыларына хезмәтләр күрсәтү спектры киң. Исәп-хисап платформасы белән турыдан-туры интеграцияләнү **түләү суммасын мизгел эчендә исәпләп чыгарырга** мөмкинлек бирә: Шәхси кабинетта яки мобиль кушымтада кулланылган газ күрсәткечләре кертелгәч, актуаль бәя һәм аларны онлайн-режимда түләү мөмкинлеге барлыкка килә, ә түләү нәтиҗәләре дә кулланучыга шунда ук күренә. Шулай ук абонентлар **мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар бирә,** аларга кирәкле документларны беркетә һәм гаризаларның статусын һәм үтәлеш этапларын күзәтә ала. Җәмгыять абонентлар белән өстәмә элемтә каналына ия булды. Ул абонентларга актуаль түләү документларын һәм исәп-хисап турында мәгълүмат җибәрә, газга бәйле иң мөһим хәлләр турында push-хәбәрләр аша җиткерә.

Платформаны кертү Җәмгыятьнең цифрлы үсеше өчен перспективалы шактый күп юнәлешләр ача. **Бердәм газлаштыру операторы порталы белән тирән интеграция процессы**

актив фазада, аның ахыргы максаты – абонент белән үзара бәйләнеш чылбырын (газ кертүгә гариза бирү, газ белән тәэмин итү челтәрен булдыру һәм аңа тоташу, газны тәүлек әйләнәсе өзеклекләрсез биреп тору, кулланучылар белән ачык, төгәл исәп-хисап эшләрен оештыру, газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау буенча киң спектрлы хезмәтләр белән тәэмин итү) тулысынча цифрлаштыру.

Яңа платформа архитектурасына **абонентлар белән үзара эш итүнең куәтле, технологик яктан үсеш алган ысулы – «Контакт-үзәк» программасы** кертелгән, бу – кулланучыдан килгән гаризаны һәм мөрәҗәгатьне кабул итүгә, эшкәртүгә һәм максатчан маршрутлаштыруга юнәлдерелгән цифрлы чишелеш. Әлеге программа продуктының эргономиклыгы һәм тар юнәлеше барлык мөрәҗәгатьләрне объектив, тулы күләмдә һәм вакытында карарга, аларга эчтәлекле җавап җибәрергә мөмкинлек бирә. Әлеге продуктка таянып, Җәмгыять Бердәм контакт-үзәк булдырган, аның хезмәткәрләре газ белән тәэмин итү һәм хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча **килгән мөрәҗәгатьләрне эшкәртәләр,** барлык булган элемтә каналларын һәм ысулларын, шул исәптән автомат шалтырату, СМС һәм push-хәбәр, шәхси телефон сөйләшүләре кебек дистанцион түләтү технологияләрен кулланып, абонентлар белән үзәкләштерелгән рәвештә аралашалар. Мондый алым халык белән исәпләүләрнең нәтиҗәлелеген тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Интерактив тавыш менюсы технологиясе белән керүче шалтыратуларны кабул итү өчен **8 (843) 222-05-55 бердәм телефон номеры билгеләнгән,** аның ярдәмендә исәп приборлары күрсәткечләрен тапшырырга, газ белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча кирәкле мәгълүматны алырга мөмкин. Әлеге ысулларны куллану киләчәктә Татарстан Республикасы гражданнарының телефон мөрәҗәгатьләрен эшкәртүне тулысынча үзәкләштерергә һәм Контакт-үзәкнең дистанцион эшен җайга салырга, шулай ук абонентлардан күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфаты турында мәгълүмат алырга мөмкинлек бирәчәк.

Абонентлар белән үзара эш итү каналларын оештыру кысаларында Җәмгыять тарафыннан омниканал концепциясе кабул ителгән, анда күпсанлы элемтә каналлары аша килгән мөрәҗәгатьләр һичшиксез каралачак һәм тулысынча эшкәртеләчәк. Абонентлар белән үзара эш итү өлкәсендә яңа технологик карарларны даими анализлап, Җәмгыять аларның иң заманча һәм перспективалыларын куллана. Мәсәлән, абонентлар өчен **«Яндекс» компаниясенең Алиса тавыш ярдәмчесе аша** аралашу каналы бар, аның ярдәмендә абонент күрсәтмәләрне тапшыра һәм исәп приборының торышы һәм бурыч суммасы турында мәгълүмат ала ала. Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре порталы сервислары белән тыгыз интеграция гамәлгә ашырылган, газ белән тәэмин итүгә бәйле мәгълүмат платформага килә һәм вакытында эшкәртелә.

СОРАУЛАР КАЛГАН ОЧРАКТА, МОБИЛЬ КУШЫМТА АША КОНТАКТ-ҮЗӘК БЕЛГЕЧЕНӘ ҮЗЕГЕЗНЕ КЫЗЫКСЫНДЫРГАН МӘСЬӘЛӘ БУЕНЧА ГАРИЗА ЮЛЛАРГА МӨМКИН. ЯҢА ПЛАТФОРМА АРХИТЕКТУРАСЫНА АБОНЕНТ БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ИНСТРУМЕНТЫ, КУЛЛАНУЧЫДАН КЕРГӘН ГАРИЗА ҺӘМ МӨРӘҖӘГАТЬЛӘРНЕ КАБУЛ ИТҮГӘ, ЭШКӘРТҮГӘ ҺӘМ МАКСАТЧАН МАРШРУТЛАРГА БҮЛҮГӘ ЮНӘЛДЕРЕЛГӘН ЦИФРЛЫ ЧИШЕЛЕШ КЕРТЕЛГӘН.

Цифрлы үсеш кысаларында түбәндәге юнәлешләр буенча **җентекле тикшеренү үткәрелә:**

– абонентлар өчен, Җәмгыятьнең абонент пунктларына бармыйча гына, газ белән тәэмин итү системасына тоташу, газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау һәм газ кертү буенча комплекслы килешүләргә электрон рәвештә кул кую мөмкинлеген оештыру өлешендә РФ Дәүләт хезмәтләре порталына **интеграцияләнү**;

– газ хуҗалыгы контролерлары өчен мобиль сервис булдыру, аның ярдәмендә хезмәткәр теге яки бу абонентның газ, техник хезмәт күрсәтү һәм алынган башка төр хезмәтләр өчен түләве турында актуаль мәгълүматка ия булачак;

– абонентны борчымыйча гына газны исәпкә алу приборларын тикшерү нәтиҗәләре турында актуаль мәгълүмат алу өчен **Аршин ФГИС белән интеграцияләнү;**

– газ җитештерүче һәм түләү агентларының контактлары, гамәлгә ашырыла торган хезмәтләр турында мәгълүмат, **«сорау – җавап» форматын булдыру**.

Һичшиксез, Җәмгыятьнең тырышлыгы абонентны цифрлы хезмәт күрсәтүгә максималь җәлеп итүгә юнәлдерелгән, әмма шул ук вакытта ул махсус пунктларга барып хезмәтләр алырга теләүче абонентлары турында да онытмый. **Абонентларга Бердәм хезмәт күрсәтү үзәкләрен оештыру буенча максатчан программа** кысаларында компаниянең абонент пунктларын бердәм корпоратив стильгә кертү, аларда клиентларга хезмәт күрсәтүнең уңайлылыгын һәм куркынычсызлыгын күздә тота торган заманча таләпләргә җавап бирүче киңлек булдыру ягыннан да зур эш алып барыла. Нәтиҗәдә Җәмгыять абонентларының 40 %ы (ә бу 600 меңнән артык шәхси исәп-хисап) көндезге хезмәт күрсәтүнең яңа форматыннан файдалана алачак.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: яңа продукт һәм чишелешләр уйлап табу, халыкка газ җиткерү процессын тулысынча цифрлаштыру ахыр чиктә безнең абонентлар өчен бәхәссез уңайлылыклар кертүгә юнәлдерелгән. Яңа исәпләү платформасы һәм аңа бәйле продуктлар – халык һәм Җәмгыять арасындагы элемтәләрне җиңеләйтә, вакыт ягыннан гадиләштерә, ә исәпләүләрне уңайлырак һәм аңлаешлырак итәргә мөмкинлек бирә торган кораллар. **Компания өчен клиентка юнәлгәнлек буш сүзләр генә түгел.** Безнең өчен һәр кулланучының табигый газ чыгымнарын реаль вакыт режимында күзәтүе, күпме куллануын, нинди хезмәтләр кирәклеген һәм аларны ничек ала алуын белүе мөһим. Һәм без, абонентлар белән аралашу ысулларын үстереп һәм камилләштереп, үз максатыбызга таба ышанычлы адымнар белән атлыйбыз.

акыллы гамәлләр
игелекле эшләр
мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

«Туган Батыр»ны яңа офыкларга **нинди** көчләр этәрә

Каз өмәсе **нинди** үзгәреш кичергән

Удмуртлар Портмаськон бәйрәмендә **ниләр** эшли

Чувашлар Сурхури бәйрәменә **ничек** әзерләнә

Шорыкйол – «сарык аягы»ннан марилар **ниләр** көтә

ТУГАН БАТЫР. БЕР ПРОЕКТНЫҢ ГАЙРӘТЛЕ БИШ КӨЧЕ

Татар әкиятләре һәм мәдәни традицияләре нигезендә Татарстан командасы тарафыннан уйлап чыгарылган Туган Батыр турында эпосның беренче өлеше 2022 елда дөнья күрде. Ике елдан да кимрәк вакыт эчендә китап халыкара дәрәҗәдәге зур проектка әверелде. «Татарстан» проектны яңа офыкларга нинди гайрәтле көчләр алып баруын белеште.

1. Мәдәниятебезгә мәхәббәт, ата-бабаларыбызга хөрмәт

Туган Батыр галәме татар мәдәнияте элементларыннан корылган: аның дөньясын баеткан символ, бизәк, исемнәр, әкияти затлар безгә татар халык авыз иҗаты, Тукай әсәрләре аша, милләтебезнең дөньяви һәм дини традицияләренең мәдәни коды буенча таныш бәянны дәвам иттерә. Туганның билгесе – күккә төбәлгән уклы җәя. Ул Казан татарлары символы санала. Каһарманның тугры юлдашлары – ат белән лачын – борын-борыннан төркиләр белән ассоциацияләнә. Кая барса да, нәрсә генә эшләсә дә, Туган Батыр үз ватаныңны ярату, тугры хезмәт итәргә әзер булу, әти-әнине хөрмәт итү, кыюлык, намуслылык, шәфкатьлелек кебек ата-бабалардан мирас булып калган рухи кыйммәтләргә таяна. Заманча телдә язылган, анимацияле, киберкиңлекле бу мөһим хакыйкатьләр дөньядагы барлык халыкларга да аңлашыла. Димәк, Туган Батыр да аларга якын.

«Туган Батыр» проектының уникальлеге – аның көчендә, бу көч бөтен төрки дөньяны берләштерергә, шул ук вакытта яшь буынның язмышына һәм аны тәрбияләүгә битараф калмаган, милли үзенчәлегебезне саклауның кирәклегенә инанган кешеләрне дә берләштерергә сәләтле», – ди Бөтендөнья татар конгрессы Милли шурасы рәисенең беренче урынбасары Данис Шакиров.

2. Гореф-гадәтләргә тугры калу һәм үз халкың белән горурлану

«Безнең гаилә укымышлы иде. Әтием инкыйлабка кадәр Казанда укытучылар мәктәбен тәмамлаган. Әни дә укымышлы булып, иске имланы белә иде. Апам бөтен авыл хатын-кызларын укытты, халык аны гомер буе остаз буларак искә алды. Минем өч балам бар, алар – икътисад фәннәре докторлары... Безне укытучылар династиясе дияргә була», – дип сөйли Казаннан Нурания Газиева. Ул – Татарстанның күренекле татар теле укытучыларыннан. Быел 100 яшен билгеләп үтте. Күренекле нейрохирург Альберт Суфиянов, татарча көрәш һәм билбау көрәше

Фотолар «Туган Авылым» милли комплексы матбугат үзәгеннән алынды. 6+

буенча биш тапкыр дөнья чемпионы Ренас Кәлимуллин, атаклы очучы Дамир Йосыпов һәм башка бик күпләр кебек, Нурания Газиева да «Халкым – татар. Уңыш коды» фильмының герое булды. «Туган Батыр» проекты командасы тарафыннан төшерелгән әлеге фильм XIX Казан халыкара мөселман киносы фестивалендә үз номинациясендә җиңү яулады.

– Без бу фильмны батырларның әкият персонажы түгел, ә арабызда яшәүче кешеләр булуын күрсәтү өчен төшердек. Һәр кеше батырлык кыла, каһарман була ала, – ди «Туган Батыр» проекты җитәкчесе, аның инициаторы һәм идея рухландыручысы Радик Абдрахманов.

3. Иң яхшылар белән хезмәттәшлек

«Казаным дөньядагы иң матур һәм уңдырышлы урында төзелгән. Явыз сихерче Сарыкан матур илебезне яулап алмакчы була. Ул Елан патшасы Зилантны аңа хезмәт итәргә мәҗбүрили. Ләкин мин, Галим бабай, аларны җиңдем. Сарыканның көчен һәм җиңүемнең ачкычын мин зихгир йөзегенә тыгып куйдым» – Туганга әләгәчәк тылсымлы йөзекнең мондый алтарихы «Туган Батыр» дип аталган анимацион сериал тизерында бәян кылына. Аның беренче сезоны 2024 ел ахырында дөнья күрәчәк. Сериалны Россиянең «Фиксики», «Смешарики» һәм башка популяр мультфильмнарын төшергән осталар ясый.

– Татарстанның мәдәниятенә һәм тарихына, легендаларына һәм мифларына нигезләнгән сюжет безгә илһам бирә. Сыйфатлы, кызыклы һәм көндәшлеккә сәләтле фильм булдырырга телибез. Россиядә дөнья дәрәҗәсендәге мультфильмнар чыгара ала торган искиткеч белгечләр бар, һәм аларның күбесе – безнең иҗат командасында, – ди сериалның креатив продюсеры Юлия Софонова.

Бу тизер, проектның үзе кебек үк, быел Санкт-Петербург халыкара икътисадый форумыннан алып Казанда узган «РОСТКИ» Россия-Кытай форумына кадәр – Россиянең барлык федераль дәрәҗәдәге мәйданчыкларында тәкъдим ителде. Сериалның «дөньякүләм» премьерасы ноябрьдә булды. Якын Көнчыгыш, Азия, Европа, Латин Америкасы илләреннән контент сатып алучы 200 компания вәкиле Туган Батыр галәме белән Дубайда узган DICM 2023 халыкара кинобазарында танышты, һәм әлеге проект аларның игътибарын җәлеп итте.

4. Глобаль күзаллау һәм дус була белү

土着蝙蝠 – кытай телендә Туган Батыр исеме менә шулай языла. Үзенең милли колориты, кызыклы сюжеты һәм геройлары белән бу яңа татар эпосы, чит илләрдә популярлаша барып, бар дөньяны яулый. Проект вәкилләре Кытай консулында кунакта булды һәм әлеге ил делегациясенә «Туган Батыр» китабының кытай телендәге басмасын тапшырды. Киләчәктә әкиятне Кытай маркетплейсларында сата башлау ниятләнә. Ә инде киләсе елда Туган Батыр, туры мәгънәсендә дә, күчерелмә мәгънәдә әйткәндә дә, Төркиягә юл тотачак. Танылган татар язучысы Зөлфәт Хәким тарафыннан хәзерге вакытта әзерләнеп яткан өченче китапта Туганның маҗаралары нәкъ менә шушы илдә дәвам итәчәк. Өченче томны тәкъдим итү дә Төркиядә төрек телендә узачак. Әкиятне испан телендә Панама, Мексика һәм Перуда зур түземсезлек белән көтәләр, анда «Туган Батыр» Бөтендөнья татар конгрессы проекты кысаларында Лима шәһәрендә тәкъдим ителде. Авторлар чираттагы идея белән янып йөри: яңа сюжет өчен алар Туганны БРИКС илләре легендаларындагы геройлар белән дуслаштырырга тели.

5. Киләчәккә омтылыш

– Балалар өчен контент булдыру белән мәшгуль кешеләргә аудиториянең фикерен, карашларын һәм өстенлек бирә торган кыйммәтләрен формалаштыру мәсьәләсендә зур җаваплылык йөкләнә. Лаеклы буын тәрбияләү, татар мәдәниятен актуальләштерү, заманчалаштыру, аны модага һәм стильгә әйләндерү безнең үзебез өчен кирәк, – ди «Туган Батыр» проектының иллюстрацияләр авторы Диләрә Газиева. Мондый эш алымы, фикер проектның барлык юнәлешләре – Алабугада ел саен укчылар турнирын оештырганда да, «Бәләкәч» балалар җыр конкурсын уздырганда да, аттракционнар паркында «Туган Батыр» уен зоналарын ачканда да, мобиль кушымта аша карап була торган «Туган Батыр» VR-энциклопедиясен эшләгәндә дә, киберспорт турнирлары үткәргәндә дә һәм башка күп нәрсәләрдә дә чагылыш таба.

– Эшебезнең һәр юнәлешендә без балалар фикеренә таянабыз. Киләсе адымнарыбызның берсе – балалар арасыннан проектны үстерүдә катнашачак директорлар советы булдыру, – ди Радик Абдрахманов. – Туган Батыр язмышына бәйле мөһим карарлар кабул итеп, алар тормышта да кирәкле карарлар кылырга өйрәнәчәк.



ИЛГИЗ ЗӘЙНИЕВ:
КУРЧАК – УЕНЧЫК ТҮГЕЛ, ҖИТДИ СӘНГАТЬ ЮНӘЛЕШЕ УЛ

Мөршидә Кыямова

Театрдагы тәэсирле чыгышлар тамашачының бар игътибарын җәлеп итә һәм сокландыра. Күп гасырлар элек барлыкка килгән һәм үсеш-үзгәреш аша озын юл үткән әлеге сәнгать бүгенге көнгә кадәр дөньяда иң популяр күңел ачу төрләренең берсе булып кала бирә.

Курчак театры – традицияләрне һәм инновацияләрне, тарихны һәм хәзерге заманны берләштергән искиткеч сәнгать. Үзенең киңкырлылыгы һәм танылганлыгы аркасында, ул күп кенә илләрдә иң кирәкле күңел ачу төрләре арасында тора. Шул ук вакытта һәр милләт аңа үз төсмер һәм традицияләрен кертә, тәэсирләрне онытылмаслык итә.

Тарихка күз салсак, әүвәл курчак театры легенда, миф һәм дини сюжетларны тапшыруның тагын бер ысулы буларак һәм кешеләр өчен күңел ачу формасы рәвешендә барлыкка килгән.

Россиядә курчак театры аеруча Петр I һәм Екатерина II идарә иткән заманнарда популяр булган. Нәкъ шул чорда күпсанлы театрлар оештырыла, алар курчаклар катнашында төрле музыкаль һәм театр спектакльләрен тәкъдим итә. Курчаклар җитеннән, агачтан һәм башка материаллардан ясала, ә аларның детальләре җентекләп эшләнә.

Татарстанның да үз курчак театры бар. Казанда урнашкан «Әкият» курчак театры республикабызның олпат театрларыннан берсе санала. 2024 елда театр үзенең 90 еллык юбилеен билгеләп узарга әзерләнә. Әлеге уңайдан театрның сәнгать җитәкчесе, республиканың атказанган сәнгать эшлеклесе Илгиз Зәйниев белән сөйләштек.

Бүгенге көндә Илгиз Зәйниев – иң популяр татар драматургларының берсе. Аның әсәрләре Татарстан театрларында гына түгел, башкорт, мари, рус, азәрбайҗан, уйгур, казах телләрендә дә сәхнәләштерелә. Илгиз Зәйниев режиссер, үзенчәлекле иҗатчы буларак та үзен күптән танытты инде.

Фотолар И.Зәйниевнең шәхси архивыннан, Р. Нәҗмиевтән алынды

«ДРАМАТУРГИЯНЕ САЙЛАР ИДЕМ»

– Илгиз Газинурович, бер әңгәмәдә үзегезне режиссер булып эшләүче драматург дигән идегез... Шулай да сез үзегезне күбрәк кайсысы итеп тоясыз?

– Аннан соң минем тагын бер һөнәрем өстәлде әле – театр җитәкчесе. Монысы инде тагын бер аерым дөнья. Шулай да, асылда минем үземне барыбер драматург итеп тоясым килә. Сайларга мәҗбүр булсам, һичшиксез драматургияне сайлар идем. Үз әсәреңне куюның ике ягы бар. Мин автор буларак үз әсәремнән читләшә алам. Пьесаны спектакль чыкканчы камилләштерергә мөмкин, чөнки әсәр сәхнәдә куелганчы язылып бетмәгән, дип саныйм. Репетиция вакытында да кулдан язып, артистларга таратам, ягъни соңгы көнгә кадәр мин аны үзгәртә алам. Автор буларак әсәр башта бертөрле языла, ә тере кеше белән эшли башлагач, ул бөтенләй икенче төсмер алырга мөмкин бит.

– Пьесаларыгызны сораучылар турында да еш ишетәм. Төрле театрлар сезнең әсәрләргә тукталасы итә. Аларны бергә туплап китап чыгарырга теләгегез юкмы? Гомумән, сез ничә китап авторы? Саллы хикәяләр язганыгызны да беләбез...

– Төрле җыентыклардан тыш, минем бер генә китабым бар, балалар өчен дүрт пьесаны туплаган «Бәби» китабы ул. 2018 елда Татарстан китап нәшриятында басылды. Китап чыгару шулай ук күп вакыт сорый. «Бәби»не бастырырга нәшрият үзе тәкъдим итте. Башкаларын да чыгарырга теләк белдерүчеләр булса, эшләрбез, Аллаһ теләсә. Ә нәшриятлардан тәкъдим юк икән, димәк, бу беркемгә дә кирәк түгел, дип саныйм. Анда бит үз эшләренең осталары хезмәт итә, кайсы китапка кытлык бар икәнен чамалыйлар, дип уйлыйм.

АЛТЫ АЙЛЫК БАЛАЛАР ӨЧЕН ДӘ СПЕКТАКЛЬЛӘР БАР

– Курчак театры башка драма коллективларыннан нык аерыламы? Бай тарихлы «Әкият» курчак театры ике телдә эшли, репертуар сәясәтендә каршылыкларга очрамыйсызмы?

– Курчак театры, әлбәттә, драма театрыннан аерыла, ул үзгә. Минем өчен бик кызыклы. Эшне оештыру процессы аерылып тора. Техник яктан күпкә авыррак курчак театрында. Алар белән 2016 елдан бирле хезмәттәшлек итәм. Башта Чаллы курчак театрында «Сак-Сок»ны, «Горебогатырь Косометович» (Екатерина II либреттосы буенча) трагикомедиясен куйган идек. Ә ике теллелеккә килгәндә исә, безнең, Аллаһка шөкер, бик дус коллектив, бер-беребезне хөрмәт итеп, ике телгә дә тигез игътибар биреп эшләргә тырышабыз.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ «ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫНА 1934 ЕЛДА НИГЕЗ САЛЫНА. Ул вакытта Беренче дәүләт интернациональ курчак театры дип теркәлә. Театрның беренче директоры, актёры, рәссамы һәм режиссеры – Сергей Мерзляков.
Ә инде 1937 елда театр артистлары Рокыя Хәбибуллина һәм Фуат Таһиров Габдулла Тукай әкияте буенча беренче милли пьеса – «Кәҗә белән Сарык»ны дөньяга чыгара. Нәкъ шул вакытта курчак театры өчен татар милли драматургиясенә нигез салына.
Курчак театрында татар, рус төркемнәре эшли. Бүгенге көндә театрның рус труппасы репертуарында 44, ә татарныкында 22 спектакль күрсәтелә.

Дәүләт тарафыннан курчак театрына менә дигән шартлар тудырылган, шуңа безнең бүлешми, тарткалашмый эшләргә мөмкинлекләребез бар. Коллектив иҗат турында гына уйлап яши.

– Илгиз Газинурович, сез курчак театрына килгәч, биредә өлкәннәр өчен дә тамашалар бермә-бер җанланып китте. Хәтта драма театрлары алынмаган әсәрләрне сәхнәләштерә башладыгыз. Мәсәлән, Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр»е... Тамашачы бик яратып йөри. Хәтта 3-4 тапкыр барып караучылар бар. Катлаулы, куркыныч, өркетә торган әсәргә алынуыгызның сәбәпләре нидә? Татар сәхнәсендә ул тәүге мәртәбә куелды, дип беләм.

– Замана таләпләре шундый. Тәкъдим күп. Шуңа күрә театрлар, үзләренең тар кысаларыннан чыгып, төрле яңалыклар кертергә тырыша. Безнең өлкәннәр өчен куелган репертуарга, билгеле, игътибар зур, шул исәптән матбугат тарафыннан да. Әмма бер әйбер күз уңыннан читтә кала: без репертуарны өлкәннәр ягына гына түгел, бәбиләр ягына таба да киңәйттек, «бәби» спектакльләр, ягъни 6 айлык балалардан башлап карый торган тамашаларыбыз да күп хәзер. Репертуар ике якка таба киңәйде...

Авыр темаларга килгәндә, без «куркыныч» әсәрләрне махсус сайламыйбыз. Без халкыбыз, илебез өчен мөһим мәсьәләләрне күтәргән әсәрләргә алынабыз, чөнки курчак театрының мөмкинлекләре чиксез, без алардан файдаланмый кала алмыйбыз. Драма театрының мөмкинлекләре җитмәгән әсәрләрне без дә куймасак, тагын кем куяр?! Турыдан-туры драма театры репертуарын гына кабатласак, бу беркемгә кызык булмас иде. Башка җирдә карарга мөмкинлек булмаган әсәрләрне тамашачы бездә күрергә тиеш.

Яхшы әсәр өчен яңа сүз, форма яки көчле герой булуы шарт.

– Бу спектакль өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясен дә көткән идек. Бирелмәсә дә, театр өчен файдасы булмый калмагандыр...

– Театрга игътибар күп булды. Моңарчы курчак театрына «керпе-куяннар йөгереп йөри торган театр» итеп кенә караган кешеләрнең фикерләрен үзгәртте, аларга яңалык ачты, минемчә. Театрга җитди карый башладылар. Тамашачыларга, җитәкчеләргә без шуны исбатларга тиеш: курчак – уенчык түгел, җитди сәнгать юнәлеше ул!

– Кызыгыз Гәүһәр, улыгыз Хәйдәр сезнең даими тамашачымы?

– Әйе, алар (әти-әниләре театрда хезмәт иткән башка балалар кебек үк) спектакльләрне репетиция вакытыннан ук карый башлыйлар, үзебез белән башка театрларга да йөриләр, Аллаһка шөкер.

– «Әкият» татар дәүләт театры 90 нчы юбилей сезонын «Камал комедияләре» белән ачты. Ни өчен нәкъ менә Галиәсгар Камалга тукталасы иттегез?

– Минем күптән үзебездә татарча комедия куясы килә иде. Театр юбилеенда театр темасына кагылышлы әсәр булса, аеруча матур булыр, дигән фикерләр белән башладык эшне. «Беренче театр» татар театры барлыкка килгәндә җәмгыятьтәге фикерләрне тасвирласа, «Банкрот» әсәрендә халкыбызның театр җанлы булуы, табигатьтән бирелгән артистлык осталыгы Сираҗетдин аша күрсәтелә, дип уйлыйбыз. Шул театр темасы бу ике пьесаны «Камал комедияләре» спектакленә берләштерде.

– Әлеге сәхнә әсәрендә журналист образын кертеп җибәрүегезнең максаты нидә? Дөресен генә әйткәндә, язучы булып киткән коллегаларыбызда да мондый күренешләрне очраткан юк бит.

– Минем уйлавымча, Г. Камал язган вакытта пьесадагы барлык исемнәр тормыштан алынган булган, халык шуны аңлап көлгән. Бүгенге көндә исә бу – буш исемнәр генә. Ә театр ул бүгенге көн белән яшәргә тиеш. Камал үз әсәрен хәзер куйса, үзе дә геройларын бүгенге шәхесләргә алмаштырыр иде. Шуңа күрә без пьесадагы геройларга, ситуациягә туры китереп, халык арасында популяр замандашларыбызның исемнәрен бирдек. Театрда хезмәт иткән яки театр турында иҗат иткән шәхесләр исемнәрен.

– Ә юбилей сезонында театрда нинди чаралар каралган? Зур гастрольләр оештырыламы? Балаларны нинди әсәрләр белән сөендерергә исәп?

– Юбилей елында безнең рус һәм татар телләрендә 6 премьера, халыкара «Шомбай-фест» курчак театрлары фестивале, «Әкият-lab» лабораториясе планлаштырылган. Шулай ук республикабыз районнарында актив чыгыш ясыйбыз. Россиянең төрле төбәкләрендә фестивальләрдә катнашабыз. Тамашачыларыбызга бүләк буларак, Мәскәүдән Образцов исемендәге курчак театры гастрольләрен үзебездә оештыру белән шөгыльләнәбез. Театр тарихын туплаган китап

әзерлибез. Чаралар бик күп һәм эчтәлекле булыр, дип өметләнәбез.

– Әлеге күптән түгел генә «Татарстан Республикасының театр сәнгатенә зур өлеш керткән һәм күпкырлы иҗади эшчәнлек өчен» Марсель Сәлимҗанов исемендәге премиягә лаек булдыгыз, котлыйбыз! Мондый премияләр иҗатчыга ни дәрәҗәдә мөһим?

– Исемлектә лаеклы кешеләр байтак иде, әле чагыштырмача яңа бүләк булганга, премиягә дәгъва кылучы шәхесләр байтак иде, шуңа күрә мине сайлаганнары өчен бик зур рәхмәт. Бу минем өчен, беренче чиратта, коллегаларым тарафыннан эшемнең уңай бәяләнүе билгесе. Әлбәттә, куаныч, әмма ул зур җаваплылык та өсти. Һәркемгә үз эшенә тиешле бәяне вакытында алырга насыйп булсын.

ТАТАР КИНОСЫ – ЙӨРӘК ЯРАСЫ

– Җәмгыятьтә тотрыксызлык үзен ныграк сиздергән саен, яшь иҗатчыларның тарихтагы исемнәргә, шәхесләргә мөрәҗәгать итүе күзәтелә. («Кави-Сәрвәр», алдарак «Минем Такташ»...) Бу замана таләбеме икән?

– Сез опера жанрында чыккан әсәрләрне санадыгыз. Операга һәрвакыт зур каһарманнар, киң масштаблы вакыйгалар кирәк. Мин моны шуның белән бәйлим, замана белән генә түгел. Әлбәттә, авыр чакларда ниндидер бөек шәхесләр тәҗрибәсенә таянасы килә, аларның хаталарын кабатламас өчен, аларның ачы язмышлары мисалы безне урап узсын дип, боларны искә төшереп торырга кирәктер.

– Илгиз Газинурович, драма әсәренә алынганда, сез үз аудиториягезне күз уңында тотып эш итәсезме?

– Юк, мин аудиторияне түгел, үземне күздә тотам. Мин – биредә туып, гади гаиләдә үскән, гадәти тәрбия алган татар кешесе, башка миллионлаган тамашачыларыбыз кебек үк. Бу куелыш миңа кызык булса, аларга да кызык тоелыр, дип саныйм. Факт, вакыйгаларны тормыштан алып язганга күрә, әсәрең халык күңеленә дә тизрәк барып җитә. Уйлап чыгарып язып булмый. Кемдер, бәлки, фантазиясенә таянып, бик оста яза торгандыр... Гомумән, сәнгать җимне тормыштан чүпли. Әсәрдәге вакыйгалар яшәеш, бүгенге вазгыять белән бәйле булмаса, кызыклы, мавыктыргыч килеп чыкмый, халык күңеленә дә барып җитмәскә мөмкин.

Режиссер үзенә ошаган әсәрне сайлап ала. Фәрит Бикчәнтәев әйтмешли, әгәр дә син сәхнәгә куярга материал сайлагансың икән, димәк, ул синең өчен бүгенге көндә дөньядагы иң даһи, шаһәсәр булырга тиеш. Әсәргә карата шундый мөнәсәбәттә булмасаң, яхшы спектакль чыгарам димә!

«Камал комедияләре» спектакленнән күренеш.

– Тормыштан алынган геройларыгыз соңыннан килеп мөнәсәбәт ачыклаганы, дәгъва белдергәне юкмы?

– Беркайчан да тормыштан турыдан-туры алганым юк. Гел йә берничә кеше язмышын кушасың, яки кыскартасың, әдәбият, театрда вакыйгалар кайнап торырга, каһарманнар күпкырлы булырга тиеш. Үзебезне таныдык диючеләр булгалый, ләкин бу бик сирәк вакытта гына чынбарлыкка тәңгәл килә. Канәгатьсезлек белдергәннәрен хәтерләмим. Бәлки, ошатмаучылар килеп әйтми генәдер, тыныч кына рәнҗеп яталардыр. Ничек кенә булмасын, татарда гайбәт түгел, гыйбрәт булсын, дигән сүз яшәп килә, язучы беренче чиратта шуны күздә тотып эш итә.

– Татар киносы турында да фикерләрегезне беләсе килә. Һушны алырлык чын татар фильмы турында хыялланмыйсызмы? Атаклы кино режиссерлары белән элемтәләрегезне күздә тотып сорыйм...

– Татар киносы барыбызның да бер йөрәк ярасы инде ул. Минем өметем Байбулат Батулла белән Илшат Рәхимбайда. Соңгы эшләре аларның потенциалын ачык күрсәтте, минемчә. Аларның, бер яктан, җитәрлек тәҗрибә туплаган, икенче яктан, әле яшьлек дәрте белән кайнап торган чаклары. Боз кузгалыр, дип уйлыйм.

Үземә килгәндә, минем сценарист сыйфатында кинода эшләп караганым булды. Бу минем өчен кызык. Режиссер буларак та эшләргә хыяллар бар, ләкин моның өчен мин башта, дәүләт акчаларына дәгъва кылмыйча, бу өлкәгә чумып, үз көчемне сынап карар өчен, үзлектән «чирканчык алырга» тиешмен, дип саныйм.

ТАТАРСТАН ХАЛЫКЛАРЫНЫҢ КЫШКЫ КҮҢЕЛ АЧУЛАРЫ

Кышкы салкыннарны җылытырга, карлы айларны күңелле итеп үткәрергә теләүчеләр чана-чаңгыларын, тимераякларын инде әзерләп куйгандыр. Ләкин кышкы уеннар, гореф-гадәтләр чынлыкта чана-чаңгыга гына бәйләнмәгән, алар күбрәк! «Татарстан», республика буенча йөреп чыгып, исемлеккә кызыклы, үзенчәлекле, хәтта ки экстремаль һәм иң мөһиме – милли гореф-гадәтләрне дә өстәде. Әйдәгез,

1. татар **2.** рус **3.** удмурт **4.** чуваш **5.** мари

кышкы уеннары, гореф-гадәтләре белән танышыйк.

татарлар

Фотолар «Татарстан» журналы архивыннан; Лилиана Вәлитовадан

КАЗ ӨМӘСЕ: БОРЫНГЫДАН КИЛГӘН ГАДӘТ

Руфия Фазылова

«Авылларда каз өмәсе гөрли», – дип җырлыйлар. Ата-бабалардан калган әлеге традицияне бүген театрлаштырып үткәрү бик популяр. Кайбер районнарда махсус шундый конкурслар уйлап чыгарганнар: зоналарга бүленеп, авыл мәдәният йортларында каз өмәләре уза. Авылның иң уңган хуҗабикәләре бәйрәмгә каз каклап килә, милли киемдәге егет-кызлар сәхнәдә җырлый, бии... Аннан зона буенча җиңүчеләрне ачыклап, аларны район мәдәният йортына чакыралар. Шул рәвешле төбәкнең иң уңган хуҗабикәсен, иң җор телле коллективын ачыклыйлар.

Быел республика масштабында да шундый бик зур чара узды. Без исә, гадәти бер татар авылына барып, гади бер татар гаиләсендә булып, чын каз өмәсен күреп кайттык.

ҺӘР ЙОРТТА – АНА КАЗ

Яшел Үзән районының Олы Ачасыр авылында яшәүче Кадрия апа Гарәфетдинова ел саен диярлек казлар үстерә. Быел аның унбер үрдәк, унбер казы булган. Башта үрдәкләрен йолкыган, аннан инде чират казларга җиткән. Кадрия апаның ике кызы, килене, ике сеңлесе кайткан иде – унбер казга ничә хатын-кыз!

Кадрия апа бер айлык бәбкәләрне Апастан барып алып кайткан. Ә бит утыз-кырык ел элек кенә халык бәбкәләрне өйдә бастырып чыгара иде, мин дә хәтерлим әле. Көннәр язга таба авышып, җылыта башлауга, өйдә «хуҗа» барлыкка килә – ана каз. Әле ул бер генә дә түгел. Ана каз өйгә кергәч, бала-чагага йөгереп йөрмәскә кушыла: «хуҗа»ны борчымаска кирәк. Ялгыш онытылып китеп, аягыңны карават өстендә тирбәтеп утыра башласаң, «шалт» – ана каз берне эләктереп тә ала.

Кадрия апа да үзенең шундый балачагын бик сагынып искә алды:

– Каз бастыруның тәртибе болай иде: бер оя – өч ана казга бер ата каз калдыралар. Көннәр җылыта башлагач, ата казга аерым тәрбия күрсәтәләр: тәм-томнар бирәләр. Янәсе, шулай йомыркалар аталанган була. Ана каз йомырка өстенә утыргач, игътибар аңа күчә. Шулай итеп, утыз көн дәвамын-

да хуҗабикә могҗиза, ягъни бәбкәләрнең чыкканын көтә. Кыш буе дүрт каз асрау чыгымлы булган инде ул. Шуның өчен кайбер кешеләр ана каз гына калдыралар иде. Ә аннан язга таба ана казын «кунакка» ата казлы йортка илтеп торалар. Әлбәттә инде, хуҗаларны бәхиллләтәләр.

БЕРГӘ-БЕРГӘ КҮҢЕЛЛЕ!

Ике сәгать дигәндә, унбер казның эшен бетерделәр. Һәм ул шундый тиз, күңелле үтте ки, бер мизгел кебек кенә тоелды. Ә Кадрия апа чын хуҗабикәләрчә йөреп кенә торды: «Гүзәл, үтүкләп бетергәч, казның баш-аякларын чистарта тор...», «Гөлназ, кызым, мә, җайлырак итеп утыр әле...», «Эчәсегез килмиме?..»

Кызлар көлешеп, җырлашып эшләде, тик, кызганыч, гармунчылары юк иде. Алдагы елларда Кадрия апа каз өмәсенә гармунчы белән авылның «Зөбәрҗәт» ансамбле хатын-кызларын да чакырган. Быел исә, казлар күп булмагач, әнә шулай үзләре генә эшләргә ният кылганнар. Бала-чаганы, ягъни оныкларны да эшкә җиккәннәр. Әллә ни ярдәм итә алмасалар да, карап, өйрәнеп торсыннар, дигәннәрдер инде.

– Элек каз өмәсен мунчада ясый идек, хәзер менә теплица эченә керәбез, җылы, якты, – диде Кадрия апа. – Заманга яраклашып тагын бер җиңел ысул: казларны үтүклибез генә. Элек безнең әниләр казны йолкыганчы мичкә тыгып ала иде, хәзер алай эшләмибез. Үтүк белән бик җайлы.

– Каз мамыгын нишләтәсез? – дим хуҗабикәгә.

– Җыеп йөриләр, сатабыз да. Быел мендәрләр ясыйм әле. Бөтен иске мендәрне кызлар ташлап бетерде, яңалары кирәк хәзер.

ЫРЫМЫ ШУНДЫЙ...

Каз түшкәләрен көянтәгә асып, кызлар чишмәгә кузгалды. Арттан исә Кадрия апа каз каурыйларын чишмә буена чәчә барды...

– Ырымы шундый, – диде хуҗабикә. – Быел унбер бәбкә сатып алган идем, Аллага шөкер, барысы да үсте. Каурыйларның да «шифасы» тигән дип уйлыйм, су буена чәчкәч, киләсе елга да бәбкәләр була, матур гына үсеп җитәләр дигән ышану бар.

– Авылның башка гаиләләре дә түшкәләрне юарга чишмә буена төшәме? – дим.

– Әйе, без хәтта бозау суйгач та, чишмә буена төшәбез. Электән шулай килгән, эчәгеләрне юып, эшен бетереп кайтасың.

– Элек өйләргә су кермәгән иде, шуңа да бөтен кеше чишмә буена төшкән. Хәзер бит һәр йортта су бар, – дим.

– Булса да төшәбез. Өйдә пычранып ятканчы, чишмә буенда җайлырак. Бездә бит чишмәләр күп, барысын да карап, төзәтеп торалар.

Кадрия апаның Олы Ачасырга килен булып төшкәненә утыз сигез ел тулган. Төп йортта каената һәм каенана белән яшәгән. Ул белгәннән бирле бу нигездә каз асраганнар.

– Соңгы өч елда гына каз алмаган идем, быел менә түзмәдем, – дип дәвам итте хуҗабикә. – Безнең йорт янында гына күл бар, кош-корт асрарга бик рәхәт. Аннары, менә шулай каз өмәләре үткәрү дә күңелле бит. Балалар җыелышып кайта, туган-тумачаны, күршеләрне дә чакырасың. Каз йолкучыларга дип, алдан тәм-томын әзерлисең, бер казны пешерәсең. Гомер буе шулай итәбез. Бер бәйрәм инде, бик күңелле!

...Хатын-кызлар чишмә буеннан кайтканчы табын әзер иде. Иң төп сый – әлбәттә, яңа гына суелган, мичтән чыккан каз. Табын артында уен-көлке, рәхмәт сүзләре ишетелде. Кадрия апаның йөзеннән елмаю китми: каз түшкәләре чоланда эленеп тора (югач суы агып бетсен өчен шулай эшлиләр), балалар җыелган, өйгә тәмле ризык исе таралган. Җылы, рәхәт, авылда гына, әниләр янында гына була торган ләззәтле бер хәят...

ФӘНЗИЛӘ ҖӘҮҺӘРОВА, Татарстанның баш фольклорчысы, филология фәннәре кандидаты:

– Сакланып килгән традицияләр арасында безнең өмәләр системасы бар. Шулар арасында иң популяры, мөгаен, каз өмәседер. Күпләр аны йола дип әйтә. Ләкин бу очракта әлеге сүз бик үк туры килеп бетми, гадәт дисәк, дөресрәк булыр. Исем кушу, килен төшерү – менә алары йола. Гадәт – тотрыклы күренеш түгел. Ул ниндидер шартларга бәйле рәвештә үзгәрүчән була. Ничек кенә тырышсак та, без аны заманга бәйләп куя алмыйбыз.

Һәр заманның үз гадәтләре бар. Мисал өчен: бүген күп авылда июнь аенда уңган хуҗабикәләрнең беренче партия тавык-чебиләре өлгереп җитә. Һәм тавык йолкырга да кеше чакыралар, чөнки аның эшен бер көндә бетерсәң җайлырак. Менә бу – өмәләр традициясе.

Каз өмәләренең хәзер вакыты күчте. 60–70 нче елларда ноябрь башында инде кар ята иде. Каз өмәләре нәкъ шул вакытка туры килде. Ул чорда әйтерсең һава торышы кешеләргә илтифат күрсәткән. Көннәр бер суыткач бүгенге кебек кире җебетми иде. Хәзер климат үзгәрде. Ләкин бүген һәр йортта туңдыргычлар бар, шуңа күрә һава торышына бәйлелек бетте.

Каз татар өчен төп ризыкларның берсе: кыз бирсә дә, зурлап кунак җыйса да, хәтта печән өстенә дип тә махсус каз каклап куйган. Каз – ул кунакка карата булган кадер-хөрмәт, дәрәҗә...

Мин дә яшь чакта каз өмәләрендә күп катнаштым. Без, бишалты кыз, алдан сөйләшенгән исемлек буенча өмәгә йөрдек. Әртил ел саен үзгәрә тора, өлкәнрәк кызлар кияүгә чыгып китә, яшьрәкләр кушыла. Каз йолкуның барлык нечкәлекләрен яңа килгән кызга аңлатасың. Бер казны чистартып, эчен алгач, хуҗабикә каз маенда коймак пешерә тора. Аннан кызларны чәйгә чакыра. Эш беткәч, (казны мунчада йолкыйсы), яңадан өйгә керәсең. Анда инде кайнар шулпа ашыйсың, тәм-томнар белән чәй эчәсең. Аннан түшкәләрне юарга чишмә буена төшәсең. Кичен тагын шул йортка җыеласың. Хуҗабикә каз пешергән, тәмле ризыклар әзерләгән. Уен-көлкеле (кызның йөргән егете булса, ул да килә), күңелле мәҗлес була иде. Безнең Кукмара якларында каз өмәләре хәзер дә уза. Әлбәттә, заман үзгәрү белән табынга чыгарыла торган ризыклар да төрләнә. Ә асылы шул – каз үскән, эше беткән, инде күңелле итеп бәйрәм итсәң дә ярый. Каз өмәләре революциягә кадәр дә булган. Аерма шул гына – халык юрганына карап аягын сузган.

АТЛАРНЫ КУАЛАП...

руслада

Фото: Александр Ефремов

…Кыңгыраулар таккан ат чанасына төялеп, «Татарстан» журналы хәбәрчеләре һәм бу күңелле тамашада катнашучылар урам әйләнде.

Бу хәл узган иске Яңа елда булды. Быел да шулай булыр, чөнки Түбән Кама районының Каенлы авылында шундый традиция яши. Күңелле тамаша урамга гына сыешып бетми: тиздән атлар поселок читенә килеп җиттеләр һәм, кар көртләрен ерып, кырга ук килеп чыктылар. Кайберәүләр (бармак белән төртеп күрсәтмибез) мондый күңел ачуларга бигүк гадәтләнмәгәннәр, шуңа күрә алар ат чанасыннан егылып төшеп тә калдылар…

– Куып тотыгыз! – дип кычкыра дилбегәсен тоткан абзый.

Ат тояклары астыннан очып чыккан вак кар бөртекләре авызга тула, күзне ачарга ирек бирми. Ләкин бу күңелле манзараны көчәйтә генә: чәчәкле-чуклы шәлләрен бөркәнгән ханымнар, йөзләре шатлыктан янып торган балаларның хис-кичерешләрен аңлатып бетереп булмый. Хәзерге технологик заманга ерак үткәннәрдән күчкән үзенчәлекле маҗара – суперкүңел ачу булды бу!

УДМУРТЛАРНЫҢ ПОРТМАСЬКОН ЙОЛАСЫ

Евгения Чеснокова

Караңгы авыл урамнары буйлап бер өйдән икенчесенә сәер затлар йөри – әллә кешеләр, әллә убырлар шунда: эчен тышка әйләндереп толып кигәннәр, башларында – битлек. Таяк белән капка шакыйлар да өйгә керәләр. Кайвакыт бөтенләй дәшмиләр, кайчагында исә сәер тавыш белән җырлыйлар...

Өйдә периметр буйлап йөриләр, таяклары белән идәнгә кагып, атлауларын дәвам итәләр. Хуҗабикә, подноска куеп, конфетлар, коймак, тутырма, үзе куган көмешкә чыгара.

– Сыйланыгыз-сыйланыгыз! – дип ярарга тырыша ул куркыныч кунакларына. – Менә коймак: ничек тиеш, шулай – ботка белән... Менә эчемлектән дә авыз итегез: барыбыз да сәламәт, шат, бәхетле булсын!

Маскарад киеме кигән кунаклар сыйлана. Битлек астыннан йөзләре күренмәгәч, каһәгатьме-юкмы икәнлекләрен һич аңлап булмый. Әмма хуҗалар: «Бөтен почмакка да басып шакыдылар, димәк, ошады бездә», – дип уйлый. Димәк, кунаклар өйдәге бөтен явыз рухны да куып чыгарды, дип сөенергә була...

Күп кенә удмурт авылларында ел саен шулай Портмаськон йоласы үтә. Портмаськон – тагын бер борынгы удмурт йоласы Вожодырның (вожо вакыты, дип тәрҗемә ителә) бер өлеше. Кайчандыр Вожодыр кышкы кояш торгынлыгы көне белән бәйле булган, вожо дигән явыз рухлар, җирдә кешеләрне куркытып, төрле зыян салып йөри, дип саналган. Һәм алар, нәкъ менә көн белән төн тигезләшеп, үзара көрәшә башлаган чакта пәйда булган.

Соңрак исә вожо ел фасыллары алышынган чакта килә торган элгәрләр рухы белән тәңгәллләштерелә башлаган. Киенепясанып куркытып йөрүчеләр нәкъ менә шул башка дөньядан килүчеләрне сурәтли. Яши торган йортны бөтен явызлыктан арындырып, анда сәламәтлек, шатлык һәм бәхет кенә калсын өчен, бу куркыныч кунакларның күңелен күрергә кирәк тә инде.

«КУРКЫНЫЧ» КУНАКЛАР

Караңгы кышкы кичтә Мәскәү янындагы Воскресенскида яшәүче Ольга Кожемякина белән ире утырган машина Татарстанның Әгерҗе районы Варклед-Бодья авылына килеп җитә. Телефоннары тотмый – бернинди элемтә дә юк монда. Карлы урамнарда йортларның кара шәүләләре шәйләнә. Нибары бер тәрәзәдә ут яна, шунда юнәләләр дә...

Фотолар: Ольга Кожемякина, Наталья Матвееваның шәхси архивыннан, «ТР удмуртларының милли-мәдәни автономиясе» ТИУнән

Ун минуттан соң инде алар мул табын түрендә утыра. Күңелле кунаклар арасында авыл клубы мөдире Наталья Матвеева да бар – Кожемякиннар Татарстандагы ерак удмурт авылына нәкъ менә аны эзләп килгән дә инде.

– Бу авыл һәм Наталья турында мин социаль челтәрләрдән белеп алдым, – дип сөйли Ольга. – Мин үзем Удмуртиядә туып-үстем, удмурт кызы һәм халык гореф-гадәтләре белән гел бик кызыксына идем. Шул исәптән Портмаськон йоласы турында да күп ишеттем. Варклед-Бодья авылында әлеге йоланың ел саен үткәрелүен кайдадыр укыгач, клуб мөдиренә яздым, алар исә безне кунакка чакырды. Дөрес, мин карарга һәм фотога төшерергә генә җыенган идем. Таныш түгел кешеләр белән бер табында сыйлануны башыма да китермәдем. Шыпырт кына машинабызда утырып торып, өйдә җыелган кунакларның Портмаськон йоласына керешүен көтмәкче идек. Тик безгә авыз ачарга да ирек бирмәделәр – табынга утыртып, ботка, итле кайнар шулпа белән сыйладылар. Бигрәк тә беренче тапкыр авыз итеп караган канлы иттән тутырма ошады, бик тәмле иде ул!

Ольгага фотограф кына булып калырга язмый – Наталья Матвеева белән йоладашлары аның үзен дә бик сәер һәм ямьсез итеп киендереп тә куя. Никадәр ямьсезрәк һәм куркынычрак булса, шулкадәр яхшырак икән – хуҗалар аларны танымаска тиеш.

Киенеп-ясанып беткәч, күрше йортларның ишеген шакыйлар. Кайберләренә кертәләр, кайсыберләре ишеген ачмый. Керткәннәрендә исә «куркыныч» кунакларны рәхәтләнеп сыйлыйлар. Алар исә бөтен почмакка таяк белән шакып чыгарга тырыша. Ольга Кожемякина шуңа гына хафалана: салкын урамнан җылы өйгә кергәч, камера тирли һәм кадрлар бик үк ачык булып чыкмый. Ә бәлки, шулай яхшырактыр да әле – бу бит сер, борынгы йола, шунлыктан сурәтләрнең бераз томанлы чыгуы гына бер дә зыянлы түгел.

Варклед-Бодья авылында йоланы үтәүчеләр бер сүз дә дәшми, хуҗага тавышларыннан танытмый. Наталья Матвеева әйтүенчә, удмуртлар бик оялчан халык – алар йөзләре ачык килеш болай шукланырга җөрьәт итмәс тә иде, үзләрен танымагач исә, рәхәтләнеп кыланырга була.

БЕЗ ШУЛАЙ ЯШИБЕЗ ИНДЕ...

Наталья Матвеева аңлата: удмуртлар ышануынча, таяклар белән шакып куркытканнан соң, өйдәге бөтен җен-пәри чыгып кача, рәхмәт йөзеннән исә хуҗалар кунакларны сыйлый. Бу нәрсәсе белән дер хеллоуинга охшаган – аны да бит америкалылар түгел, ә борынгы кельтлар уйлап тапкан. Элгәрләрдән калган Портмаськон исә Әгерҗедәге Варклед-Бодьяда гел булган, Наталья балачагында да әлеге йолада бик теләп катнашуын яхшы хәтерли. Әлбәттә инде, ул чакта кызчык барысын да уен дип кенә кабул иткән, бәйрәмнең яшерен мәгънәләрен бөтенләй белмәгән. Шулай да әлеге йола гадәтләре аның күңеленә шулкадәр сеңгән ки, ул удмурт халкын Портмаськоннан башка күз алдына да китерә алмый.

– Без шулай яшибез инде, – дип елмая ул.

– Билгеле, Наталья – клуб мөдире, һәм бәйрәм йолаларын үткәрү аның төп эшедер кебек, – дип сөйли Ольга Кожемякина. – Әмма, беләсезме, эштә янарга да, бернишләмичә генә вакыт үткәрергә дә мөмкин бит. Менә ул янып эшли. Аның өчен халык бәйрәме сакланырга тиешле нәрсә генә түгел, бәлки аның тормышының табигый бер өлеше ул. Бу шулкадәр шәп бит!

Авылны урап чыккан вакытка ишеп кар ява башлый. Һәм үзеңне ниндидер бер параллель дөньяда итеп тоясың. Һәм бу дөнья шулкадәр гүзәл һәм саф ки, чөнки анда җен-убырларга да, явыз кешеләр һәм ниятләргә дә урын юк...

ЭЛГӘРЛӘР ДӨНЬЯСЫНДА

Удмуртлар тормышына христианлык үтеп кергәч, борынгы йолалар Раштуа бәйрәменең бер өлешенә әйләнә. Портмаськонлы һәм багулы Вожодыр хәзер Раштуадан Качману бәйрәменә кадәр – 7 гыйнвардан 19 ына кадәр уздырыла. Бу көннәрдә вожо рухлары кешеләр янына судан килә дип санала, шунлыктан бу атнада мунча керү, кер яки идән юу рөхсәт ителми.

Жуковскийның – Светланасын, Пушкинның Татьянасын исегезгә төшерсәгез, христиан динендә бу көннәрдә багучылык белән шөгыльләнүләрен яхшы хәтерлисездер. Татарстан удмуртлары милли-мәдәни автономиясе идарәсе рәисе ярдәмчесе Ольга Чайникова әйтүенчә, удмуртларда да бу бәйрәмдә багучылык киң таралган, һәм хәзерге яшьләрнең дә киләчәкләренә фал ачтырасы килә икән.

– Без Казандагы удмурт якшәмбе мәктәбе кызлары белән әлеге йолаларны үтәп карадык, алар бик кызык булды, – дип исенә төшерә Ольга Чайникова. – Аларга бигрәк тә шәм һәм су белән багу ошады. Ул болай эшләнә: рухларга сорау бирәсең дә янып торган шәм балавызын суга тамызасың. Шул фигура суда каткач, шуның дивардагы күләгәсеннән соравыңа җавап табасың...

Ольга әйтүенчә, тагын әле авылларда кызлар капка артына киез итек ыргыта: башы кайсы якка күрсәтә – кияү шул яктан киләчәк, имеш. Яисә зур кашыкка су салып тәрәзә төбендә төнгелеккә калдыралар. Иртәнгә кадәр су туңа, һәм ул кытыршы булып туңу никахсыз бала табу ихтималын фаразлый икән.

Соңгы багу, әлбәттә, якшәмбе мәктәбендә укучы кыз балалар өчен түгел әлегә. Әмма үз киләчәгең хакында төрле ысуллар белән хыяллану удмурт балалары өчен мавыктыргыч маҗара да, ата-бабаларының гореф-гадәтләре белән танышу өчен бер файдалы форсат та ул.

БЕР ЕЛГА ҺӘМ ГОМЕРЛЕККӘ БАГУЛАР

Евгения Чеснокова

Кызлар су салынган чан тирәли басалар да, уңайсызланудан кеткелди-кеткелди көлеп, йөзекләрен суга салалар. Аларның берсе чан эчендәге суны кулы белән бөтерчек хасил булырлык итеп болгата, ул арада кызлар туган телләре – чуваш телендә нәрсәдер җырлый.

Һәр җыр дүртьюллыктан гыйбарәт, аның соңгы ике юлы – нindидер юрау булып тора. Әлеге сүзләр әйтелгәндә, суны бөтерүче кемнең йөзеген тартып чыгара, сүз шуңа аталган дип санала.

«СУ ӨСТЕНДӘ МАТУР ЧӘЧӘК БАЛКЫДЫ»

Мәсәлән, бер җыр менә мондыйрак:

Ишек ачылды – киң ачылды.
Су өстендә матур чәчәк балкыды.
Суда матур чәчәк – су яктысы.
Без – ата-ана йорты балкышы.

– Яктылык турында сүз бара икән, бу – багу сораучы өчен бик яхшы билге. Ата-аналар искә алына икән, димәк, гаиләдә яхшы хәбәр булачак, – дип аңлата Аксубай районы Кече Сөнчәле авылының клуб мөдире Вера Уканеева. – Гадәттә, мондый борынгы җырларның беренче ике юлы табигать дөньясына карый, ә калган икесе кеше язмышын юрау буларак карала. Кеше һәм табигать арасында гармония булырга тиеш.

Вера безгә тагын бер җырны тәрҗемә итә, анысы шушы җирлеккә бәйле:

Чуар киез итекләр.
«Ак йоннанмы?» – дип сорыйлар.
Кая гына барсаң да таныйлар:
«Сөнчәленекеләр?!»

Клуб мөдире әйтүенчә, монда багу сораучы оста булачак дигән мәгънә салынган, ул осталыгы белән туган ягыннан читтә дә танылачак. Күргәнебезчә, дүрт юлдан торган торган чуваш җырларын аңлату да – үзенә күрә сәнгать, һәм аңа, бик борынгы заманнардан ук безнең көннәргә килеп җиткән халык бәйрәмнәрендә катнашып, кечкенәдән өйрәнәләр.

Багу – чувашларда кышкы йола-гадәтләрнең мөһим өлеше, Кече Сөнчәледә Кив Сене сул (кайсыдыр башка җирлекләрдә ул чувашларның Сурхури бәйрәме белән кушылып китә) дип аталган бәйрәмнең бер үзенчәлеге. Крестьяннарның төп шөгыле игенчелек һәм терлекчелек булганга, «өйләнәмме-юкмы / кияүгә чыгаммы-юкмы» кебек тапталган темага гына

Фото Вера Уканееваның шәхси архивыннан

түгел, ә уңыш мул көтеләме, киләсе игенчелек сезонында һава торышы уңай киләчәкме, терлекләрдән яхшы үрчем көтәргәме-юкмы икәнен дә багалар.

ЯХШЫ ТОРМЫШКА ӨМЕТЛӘНЕП

Сурхури элек кышкы кояш торгынлыгы көннәрендә бәйрәм ителгән һәм караңгылыкның җиңелүен символлаштырган. Чувашлар христиан динен кабул иткәннән соң, еллык календарь циклындагы тәүге йолалары Раштуа һәм Качмаңу арасындагы изге көннәр дип йөртелгән вакытка күчә. Мәсәлән, Кив Сене сул – Иске яңа ел ул. Совет чорында борынгы бәйрәм йолалары, әлбәттә, хупланмый, әмма авылларда халык барыбер гореф-гадәтләрне сакларга тырыша.

– Әнинең Иске яңа елда чуваш кабартмасы – йавалар пешергәнен, борчак кыздырганын балачактан хәтерлим, – дип искә ала Вера Уканеева. – Балалар шул борчакны кесәгә тутыра да, җырлый-җырлый, такмаклар әйтеп, авыл буйлап өйдән өйгә йөри иде. Авылдашларны куркытыр өчен, малайларның иске туннарны тискәре ягы белән киеп йөргәне дә хәтердә.

Чувашларның мондый коляда җырларын көйләгән балаларны, әлбәттә, бәлешләр һәм конфетлар белән сыйлау гадәткә кергән. Ә кыздырган борчакны чувашлар, бәйрәм белән котлап, бер-берсенең өстенә сибәләр. Йортларга муллык иңсен, уңыш әйбәт булсын өчен анысы.

Яшьләр гадәттә кичләрен берәр өйдә җыела торган булган. Егетләр сыра кайната, кызлар пироглар пешерә, ә аннары югарыда искә алынганча багалар, рәхәтләнеп бииләр, җыр сузалар.

Яңа буыннарга тапшыру өчен, борынгы гадәтләрне актив рәвештә яңадан торгызган хәзерге заманда яшьләрне бәйрәмгә клубларда җыялар. Җырлы йолаларны да бераз үзгәртәләр.

– Борынгы җырларда, – дип аңлата Вера Уканеева, – төрледән-төрле юраулар ишетергә мөмкин. Бервакыт, күптән инде, безнең бәйрәмдә бер әбигә теге дөнья турында сүзләр эләкте. Һәм ул шул елны үлде. Шуннан бирле без андый нәрсә турында җырламыйбыз. Яхшыны гына телисе килә...

ТАВЫКЛАР АШЛЫК ТАШЫГАНМЫ? АКЧАГА!

«Сурхури» сүзе «сарык аягы» дип тәрҗемә ителә. Һәм бу тикмәгә генә түгел.

– Хәтерлим әле, без, кызлар, бәйрәм кичендә караңгы абзарга кереп, сарыклар тота идек, – дип искә ала Буа районының Таковар авылыннан Анна Никанорова, – Карасы эләксә, ирең кара чәчле, агы туры килсә, ирең блондин булачак. Сарык соры йонлы булса, чал кергән, карт иргә чыгачаксың.

Шунысы кызык: иреңнең нинди булачагына багуның бу ысулы турында кайбер чувашлар интернетта болай дип яза: кайчак багучы кыз сарык түгел, кәҗә тота. Нишлисең инде, димәк, ирең дә...

– Сурхури – бик күңелле бәйрәм, – дип дәвам итә Анна Степановна. – Без Яңа елга караганда Сурхурины ныграк көтеп ала идек. Бу көннәрдә бераз тәртипсезләнеп алырга да мөмкин, беркем дә ачуланмый иде.

Тәртипсезлек дигәне, аның әйтүенчә, берәр кешенең капкасына ачылмаслык итеп кар өю яки кемнеңдер чанасын авыл читенә кадәр илтеп кую булган. Тик моны ни өчен эшләгәнлекләрен Анна Никанорова белми. Йоласы шундый!

Әле тагын ишегалдында карга сузылып яткаганнарын да искә төшерә ул, иртән исә гәүдә калдырган эзгә карыйсың. Җил салам алып килеп салса, быел мул тормыш көтмә. Тавыкның ашлык ташып куюы, акча белән барысы да җайланыр, дигәнне аңлата. Ә менә күмер эләксә, анысы бер дә яхшыга түгел – янгын чыгасын көт тә тор...

Яки өйдә тәңкәләр, ашлык, су салынган табакларны идәнгә тезеп куйганнар да бер тавыкны керткәннәр. Әгәр ул акча яки ашлык салынган табак янына килсә, мул тормышка юрала, сулы савытны сайласа, багучыга эчкечелек яный (әгәр кыз кеше бакса, ире исерек була) дигәнне белдерә.

Бу багулар, әлбәттә, еш кына чынга да ашмый, дип көлә Анна Степановна. Хәтта, мөгаен, күп очракта чынга ашмыйдыр. Ул, мәсәлән, кайчандыр киез итеген басу капкасы аркылы ыргыткан (булачак кияүнең кайда яшәгәнен шул рәвешле багу йоласы күп халыкларга, шул исәптән чувашларга да хас), ләкин кияүгә чыгу юнәлеше киез итекнеке белән бер дә туры килмәгән.

Аның каравы мондый йолалар – борынгы гореф-гадәтләрне, халык җыр-биюләрен тагын бер кат искә төшерү, балаларда һәм оныкларда үз милләтенә, ыруына, тарихына тартылу хисен саклау өчен, гореф-гадәтләрне өйрәтүнең яхшы ысулы ул.



марида

ШОРЫКЙОЛ.
МАРИЧА ЯҢА ЕЛ

Дмитрий Сивков

«Ызба вакытлыча – театрга, яшьләр – актерларга, барлык кунаклар тамашачыларга әверелә. Ә костюмнары! Берәү, кулларны тыгарлык итеп, ике яктан киселгән капчык кигән, башында – авыз һәм күзләр өчен тишекләр тишелгән битлек, мыек һәм сакал күмер белән ясалган. Икенчесенең аяк киеменнән башка бернинди киеме дә күренми. Ул салам белән шулкадәр оста уралган ки, өстендә күлмәге бармы-юкмы икәнлеге бөтенләй сизелми. Башкалары тискәре ягына әйләндерелгән тун кигән, бармаклары, битләре шулкадәр буялган ки, күзләренең агы гына күренеп тора».

Казан университетын тәмамлаган танылган этнограф Степан Кузнецов Шорыкйолны шулай тасвирлый. Кичә түгел – XIX гасырда ук. Ике гасыр диярлек вакыт узган, ә бу мари бәйрәме яши, ел саен яңа төсмерләргә байый гына бара. Аның турында күбрәк белергә вакыт.

«ҮРЧЕМ БИР!»

Шорыкйол үзенең хисабын 22 декабрь – Төньяк ярымшарда иң кыска көн һәм иң озын төн булган вакыттан башлый. Бәйрәмнең исеме «сарык аягы» дип тәрҗемә ителә. Тәмләткечләр салып пешерелгән хуш исле сарык итен күз алдына китереп, авыз суларын китерергә ашыкмагыз. Монда сүз сый турында бармый: бәйрәм вакытында марилар, абзарга кереп, «Шорык йол, шочыкто!» – «Сарык аягы, үрчем бир!» дип сөйләнә-сөйләнә, сарыкны аягыннан тарталар икән. Шулай итеп, яңа елда терлекләрнең зур үрчеме «программалаштырыла». Тагын бакчада, карны өемнәре ясап, җимеш агачлары һәм куакларының ботакларын һәм кәүсәләрен дә селкетергә кирәк. Барысы да яңа елда мул уңыш җыю өчен эшләнә.

Шорыкйол, үзенә күрә бер ревизия кебек – хуҗалыкта тәртип урнаштырып, аны киләчәктә иминлек һәм муллыкка әйләндерү гамәле. Ир-атлар үзләренең сунарчылык, балыкчылык кирәк-яракларын, эш коралларын тикшерәләр, хатын-кызлар кул эшләрен урамга чыгарып эләләр, балалар да үз эшләнмәләрен күрсәтәләр. Шулай ук пешеренергә, кыскасы, тәмләп сыйлану

Фото автордан алынды

гадәте дә бар. Бу Васли кува-кугыз (Василий карт һәм аның карчыгы) һәм аларга ияргән киенгән-ясанган затлар белән очрашуга әзерлек тә дигән сүз. Алар алдында узган ел турында хисап тотарга туры киләчәк бит. Хәйләләмәү яхшырак, югыйсә алар сүзеңә ышанмаска, барысын да үзләре санап чыгарга да мөмкин.

ӘЙЛӘНДЕРЕП КИЕЛГӘН ТОЛЫПЛАР ҺӘМ ЯШЕРЕН УРЫНДАГЫ БҮЛӘК

Шорыкйол бәйрәмендә гадәттә авылның олысы-кечесе – барысы да катнаша.

– Балалардан башка бездә бер бәйрәм дә узмый, – ди Кукмара районының Починок-Кучук (Мултан) авыл мәдәният йорты каршындагы «Кна вел» фольклор ансамблендә катнашучы Ирина Родыгина. – Алар үз гореф-гадәтләрен кечкенәдән сеңдереп үсәргә тиеш.

Мариларда буыннан буынга күчүчәнлек традициясе беренче урында тора. Туган тел укытучысы Ирина, мәсәлән, сәхнәгә XIX гасырга караган ике тиенлек көмеш тәңкәләр тезелгән монисто тагып, милли күлмәктән чыга. Әлеге матурлык аңа дәү әнисенең әнисе Ульяна Никифоровна Исаевадан калган мирас.

– Мин Шорыкйолга беренче сыйныфта ук катнаштым, дусларым белән бергә, өйдән өйгә йөри идек, – дип сүзгә кушыла «Кна вел» җитәкчесе һәм авыл мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе Ангелина Ирбулдина. – Хәзерге кебек үк диярлек киенгәннәр: тискәре ягына әйләндерелгән толып, төрле җәнлек битлекләре... Ул вакытта безне беркем дә оештырмый иде, шундый традиция барлыгын белеп, үзебез йөри идек. Үзебезгә кызык һәм күңелле иде. Әлбәттә, ул чакта хәзерге кебек масштаблы тамаша түгел иде. Миңа иң ошаганы – хуҗаларның кунакны сыйлавы түгел, ә бүләкләрне яшерүе. Кайчак аларны табу шактый матавыклы булып чыга.



СӘЕР ЗАТЛАР, ДОГА ҺӘМ БАГУЛАР

Авылда Шорыкйол турында онытa башлаган вакытлар да була тарихта. Әлеге күркәм традицияне җиде ел элек яңартканнар, күпчелек «Кна вел»ның элекке җитәкчесе Леонид Искаков тырышлыгы белән. Леонид Александровичка инде 71 яшь, әмма ул эштән читләшми, коллективта әлегә кадәр гармунчы булып тора. Ул шулай ук Кукмара районы мариларының башлыгы (старейшиналары) санала.

– Үземне белгәннән бирле, Шорыкйолга һәрвакыт карачкы булып киенгән кешеләр, нигездә яшьләр һәм балалар йөрде. Ә әниемнең элеккеге заманда бөтен олы кешеләр дә шулай киенә иде дип сөйләгәне хәтердә, – дип сүзгә кушылды Леонид Искаков. – Без дә бу традицияне яңадан торгыздык. Мултанда гына түгел, ә күрше Княгор, Иске Кенә һәм Чигайка авылларында да. Ә йортларны әйләнеп чыккач, барысы да клубка кич утырырга җыела, башлар алдыннан мин, мари карты буларак, дога укыйм.

Элек бәйрәмдә катнашучылар мари йортларына гына кергәннәр, хәзер татарларга да, русларга да, украиннарга да, хәтта вьетнамнарга да керәләр. Соңгылары безгә яңа елны дүрт тапкыр билгеләп үтү бик ошый, дип шаярталар – марича, гадәти, иске һәм көнчыгыш йолдызнамәсе буенча.

Дөрес, элеккеге еллардагы кебек, һәр йортта да киенгән кешеләрне шатланып каршы алмыйлар, ди мари карты. Элек мондый хуҗаларның ишекләрен карга күмгәннәр. Бүген алай эшләп булмый. Әмма багучылык һаман да кулланыла. Мәсәлән, кияүгә чыкмаган кызлар караңгыда, көтүгә кереп, сарык тоталар. Кайсы сарыкны эләктерәсең, кияү шундый булачак: аксыл яисә кара чәчле, яшьрәк яисә олырак.

– Узган елдан алда олырак, кара сарык эләккән иде, әмма әлегә кадәр кияүдә түгел. Күрәсең, әле вакыт җитмәгән, – дип көлә Ангелина Ирбулдина.

Шорыкйол бәйрәме балалар һәм яшүсмерләр күңел ачу дөньясыннан авыл халкының көнкүрешенә әйләнеп кайта. Күркәм халык традицияләре – алар искерми.

Фотолар: Анна Арахамия, Александр Ефремов. РЕКЛАМА

«СӨЕМБИКӘ»: МАТУРЛЫК КАЯН БАШЛАНА

Милли бизәкле ишекләрне ачып кергәч тә, күз түрдәге тәхеткә төшә. Бер мәл үзеңне патша сараенда дип хис итәсең: түрдә хан кызының зиннәтле баш киеме, күлмәкләре. Әйтерсең лә хәзер нindидер могҗиза булачак...

Ә берничә мизгелдән биредә сине дә хан кызына әйләндерәләр. Тәхеткә утырып, килештереп кенә фотога төшәсең...

«Сөембикә» матурлык салонында әнә шулай тиз генә үзгәрергә мөмкин. Миллилек белән затлылык кушылган урында без дә чибәрләнеп кайттык. Яңа ел җитә бит, күңел могҗизалар көтә...

БАРЫСЫ БЕР ТҮБӘ АСТЫНДА

Баштарак «Туган Авылым»а татар халык ризыкларыннан авыз итәргә йөрсәк, хәзер ул чын милли комплекска әйләнде. Биредә бүген музейлар, никах үзәге, төрле кибетләр эшли, ә балалар өчен ни генә юк! Көз башында исә «Сөембикә» матурлык салоны да ачылды. Ягъни никах, мәҗлесләргә әзерләнгәндә бик җайлы – макияж, чәч ясату барысы да бер җирдә.

– Берничә юнәлештә эшлибез, – диде «Сөембикә» милли матурлык салоны җитәкчесе Алинә Хәмидуллина. – Кәләшләрне никахка әзерлибез. Моны «Туган Авылым»да урнашкан никах үзәге белән берлектә эшлибез. Икенчесе – хәләл юнәлеш. Монысы мөселман кызлары арасында бик популяр. Хәләл ысул белән каш, тырнак ясатырга, чәч буятырга гүзәл затлар бик теләп йөри. Моның өчен бездә бөтен шартлар тудырылган. Өченче юнәлешебез – туристлар белән эшләү. Бүгенге көндә «Туган Авылым» комплексы туристлар саны буенча алдынгы урыннарны били. Һәм килгән һәр кунак «Сөембикә» матурлык салонына экскурсиягә керә. Гид кунакларга Казан ханлыгы чорында татарларның ничек бизәнүләре, киенүләре хакында сөйли. Әлбәттә, ханбикәбез Сөембикәнең гүзәллегенә дә туктала. «Сөембикә» – сөекле кыз дигән мәгънәне аңлата. Чыннан да, ханбикәбезнең исеме җисеменә туры килгән. Экскурсиядән соң хатын-кызларга «Сөембикә» прическасы ясатырга, ә ир-атларга «Туган Батыр» стилендә чәч кистерергә тәкъдим итәбез. Соңыннан исә тәхеткә утырып, патшалар киемендә фотога төшәләр. Кунаклар өчен махсус шундый фотозона ясадык.

ИШЕКЛӘР ҺӘРКЕМ ӨЧЕН АЧЫК!

«Сөембикә» – Казанда беренче милли матурлык салоны. Монда чәчне Су анасыныкы кебек бөдрәләтеп ясарга, ә тырнакны Шүрәленекедәй үстерергә (тик зәвыклы итеп) була. Аңлашыла ки, бу заманга яраклашып «мөгез» чыгару, ләкин нәкъ менә шушы исемнәр халыкны кызыктыра икән, бигрәк тә туристларны. Әлбәттә, чәчне буятып, модалы итеп кистерергә, тырнакларны да күңел теләгәнчә ясатырга мөмкин.

Биредә һәр нәрсә уйланылган, хәтта көзгедә дә: «Матурым, как тебе?» – дип язылган. Әлеге дә баягы, заманга яраклашу: селфи төшәргә яратучылар өчен икән. Көзге каршына килгән гүзәл зат (ир-ат та булырга мөмкин) телефоннан үзен төшереп, якын кешесенә фотоны юллый. Ә текстны язып торасы юк, «Матурым, как тебе?» дигән сорау инде бар.

Милли салонның тагын бер үзенчәлеге – биредә гел татар җырлары яңгырый, аларның да тарихка кереп калганнары: Илһам Шакиров, Таһир Якупов, Әлфия Авзалова кебек легендар җырчыларның тавышларын ишетергә мөмкин.

– Әлбәттә, безгә башка милләт вәкилләре дә килә, – дип дәвам итте Алинә. – Яшьләр, өлкәннәр дә килә, нindидер бүленеш юк. Танылган артистлар да йөри. Безнең ишекләр һәркем өчен ачык!

МАКСАТ БЕЛӘН ЯШӘҮ...

Алинә – КФУның фундаменталь медицина факультеты студенты. Тиздән ул кулына табиб дипломы алачак. Студент кына булуына карамастан, чибәр кызның ничә еллык эш тәҗрибәсе бар: башта репетитор, соңрак матурлык салоны. Эш шунда ки, Алинә бер ел элек Казанның тагын бер урынында «Сөембикә» матурлык үзәге ача. Тәҗрибә туплагач, кыюлыгын җыеп, «Туган Авылым» комплексы җитәкчелегенә мөрәҗәгать итә. «Сөембикә» матурлык үзәге әнә шулай биредә дә эшли башлый.

– Алинә, сиңа мондый кыюлык кайдан килә? Уку белән бергә эшне алып бару бик авыр хезмәт бит, – дим.

– Кечкенәдән кыю идем, һәм янәшәмдә әнием миңа һәрчак көч биреп торды. Беренче сыйныфка укырга кергәндә табиб булачакмын дигән максатым бар иде. Аннары актив укучы булдым. Җиденче сыйныфны тәмамлагач, «Сәләт»кә бардым. Шуннан башланды инде... Республика күләмендә нинди иҗади, интеллектуаль конкурслар бар, барысында да катнаштым. Үзем

кебек актив егет-кызлар белән республика яшьләр форумнарын оештырдык. Парламент дебатларында җиңүләр яуладым. Унтугыз яшемдә республика күләмендә уздырылган «Политзавод» дип аталган иҗтимагый-сәяси проект җиңүчесе булдым. (Әлеге проектның кураторы – ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин.) Шулай ук узган ел «Кадрлар резервы» проекты җиңүчеләре исемлегенә кердем. Саный китсәң бик күп инде... Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләренә барып та, төрле форумнарда проектлар яклап, иң яхшылар рәтендә булдым. Узган ел Президент академиясе оештырган белем форумында катнашып җиңү яуладым. Тагын МГИМО уздырган «Ныклы үсеш» форумында «Медицина – сәламәт тормыш рәвеше» темасына чыгыш ясап, «Иң яхшы тема һәм делегат» исеменә лаек дип табылдым...

Алинәнең максаты – дипломлы кардиолог булу. Быел ул Төркиянең иң яхшы кардиология үзәгендә практика узган. Бер ай буена тәҗрибәле кардиологлар янәшәсендә булып, кан тамырларына стент кертү методына өйрәнгән. Төрекчәне яхшы белгән Алинәне төрекләр бик җылы кабул иткән.

– Нигездә анда инглизчә һәм төрекчә аралаштык, – ди Алинә. – Төрекләр татарларны бик ярата, шуңа күрә миңа андагы табиблар белән эшләү рәхәт булды. Операцияләрнең ничек узганын җентекләп карап, өйрәнеп тордым. Төркиядә кан тамырларына стент кую методы бик популяр.

– Бу юнәлеш бездә ничек? – дим булачак табибка.

– Бездә дә кардиология өлкәсе бик яхшы үсеш алган. Университетта нәкъ быел стент кую методы турында өйрәнәбез. Миңа чит ил тәҗрибәсе дә кызык тоелды, профессионал булу өчен тегесе дә, монысы да кирәк. Хәзер үзем өчен тәгаен беләм – кардиология өлкәсендә үсәсем, шул юнәлештә эшлисем килә.

«САНИТАР ТАЛӘПЛӘР ҮТӘЛЕРГӘ ТИЕШ»

Әле беренче сыйныфта укыганда ук Алинә үз бүлмәсе ишегенә «Баш табиб Хәмидуллина А.» дип язып куя. Әлеге максатына ул акрынлап якынлаша. Бүген инде яңа максат, планнар белән яши.

– Медицина өлкәсендә профессионал буласым һәм «Сөембикә» исеме белән үземнең кардиология үзәкләрен ачасым килә, – ди Алинә. – Алар бөтен Татарстан буенча эшләсен иде. Миңа калса, матурлык салоны белән медицина үзәге бер түбә астында булса, бик уңайлы. Аннары икенче ягы да бар – чисталык. Матурлык салонында да бөтен эш кораллары дезинфекцияләнгән, санитар таләпләргә туры килгән булырга тиеш. Бүген бик күп чирләр бар, ни кызганыч, кешеләр алар турында кайчак үзләре дә белми. Санитар таләпләр үтәлмәгән җирдә тырнак ясату, инъекцияле

процедуралар эшләтү зур ахмаклык. «Сөембикә» салонында без санитар таләпләр үтәлүгә бик җаваплы карыйбыз.

Алинә тагын бер хыялы белән уртаклашты – Татарстанда җитештерелгән чималдан табигый косметика җитештерәсе килә аның.

«ИҢ ЯХШЫЛАРНЫ САЙЛАДЫК»

«Сөембикә» матурлык салоны миллилек белән зәвыкка басым ясый. Моның өчен алар Казанның иң яхшы чәчтарашларын, визажист, башка осталарны җыйганнар. Ләкин аңа карап бәяне арттырмаганнар, уртача тотарга тырышалар. Хакны югары иткәнче, күбрәк кеше белән эшләүне кулай күрәләр.

– Без һәрвакыт люкс косметика белән эшлибез, мәсәлән, тырнак буявы Luxio, ә чәчләр өчен Lebel һәм Greymy брендларын кулланабыз, – диде Алинә. – Тагын төрле ташламалар, акцияләр турында да әйтәсем килә. Мисал өчен, никахны «Туган Авылым» ресторанында үткәрүчеләргә «Сөембикә» салонына 500 сум ташлама каралган. Даими йөрүче клиентлар күбәйде, аларга аерым мөнәсәбәт.

– Ә туристлар «Сөембикә» салонында матурланамы соң? – дим.

– Әйе, тик аңлашыла инде, алар әллә нинди купшы прическалар сорамый, җиңелчә макияж, тырнак ясатырга мөмкиннәр. Ә менә ирегетләр «Туган Батыр»га өстенлек бирә, бик еш шул исемдәге чәч кисү стилен сайлыйлар.

Милли кафе, ресторaннар булган кебек, хәзер Казанның әнә шундый үзенчәлекле матурлык салоны бар. Аның ишеге һәркемгә ачык.

«Татарстан» журналы укучыларын Алинә якынлашып килгән Яңа ел белән котлады. Һәм үзенең ихлас теләкләрен җиткерде:

– Дөньяны матурлык коткара, дигән бер бөек классик. Яңа елда бигрәк тә матур булу кирәк. Хәзер күп оешмаларның корпоративлары башланды, ә «Сөембикә» милли салоны ярдәме белән сез бәйрәмнең ханбикәсе булачаксыз. Монысына һич шикләнмим!

Журнал укучыларына «Татарстан» промокоды белән 500 сум ташлама!

ALGA: КӨЧЛЕ РУХЛЫ КЕШЕЛӘР СТИЛЕ

Оксана Бирюкова

Моннан берничә ел элек Татарстан эшкуары Тимерхан Зыятдинов көндәлек спорт киеменең дә мәдәни һәм тарихи кыйммәтләрне чагылдыра алуы хакындагы идеясен тормышка ашырырга була. Бүген исә инде ALGA брендлы милли кием хәтта республикадан читтә дә бик популяр.

«Татарстан» журналына интервьюсында эшкуар әлеге фикернең ничек башына килүе, аутентик кием җитештерү компаниясенең хәзерге хәле һәм үзен уңышка нәрсә илһамландыруы турында сөйләде.

– Тимерхан, ALGA бренды ничек пәйда булды? Әлеге идеяне тормышка ашыру өчен нинди кыенлыкларны җиңәргә туры килде?

– Мин – дзюдо буенча спорт мастеры, үземнең спорт карьерам тәгәлләнгәч, 2014 елда Европа брендларыннан берсенең спорт киемнәрен Россия территориясендә күпләп сату белән шөгыльләнергә ниятләдем. 2018 елда исә милли кием брендын булдыру фикере башыма килде. Шактый халыкның традицияләрне хөрмәтләвен һәм үз милләте белән горурлануын яхшы аңлаганга, әлеге юнәлешне тәфсилләбрәк өйрәнә башладым. Халыкның дине, теле, әдәбияты, бәйрәмнәре, ризыклары, сәнгате, кием-салымы теләсә кайсы милли мәдәниятнең асылын тәшкил итә. Республикабызда әлеге юнәлешләрнең һәркайсы даими үсештә. Бик күп мәчетләр һәм чиркәүләр төзелә, милли бәйрәмнәр гөрләтеп уздырыла, татар халык ашлары белән рәхәтләнеп сыйланып була, милли сәнгать көннән-көн күбрәк популярлаша. Ә менә милли кыйммәтләрне һәм гореф-гадәтләрне чагылдыра торган кием-салым юнәлешендә ул чакта бернинди тәкъдим дә юк иде. Нәкъ менә шул яңа бренд тудыруга этәргеч булды. Ни өчен шулай атадыгызмы, дисәгез, бусы да бик гади аңлатыла. КВНдагы данлыклы мәзәкне хәтерлисездер: татарларның «артка» дигән сүзе юк, без борылабыз да фәкать алга гына барабыз! Теләсә кайсы эшкуарлыктагы кебек үк, кыенлыклар шактый еш очрый. Һәм бу чакта шунысын аңлау мөһим: теләсә нинди марканы булдыру – бик озакка сузылачак уен ул. Дөньядагы популяр брендларның күпчелегенә инде 30 ел һәм аннан да артыграк.

– Компанияне оештыруда һәм үз җитештерүегезне аякка бастыруда «Эшкуарлык фабрикасы» һәм республика Рәисе нинди роль уйнады?

– Моннан берничә ел элек мин чыннан да «Эшкуарлык фабрикасы»нда катнаштым һәм анда ALGA проектын Татарстан Рәисенә тәкъдим иттем. Рөстәм Нургали улына бик рәхмәтлемен: ата-бабаларыбызныкы кебек тегелгән киемне киеп йөрүнең уңайлы булуын ул үз мисалында күрсәтте.

– Үзегезнең бренд турында берничә сүз әйтегез әле: ул нәрсәсе белән үзенчәлекле, бу тәкъдим ителә торган продукциянең ассортиментында ничек чагыла?

– Баштарак кием тәнне суыктан яки көйдергеч кояштан саклау

* Алга

Фотолар Тимерхан Зыятдинов архивыннан. Реклама

өчен тәгаенләнгән. Узган гасыр уртасына кадәр киемдә логотиплар булмаган. Футболка, худи, спорт костюмы, бейсболка кебек киемнәр пәйда булгач, Көнбатыш эшкуарлары шуны аңлаган: кеше иң нәтиҗәле реклама булып тора – һәм билгеле бер марка белән мавыгу идеясе тарала башлый. Безнең күбебез люкс маркалары исемнәре яки чит телдә язылган логотиплы кием кия һәм, үзе дә сизмичә, Көнбатыш брендларын һәм аларга хас кыйммәтләрне бушлай рекламалый. ALGA бренды киемнәре исә даими камиллеккә омтылган, үз Ватаннарын яраткан көчле рухлы кешеләргә тәгаенләнә. Безнең барлык коллекцияләрдә дә минимализм күзәтелә – бары тик логотип (гел алга бару) һәм республика гербы (кече ватаның белән горурлану) сурәтләнә. Премиаль коллекциядә һәм милли стильдәге костюмнарга исә бернинди аерым билге дә төшерелми.

– Тимерхан, үз балаларыгызның бизнеста булуын теләр идегезме?

– Минем өч кызым һәм бер улым бар. Беренче чиратта мин аларның бәхетле булуын телим – яраткан эшләре белән шөгыльләнсеннәр, күп бала үстерсеннәр һәм гореф-гадәтләрне сакласыннар иде.

– Компанияне нинди юнәлештә үстерергә ниятлисез?

– Хәзер ALGA – Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама һәм Әлмәт сәүдә үзәкләрендәге 10 кибет ул. Аларның берсе – иң затлысы һәм зурысы – Luciano Vita Club (Уң як Болак урамы, 1/51) комплексында бутик-ательe буларак эшли: әзер продукцияне сатабыз, премиаль Европа тукымаларыннан шәхси үлчәмнәр буенча кием тегәбез. Без маркетплейсларда да бар, үзебезнең корпоратив бүлегебез эшли (күпләп сату һәм спорт командалары, төрле оешмалар өчен заказ буенча тегү). Безнең брендка әле нибары биш кенә ел бит, 2024 елда һәр юнәлеш буенча позицияләрне ныгытырга, Уфада кибет һәм Мәскәүдә бутик ачарга җыенабыз.

– Сезне нәрсә илһамландыра һәм яңа 2024 елда уңышка өметләнергә нигез булып тора?

– Спортчы буларак, һәрвакыт Олимпия чемпионы булу турында хыялллана идем. Проектны башлаганда, глобаль максат куйдым: ALGA дөньяның барлык мода башкалаларында иң затлы кибетләрен ачарга тиеш – теләгән һәркем сыйфатлы кием сатып алсын һәм безнең мәдәниятебез белән дә танышсын иде. Менә шул илһамландыра да инде!

МОГҖИЗАГА ЫШАНЫРГА КИРӘК!

Яңа ел – тылсымчы, фея, фәрештәләрнең кызу эш өсте, алар балаларга гына түгел, өлкәннәргә дә иң изге хыялларын тормышка ашырырга ярдәм итә. Әмма әлеге хыял-ниятләр төгәл формалаштырылган, өметкә төрелгән һәм күк канцеляриясенә җибәрелгән булырга тиеш. Иң иҗади мохитләрнең берсе – кино сәнгате вәкилләренең Яңа ел алдыннан теләкләре моңа шәп мисал була ала.

Елена Вальцефер, «ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбе директоры, кино, бала тәрбияләүдәге иң ихлас ысул һәм иң изге хыялы хакында.

– Кино – гаҗәеп дөнья ул. Ул безне, геройларның кичерешләренә чумып, башка галәмнәргә күчерергә; кәефне күтәреп һәм күңелдә рәхәт хатирәләр калдырып көлдерергә һәм сөендерергә яки, киресенчә, тирән хисләр уятып һәм тормыш турында уйланырга мәҗбүр итеп елатырга сәләтле.

Кино, үзебезне танып-белергә һәм рухи байлыгыбызны тирәнәйтергә булышып, күңел өчен чын дәва була ала.

Әмма әлеге дөнья аның үзгә бер жанры – балалар киносыннан башка беркайчан да туп-тулы, бербөтен булмас иде.

Биредә барысы да чып-чын, әмма бер чеметем тылсым, әверелү һәм могҗиза кушмый булмый.

Киләчәк җәмгыятьнең нинди булачагы без, өлкәннәрнең, аны нинди мәгънә белән баетуыбызга бәйле, чөнки бүгенге балалар – тагын бер ун-унбиш елдан соң ил язмышын хәл итәчәк буын бит ул.

Балалар киносы – карарга, аңларга, анализларга өйрәтә торган уникаль инструмент. Бу тәрбиянең шактый үтемле дә, бер үк вакытта бик эчкерсез-ихлас ысулы да булып тора.

Кино мәктәбе директоры сыйфатында минем төп бурычым – нәкъ менә балаларга аңлаешлы контент булдыру, ул фильмны карагач ук онытылмыйча, уйланырга, үзеңне геройлар урынына куеп карарга мәҗбүр итәргә тиеш.

Илебез тарихы, мәдәнияте, идеологиясенә нигезләнгән фильмнар гади хакыйкатьләрне аңлау, тәрбиянең күп кенә бурычларын бик җиңел хәл итү мөмкинлеген бирә.

Хәзер балалар киносының төп проблемасы – өлкәннәрнең аны төшерергә теләмәвендә: чит илдә эшләнгән тулы метражлы мультфильмны күрсәтү һәм шуннан табыш алу күпкә гадирәк һәм арзанрак бит.

Шунлыктан минем хыялым мондыйрак: әфсен-төфсен белән балалар киносы торгызылсын, аны төшерергә сәләтле бай өлкәннәрне үзенә җәлеп итсен һәм моңарчы күрелмәгән, өр-яңа, искиткеч югары дәрәҗәгә ирешсен иде!

Фото: Анна Арахамия. РЕКЛАМА

«ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбенең кыю һәм чыннан да бик иҗади ата-аналары киләсе елга хыял һәм ниятләре хакында

АЛИЯ ПОЛЯКОВА:
– Үземнең сәламәтләндерү проекты турында төшереләчәк фильмымның продюсеры булырга хыялланам. Әлеге проектымда катнашучыларның табигать чаралары ярдәмендә төрле чирләрдән сихәтләнүе хакындагы чын хәлләр исә фильмның нигезен тәшкил итәр иде.

НУРИЯ ЕЛЕСИНА:
– Иң гади һәм шул ук вакытта иң мөһим нәрсәләр турында хыялланам: балалар сәламәт булсын, укуда уңышларга ирешсен һәм һәр көнне үзләре өчен нинди дә булса яңалык ачсын иде. Иҗат хыялларына килгәндә исә, мин инде төрле амплуада – укытучы, полицейский, Убырлы карчык һәм сихерче булып төшсәм дә, беркайчан да сериалда катнашканым һәм чын театр сәхнәсендә уйнаганым булмады. Шунлыктан яңа елда моның тормышка ашуын телим.

ОЛЕГ ПОЛЯКОВ:
– «Робинзоны» сериалының дәвамын төшерүне түземсезлек белән көтәм.

«ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбенең тиңдәшсез һәм талантлы актерлары хыялдагы рольләре, яраткан фильмнары һәм яхшылыкның явызлыкны һәрвакытта да җиңүе хакында

ДАША ПОЛЯКОВА, 17 ЯШЬ:
– Минем ерак киләчәк турындагы фильмда төшәсем килә: вакыйгалар Җирдә барсын, ә мин галәмнән килгән кунак – арктурианлыны уйнасам иде. Минем персонажым бик кызыклы, яхшы күңелле, юморны аңлый торган булсын. Ул нинди дә булса куркыныч, хәвефле гамәл кылсын, әмма ахыры хеппи-энд белән тәмамлансын иде.

ВИКТОРИЯ ПОЛЯКОВА, 14 ЯШЬ:
– Мин зомби йә апокалипсис турында куркыныч яки фантастик фильмда төшәр идем. Мин шаян, күңелле, ярдәмчел төп геройны уйныйм, искиткеч юмор хисе өчен аны кайбер персонажлар яратып та бетерми. Фильмда минем героем, башка кешене коткару өчен, үз гомерен корбан итәргә тиеш.

МАША ПОЛЯКОВА, 11 ЯШЬ:
– Минем әле киләчәк турында зурдан кубып хыялланганым юк. Бүгенге көндә мин дөньяда сугышлар булмавын, кешеләрнең бер-берсе белән талашмавын телим. Шәхсән үзем исә тагын бер тапкыр «Хыял утравы» паркына бару хакында хыялланам. Без җәен әнием белән анда булдык инде, тагын барасым килә. Тагын әле сеңелкәш турында хыялланам. Минем ике апам бар инде, ә минә сеңлем юк әле, шунлыктан минем дә апа буласым килә.

УЛЬЯНА ОСИПЕНКО 9 ЯШЬ:
– Минем ерак киләчәктәге мәктәп турында юмористик фильмда төшәсем килә. Бу моннан 100 елдан соң мәктәпләрнең нинди булачагын күрсәтү өчен кирәк – анда өй эше бирелмәячәк, укытучыны исә ясалма интеллект алыштырачак. Мин төп рольне – иң популяр, акыллы һәм матур кызны уйнаячакмын. Ул һәрвакыт үзенең дусларына ярдәм итәргә әзер. Мәктәптә дә вакытны бик күңелле үткәреп булуны да күрсәтер идек.

РЕГИНА КӘЛИМУЛЛИНА, 9 ЯШЬ:
– Минем хыялымдагы роль – кешеләр һәм роботлар кланнарыннан торган киләчәк турында фантастик фильмдагы кыз. Мин һичшиксез җиңәчәкмен, кешеләрне явызлыктан коткарачакмын, дөнья өр-яңа җете төсмерләргә байып балкыячак. Минем героем бик кыю һәм батыр, аның әле башка явызларга охшамаган һәм аны яратучы дус роботы да бар.

АЛИНӘ НАСЫЙРОВА, 7 ЯШЬ:
– Минем мультфильмда төшәсем килә: янәсе, йокымнан уянам да гадәти булмаган дөньяда төрле мультфильмнар геройлары белән очрашам. Мин кыю һәм батыр булачакмын, чәчәктән чәчәккә сикереп йөриячәкмен һәм Дисней персонажлары белән аралашачакмын.

АЙЗИЛӘ НАСЫЙРОВА, 13 ЯШЬ:
– Минем исә героема әти-әнисен коткару өчен әллә никадәр батырлык эшләргә туры киләчәк фильмда уйныйсым килә. Юлымда кызыклы маҗаралар күп очраса да, минем кыю һәм көчле героем аларның барысында да җиңеп чыгачак.

КАМИЛЛА КУЗНЕЦОВА, 8 ЯШЬ:
– Минем шундый фантастик фильмда төшәсем килә – андагы әкияттәгедәй матур һәм серле урында бөтен агач-куаклар өстән аска таба үсә икән. Мин йөзләгән чәчәктән тегелгән гадәти булмаган костюмлы агент-супергеройны уйнар идем. Аның киеме бөтен кешене таң калдырачак. Минем төп миссиям – бөтен кешене бәхетле итү.



АЛЬМИРА ШӘКУРОВА, 10 ЯШЬ:
– Мин һәрвакыт фантастика, төрле миф һәм легендалар белән мавыгам. Һәм мин яраткан Перси Джексон турындагы фильмнарда боларның барысы да бар. Минем бик кыю, шул ук вакытта бик йомшак күңелле алиһә ролен уйныйсым килә.

АМЕЛИЯ ГАЯЗЕТДИНОВА, 7 ЯШЬ:
– Мин Малефисента роле турында хыялланам, чөнки ул бик күпкырлы. Аңарданазлылык һәм гүзәллек, кыюлык һәм батырлык яраша. Моңа ирешү өчен, мин бик каты тырышачакмын.

МАРИЯ ЧИНИЛКИНА, 11 ЯШЬ:
– Минем фантастика яки дорама жанрларындагы фильмнарда төшәсем килә. Вакыйгалар нинди дә булса тауларда барачак, минем персонажым исә яхшы күңелле, шаян булачак һәм шәһәрне явызлыктан һичшиксез коткарачак.

РУСЛАН КУЗНЕЦОВ, 7 ЯШЬ:
– Мин космоста һәм Җирдә яшәүче супергерой – трансформерлар турындагы фильмда төшәр идем. Мин – Титан исемле, зәңгәр төстәге йөк машинасы. Куркыныч якынлашканда, дошманны җиңәр өчен, ул тиз арада трансформацияләнә. Дусларын коткарыр өчен, Титанга явыз трансформерлар белән сугышырга кирәк. Әлбәттә инде, ул барысын да җиңәчәк!

ИЛЬЯС ШИҺАБИЕВ, 12 ЯШЬ:
– Мин фантастик фильмнар белән мавыгам, чөнки тылсым, моңарчы күрелмәгән мөмкинлекләр һәм нindидер гаҗәеп дөньяга эләгү бик кызык ул. Фильмда вакыйгалар ерак киләчәктә, гадәти булмаган космик кораблар белән ерак галәмдә барачак. Минем героем – үзен теләсә кайсы заманга һәм теләсә кайсы урынга күчерерлек җайланма уйлап тапкан кеше. Ул игелекле, көчле, кыю, дөньяны космик роботлардан коткарырга сәләтле. Ихтимал, бу юлда аңа үзен корбан итәргә дә туры килер.

ГАБРИЭЛЛА САЛӘХЕТДИНОВА, 9 ЯШЬ:
– Фильмдагы вакыйгалар космоста барачак, мин исә галактиканы явызлардан коткарачак геройны уйнаячакмын. Минем героем кыю һәм батыр, чөнки космосны шундый сыйфатларга ия булганда гына буйсындырырга мөмкин.

КАМИЛЛА КӘЛИМУЛЛИНА, 14 ЯШЬ:
– Мин теләсә нинди фильм, дорама, сериалда яки мини-роликта төшәргә сөенеп риза булыр идем, тик анда вакыйгалар бик матур табигатьле илдә, мәсәлән, Корея, Япония, Төркия яки Россиядә барырга тиеш. Героемның уңаймы-тискәреме булуы да мөһим түгел, чөнки һәр персонаж үзенчә кызыклы бит. Минем героемның миссиясе – ниндидер начар гадәтләрне, ямьсез холыкларны күрсәтү, башкалар шуны карап гыйбрәт алырлык булсын иде.



НИКИТА СИДОРЕНКО, 12 ЯШЬ:
– Мин «Дети шпионов 5» фильмында төшү турында хыялланам, анда вакыйгалар киләчәктә, Марстагы станциядә барачак. Мин – Кей Картес исемле агент-шпион, яхшы күңелле һәм гадел, шул ук вакытта кыю, көчле һәм бераз мәзәгрәк. Минем героем OSS агентлыгын (супершпионнар оешмасын) космик пиратлардан коткарырга тиеш. Һәм ул коткарачак та.

ДАНИЭЛЬ ВӘЛИЕВ, 9 ЯШЬ:
– Миңа барыннан да бигрәк Бөек Ватан сугышы турында фильмнар ошый. Мин гомумән хәрби тематика белән кызыксынам. Шунлыктан вакыйгалары Бөек Ватан сугышы чорында барган фильмда төшәсем килә. Герое – легендар Ил-2 самолеты очучысы. Ул кыю һәм куркусыз, көчле һәм игелекле булырга, иптәшләренә уртак дошманны ничек тә тизрәк җиңәргә булышырга тиеш.

ВАЛЕРИЯ ДАНИЛОВА, 8 ЯШЬ:
– Минем су асты дөньясы һәм андагы Русалочка турындагы фильмда төшәсем килә. Шторм вакытында ул дуслары белән ярга чыгарып ташлана, һәм алар барысы да сусызлыктан аңсыз кала башлый. Русалочка үзенең бөтен акылын, зирәклеген эшкә җигеп, башта берәм-берәм бөтен дусларын суга төшерә, аннары үзе дә туган стихиясенә исән-имин әйләнеп кайта.

АДЕЛЬ САДЫЙКОВ, 8 ЯШЬ:
– Минем «Один дома» фильмының яңа версиясендә төшәсем килә. Ул инде мин туганчы ук төшерелгән, тик аны һаман яратып карыйлар. Казанда, ә иң яхшысы безнең өйдә төшерсәләр, ничек шәп булыр иде! Мин инде каракларга нинди капкыннар куясымны да уйладым. Минем героем, Кевин исемле малай, үзенең куркуын җиңә, батырлык күрсәтә, дошманнарын акылга утырта, шул ук вакытта нечкә күңелле булып кала һәм барыбер могҗизага ышана!

редакция кухнясы

КЫТАЙ ПИЛМӘНЕ

Татьяна Вафина

Кытайлар турында быел инде шактый күп язсак та, аларның Яңа ел бәйрәмендәге төп ризыгы хакында да сөйләми кала алмыйбыз. Хәер, ул нәкъ безнеке кебек диярлек – кытайлар да Яңа ел табынына пилмән пешерергә ярата. Тик менә аларның эчлеге генә бүтән, Яңа елны да башка көнне каршы алалар. Әмма мондый вак-төяк кенә безгә чын кытай пилмәне белән сыйланырга һич комачауламаячак, чөнки бу ризык Кытайда кышын бик популяр. Көннәр суыткач, кытай пилмәне – цзяоцзыга ихтыяҗ күпкә арта: аны өйдә дә, ресторанда да, махсус пилмән йортларында ди гаять күп ашыйлар, чөнки бу ризык бик тиз җылыну мөмкинлеге бирә, дип саныйлар. Цзяоцзы белән җылынырга дип, без дә «Китайский дворик» ресторанына керәбез. Анда безне яшь оста Ван Хуэй каршы алды.

БЕЗГӘ КИРӘК

БУЛАЧАК:

Камыр өчен:
- Он – 250 г,
- Су – 150 мл,
- Тоз – тәменчә.

Эчлек өчен:
- Йомырка – 3 данә
- Джусай суганы – 100 г,
- Креветка – 200 г.

ПИЛМӘН БӨГҮ ОСТАСЫ

– Ван бирегә Мәскәүдән килде, – дип таныштыра безне пилмән пешерү остасы белән «Китайский дворик» хуҗасы Аида Демьянова. – Анда ул эшләгән кытай рестораны ябылгач, без аны Казанга, үзебезнең яңа ачылган ресторанбызга чакырдык. Ван бары тик пилмән генә пешерә. Ул аны төрле төстәге камырдан, шул исәптән үтә күренмәледән дә ясый һәм, йә шулпада кайната, йә кыздыра, яисә парда пешерә... Эчлеге төрле булырга мөмкин: ит, тозлы кәбестә, кукуруз, суган, гөмбә, балык, креветка...

Ван камыр баса һәм бүген безне йомыркалы, креветкалы һәм джусай суганлы пилмәне белән сыйлаячагын әйтә.

– Бу бик тәмле! – дип өстәргә ашыга Аида, без нәрсәдер сорап өлгергәнче.

– Йомырканы башта табада болгата-болгата кыздырабыз, – дип шәрехли Ван. – Аннары башка туралган ингредиентларны



Фото: Ната Смирнова

1 Турыйбыз

2 Кушабыз

3 Тоз сибеп болгатабыз

4 Басабыз

5 Әвәлибез

6 Кисәбез

7 Җәябез

8 Тутырабыз

9 Бөгәбез

һәм заказчы теләге буенча төрле-төрле тәмләткечләр өстибез.

Без тиешле булган бөтен тәмләткечләрне дә кушуларын сорадык. Һәм менә инде эчлек әзер, хәзер иң кызыгы башлана. Ван Хуэй эчлекне камыр эченә таякчыклар белән бик оста итеп сала да, әллә нинди безгә таныш булмаган ысул белән пилмән бөгә башлый – симез-симез ярымайлар килеп чыга. Өстәлдә әлеге ярымайларның саны геометрик прогрессиядә арткан арада без пилмән һәм Кытайдагы Яңа ел бәйрәме турында сөйләгәннәрне рәхәтләнеп тыңлыйбыз.

ЯЗГЫ ЗУР КҮЧЕШ

– Кытайлар үз яңа елын Ай календаре буенча каршылый, – дип аңлата безгә Аида. – Шунлыктан әлеге дата ел саен үзгәреп тора. Быел ул 10 февральгә туры килә. Бу – бик әһәмиятле гаилә бәйрәме. Моңа ике атна кала, Кытайда бөтен бизнес диярлек туктала, бөтен транспортка билетлар сатылып беткән була. Һәркем туган йортына кайтырга тырыша. Эш шунда ки, кытайларның күпчелеге өйләреннән ерак-ка китеп эшли. Шунлыктан Көньяк провинциядән өйләренә – Төньякка яки Көнбатышка юнәләләр. Һәм киресенчә. Яңа елны һәркем өендә, якыннары белән каршыларга тиеш. Шунлыктан бу вакыт Чу нюнь – язгы күчеш дип атала.

МИН ДИНАСТИЯСЕНЕҢ ЯҢА ЕЛ МЕНЮСЫ

Яңа елга әзерлек эшләре 15 көн бара һәм фонарьлар бәйрәме белән тәмамлана. Иске елның соңгы көнендә исә бөтен гаилә белән пилмән бөгәләр – мондый күмәк эш гаиләне берләштерә, дип санала. Пилмәннең исеме – цзяоцзы – иске белән яңаның алмашынуын аңлата. Ярымай рәвешендә бөгелгән пилмән исә муллык һәм уңыш символы санала.

Легенда буенча, кытай пилмәнен Көнчыгыш Хань династиясе табибы Чжан Чжунцзин (150–219 еллар) уйлап тапкан – ул сарык ите, борыч һәм салкын тиюдән дәвалый торган кайбер үләннәрне камырга төреп пешергән. Әлеге конвертлар бик тәмле һәм хуш исле булып чыккан, һәм шундый аппетитлы «дару» халык арасында тиз ара-

да популярлашкан. Әмма цзяоцзы менюга традицион Яңа ел ризыгы сыйфатында 1368–1644 елларда хакимлек иткән Мин династиясе чорында гына теркәлгән.

КҮРӘЗӘЛЕ ЭЧЛЕК

Кытай пилмәнендәге эчлекләрнең төрле булуы да тиккә түгел. Аларның һәркайсына билгеле бер мәгънә салынган. Джусай суганлы пилмәне сезгә озын гомер; шиитаке гөмбәсе салынганы – илһам; рапслысы – теләгәнегезгә ирешү; балыклысы – муллык; баллылары (андыйлары да була) гаиләдә бәби тууны юрый.

КЫТАЙЛАР ДА БЕЗГӘ ОХШАГАН

Бүген кытайлар, нәкъ безнең кебек үк, пилмәнгә берәр сюрприз – тимер тәңкә яки йөзек яшерергә мөмкин. Бу да традициягә әйләнгән. Аннары алар да, безнең төсле үк, үзләренең «беренче каналын» карый – анда Яңа ел концертында илнең иң яхшы артистлары һәм, шул исәптән, кытайларның яраткан җырчысы Витас җырлый. Аннан соң күрше һәм туганнарын котларга баралар... Әмма кытайлар өчен Яңа елны бәйрәм итү безнең белән чагыштырганда әһәмиятлерәк. Без аны дуслар белән каршыларга яки кая да булса сәяхәткә чыгып китәргә мөмкин. Кытайда болай була алмый. Алар бары тик гаилә белән генә каршылый. Ел буена күрешмәгәннәр өчен бу – очрашуга менә дигән сәбәп.

МАЙМЫЛЛАР ПАТШАСЫ

– Кытай балаларына безнең Кыш бабай яки Дед Мороз кебек персонаж бүләк китерәме соң?

– Аларның Суню Укун дигән маймыллар патшасы бар. Әлеге алдакчы, хулиган, шук-шаян әдәби персонаж – атаклы «Көнбатышка сәяхәт» романы герое. Тылсымлы таштан туса да, ул акыл иясе дә, бөек сәяхәтче дә. 500 ел яшәү дәверендә 72 тапкыр үзгәреш кичергән һәм үзен даими камилләштерүче бу герой бик популяр – ул мультфильмнарда да, Яңа елга да килә... Тагын ике классик әсәр – «Кызыл тирмәдә күргән төш» һәм «Өч патшалык» геройлары да аңардан калышмый.

ТЫНЫЧЛЫК-САЛМАКЛЫК-УҢАЙЛЫК

Кытайда 31 декабрьдә безнең Яңа елны да билгеләп үтәләр, тик нибары өч көн генә. Бу алар өчен күбрәк яшьләр бәйрәме, шунлыктан һәркемнең дә гаиләдә каршылавы мөһим түгел. Ә менә үзләренең, чын Яңа елын бергәләп бәйрәм итүгә алар ныклап әзерләнә.

Казанда яшәүче кытайлар, әлбәттә, Россиядәге Яңа елны игътибарсыз калдырмый. Безнең белән бергә пилмән дә бөгәләр, тик бездән тизрәк, күп төрлерәк итеп...

АШЧЫ ВАН ХУЭЙДАН КИҢӘШ:
– Кислота-селте балансын саклау өчен, пилмәнгә итне – азрак, яшелчәләрне күбрәк салырга кирәк. Итле эчлекне гөмбә, суүсемнәр, бамбук сабаклары белән тагын да туклыклырак итәргә була.

Гомумән, аларга Казан бик ошый. Алар әйтүенчә, башка шәһәрләр белән чагыштырганда, республикабыз башкаласында тормыш тынычрак, салмаграк, уңайлырак. Шуңа рәхмәт йөзеннән һәм якынлашып килгән Яңа ел хөрмәтенә кытай ашчылары «Татарстан» журналын муллык вә озын гомер юраган пилмән генә түгел, тагын берничә Яңа ел ризыгы – кыздырылган бытбылдык йомыркасы белән пешерелгән сыер ите һәм баллы топинамбур да әзерләп сыйлады.

Барысы да бәйрәмчә һәм бик тәмле булды!

ПИЛМӘН МЕНЮСЫ:
Үзебез татып караган кытай пилмәннәрен сезгә дә тәкъдим итәбез:
- 鸡肉冬笋馅饺子 – тавык итле һәм кышкы бамбук үрентеле пилмән
- 鱼肉韭黄馅饺子 – балыклы һәм хуш исле сары суганлы пилмән
- 香菜馅饺子 – кинзалы пилмән
- 西瓜皮馅饺子 – карбыз кабыклы пилмән
- 番茄鸡蛋馅饺子 – томатлы һәм йомыркалы пилмән
- 韭菜虾仁馅饺子 – креветкалы һәм хуш исле суганлы пилмән
- 炼油红糖蒸饺 – көрән шикәрле, парда пешерелгән пилмән
- 猪肉芹菜饺子 – сыер итле һәм сельдерейлы пилмән
- 开口露馅水饺 – пешерелгән ачык пилмән
- 海带水饺 – диңгез кәбестәле пилмән
- 萝卜木耳陷饺子 – тормалы һәм агач гөмбәле пилмән
- 猪肉豇豆馅饺子 – итле һәм кузаклы фасольле пилмән

ТАТ МЕДИА

Телевизор, вертикаль пылесос, ипи пешерә торган җайланма һәм башка бүләкләр от. Иң зур бүләк – «Шифалы су – Ижминводы» санаториена 2 кешелек юллама!

Бүләкләрне уйнату 2024 елның 8 февралендә узачак.

ЯЗЫЛ

«ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

ҖИБӘР

«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә 2024 елның 22 гыйнварына кадәр җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз!). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

ОТ

Телевизор, вертикаль пылесос, ипи пешерә торган җайланма һәм башка бүләкләр от. Иң зур бүләк – «Шифалы су – Ижминводы» санаториена 2 кешелек юллама!

Әлеге чараны оештыручы, кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны tatmedia.ru. сайтында белә аласыз. Акция 2023 елның 16 ноябреннән 2024 елның 20 мартына кадәр уздырыла. Гаризалар 22.01.2024 кадәр кабул ителә. Реклама. Яшь чикләве 16+. Бүләкләр рәсемдәгедән аерылырга мөмкин.

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Беренче татар марксист әдибе **кем** ул

Китап киштәсендә **нинди** әсәрләр көтә

Нургали Надиев **нинди** мирас калдырган

СССР чорында **нинди** курчаклар белән уйнаганнар

БЕРЕНЧЕ ТАТАР МАРКСИСТ ӘДИБЕ ГАФУР КОЛӘХМӘТОВ

Илдус Заһидуллин

XX гасыр башы татар иҗтимагый хәрәкәтенә хас күренешләрнең берсе – рус әдәбиятын һәм мәдәниятен якын иткән яшьләр арасына революцион фикерләр үтеп керү, социал-демократлар идеологиясе таралу. Казан татар укытучылар мәктәбе шундый радикаль фикерле төркемнең формалашу үзәге булып тора. Гаделлек, тигезлек һәм демократик хокукларга ирешү, социалистик җәмгыять төзү турында хыялланган төркемдә Габделгафур Коләхмәтов та була. Киләчәктә ул беренче татар марксист әдибе буларак танылачак.

БЕЛЕМ ТУПЛАУ

Габделгафур 1881 елның 5 маенда Пенза каласында Юныс һәм Бибигазизә Коләхмәтовлар гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга килә. Бабасы – шәһәрдә сабын, шәм, ислемай, косметика мануфактурасы һәм кибетләр хуҗасы, икенче гильдия сәүдәгәре Мөхәммәтҗан Коләхмәтов. Сәүдәгәрнең вафатыннан соң 3 улына калган мануфактура 1888 елда банкротлыкка чыга. Юныс гаиләсе белән Саратов губернасы Кузнецк өязе Кундель хуторына күченеп китә. Юныс уллары Гафур һәм Габделкаюмны 1894–1897 елларда Нижний Ломов өязе Ятмис авылындагы Хәсән мулла мәдрәсәсендә укыта. Балаларына яхшы белем бирү теләге әти кешене 8–9 кешедән торган гаиләсе белән Казанга күчену карарына китерә. Бу 1897 ел була. Гаилә башлыгы Үтәмешевләрнең сабын кайнату заводына баш мастер булып урнаша.

Гафур, кабул итү имтиханнарын уңышлы тапшырып, 1898 елның августында Казан татар укытучылар мәктәбенә (КТУМ) казна хисабына укый торган төркемгә кабул ителә. Рус телен яхшы белүе аңа бирeдә белем алуны нык җиңеләйтә. Гафур, программадан тыш, рус һәм дөнья әдәбияты классиклары әсәрләрен йотлыгып укый. Этнография, тарих, зоология, педагогика буенча хезмәтләрне өйрәнә.

1902 елның 18 маенда гаиләгә кайгы килә: 53 яшьлек этиләре вафат була. Гаилә турында кайгырту Гафурга кала. Шуңа күрә егет КТУМны тәмамлаганнан соң дары заводына эшкә урнаша. Көздән Дары бистәсендә өч еллык рус-татар мәктәбе мөдире һәм укытучысы итеп билгеләнгәч, Ш. Таһириның йортын мәктәпкә арендага алып, гаиләсен шунда яшәргә күчерә. Гафур Коләхмәтов ир һәм кыз туганнарына һәрвакыт ярдәм итәргә тырышып яши.

РЕВОЛЮЦИОН ЭШЧӘНЛЕК

Г. Коләхмәтов КТУМда Хөсәен Ямашев йогынтысында махсус әдәбият укый һәм марксизм тәгълиматы белән таныша башлый. Алай гына түгел, 1901 елны КТУМ укучыларының социал-демократик түгәрәге чират белән Гафур һәм Х. Ямашев яшәгән йортларда җыела торган була.

1902–1903 елларда большевик С.Н. Гассарның яшерен түгәрәгенә йөри. Түгәрәк утырышлары Коләхмәтовлар фатирында да уздырыла, биредә яшерен әдәбият

Фотолар автордан алынды

та саклана. Гафур большевикларның төрле җыелышларында даими катнаша. 1911 елдан Х. Ямашев оештырган яшьләр түгәрәгенә йөри.

Ул эшчеләр арасында аңлату эшләре һәм яшерен түгәрәк алып бара. 1903 елның җәендә Дары заводы эшчеләренең Аккош күлендә үткәргән сходкасында катнаша. 1904 елны Алафузов заводы эшчеләренең яшерен түгәрәгендә марксистик политэкономиянең төп нигезләреннән берсе булган өстәмә кыйммәт турында доклад сөйли.

Аның сәяси эшчәнлегенең иң югары ноктасы – 1905 елның көзендә Казанда үткәрелгән сәяси митингларда һәм баррикадаларда актив катнашу. Халыкка демократик ирекләр бирү хакында 1905 елның 17 октябрь Манифесты игълан ителгәч, Казанда чуалышлар башлана. 25 яшьлек егет 19 октябрь көнне шәһәр Думасы бинасы янында митингта һәм полицияне коралсызландыруда катнаша, РСДРПның Казан комитеты җитәкчесе Н.И. Демперов җитәкчелегендәге халык милициясенә языла. Коралланган бер төркем революционерлар Казан шәһәр идарәсе бинасында туплана, 21 октябрь көнне, утлы кораллардан атып, хәрбиләргә каршы тора, ләкин көчләр тигез булмау сәбәпле, бирелергә мәҗбүр була. Кулга алынганнар арасында Г. Коләхмәтов та була. Ул 11 тәүлек төрмәдә утырып чыга. Соңрак иптәшләренә, мин шәһәр идарәсенә студентлар янына корал алу һәм восстание күтәрү өчен бардым, дип сөйли. Шушы вакыттан 1913 елга кадәр полициянең яшерен күзәтүенә алына.

Аның эшчәнлегенең мөһим өлешен милләттәшләре арасында марксизм тәгълиматын язма төстә пропагандалау алып тора. 1903 елдан башлап, большевикларның прокламация һәм китапчыкларын татарчага тәрҗемә итүдә, гектографта күпләп бастыруда катнаша. Шул рәвешле татар завод-фабрика эшчеләрен, авыл игенчеләрен һәм Казан укучы яшьләрен самодержавиегә каршы сыйнфый көрәшкә тупларга тырыша.

Беренче инкыйлаб елларында тәрҗемә эше тагын да күбәя. Гафур унлап прокламацияне татарчага тәрҗемә итә. 1905 елның көзендә татар эшчеләре арасында ул тәрҗемә иткән «Соңгы патша» исемле брошюраның һәм крестьяннарны көрәшкә чакырган прокламацияләрнең киң таралуы мәгълүм.

1906 елны «Азат» газетасында аның капиталистларның байлык артыннан куувы һәм, хатын-кызларның завод-фабрикаларга эшкә чыгуы сәбәпле, өй тәрбиясеннән мәхрүм балалар проблемасы хакында «Хатыннар мәсьәләсе», хөкүмәтнең гаскәр тотуга күп акча сарыф итүе турында «Эш юктан» исемле һ.б. публицистик мәкаләләре дөнья күрә, төрле псевдонимнар белән Алафузов һәм Дары заводы эшчеләре тормышына бәйле хәбәрләре урнаштырылып тора. РСДРПның Казан комитеты кушуы буенча Германия, Италия, Испания, Швейцария һәм Австро-Венгрия конституцияләре турында мәкаләләр бастыра.

Гафур Коләхмәтов, илдә революционерларны эзәрлекләү һәм аларны сөргенгә сөрү көчәйгәч, мондый эш алып барудан читләшә.

МИЛЛИ-МӘДӘНИ ТОРМЫШТА КАТНАШУЫ

Коләхмәтовның Казанның милли-мәдәни тормышында үз урыны бар. Ул халык мәгарифен үстерүгә үз өлешен кертә. Үзе эшләгән рус-татар мәктәбен җиһазлар, уку әсбаплары белән тәэмин итә, яңа укучылар җәлеп итүдә каршылык күрсәткән мәхәллә руханилары белән көрәшә һ.б. Гафур һәм аның энесе, шулай ук КТУМны тәмамлаган Габделмәннан, 1907 елның 16–19 май көннәрендә Казанда

Татар зыялылары. Утырганнар (сулдан уңга): Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, басып торалар: Гафур Коләхмәтов һәм аның энесе Каюм Коләхмәтов. Казан, 1912 ел.

татар укытучыларының икенче киңәшмәсендә актив катнаша. 1910 елда Коләхмәтов, үз педагогик тәҗрибәсенә һәм А.И. Гольцбергның методик хезмәтенә таянып, башлангыч мәктәптә арифметика укытуга багышланган «Ысулы тәгълиме хисап» исемле 54 битлек дәреслек бастыра. Педагог 1911–1912 уку елыннан Апанай мәдрәсәсе каршындагы рус сыйныфына укытучы булып күчә.

Аның иҗтимагый эшчәнлегенең тагын бер мөһим юнәлеше – туганнары (апасы Шәмсекамәр, сеңлесе Суфия, энесе Усман) белән бергә спектакльләрдә һәм әдәби-музыкаль кичәләрдә катнашу. 1903 елның көзендә бертуган Исмәгыйль һәм Гариф Габитовлар, беренче чиратта рус уку йортларында укучы татар яшьләрен туплап, атнаның шимбә көнендә җыела башлыйлар. Коләхмәтов З. Бигиевнең «Зур гөнаһлар» романын тикшерүгә багышланган утырышта Ф. Әмирхан һәм Г. Камал белән якыннан таныша. «Шимбәчеләр» (Гафур Коләхмәтов, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, реаль училище укучылары Мулланур Вахитов, Рәхим Тенишев, курсисткалар Әминә һәм Мәдинә Терегуловалар, Суфия һәм Заһидә Әхмәровалар һ.б.) 1904 елның гыйнварында Рабига Габитова фатирында төрек драматургы Нәмык Кәмалның Г. Камал тәрҗемәсендәге «Кызганыч бала» драмасын сәхнәләштерә. Татар театр тарихына бу тамаша һәвәскәрләр куйган беренче татар спектакле булып кереп кала. Ял көннәрендә Габитовлар һәм Алкиннар фатирларында Гафур һәм аның апасы Шәмсекамәр катнашында һәвәскәрләр тарафыннан Г.Ильясинның «Бичара кыз», Г.Камалның «Кызганыч бала», «Гашыйк бәласе» драмалары һәм А.Н. Островский пьесалары русча сәхнәгә куела.

1906 елның 22 декабре татар театрының туу көне буларак билгеләп үтелә. Бу көнне «Новый клуб» бинасында КТУМның ярлы укучылары файдасына беренче тапкыр рәсми спектакльләр (билет сатып) – «Кызганыч бала» һәм «Гыйшык бәласе» пьесалары куела. Артистлар арасында Гафур һәм аның сеңлесе Суфия дә була. 1908 елның март аенда Гафур «Яшьләр труппасы» составында Г. Камалның «Бәхетсез егет» спектаклендә Кәрим бай ролен уйный.

1908 елның көзендә Г. Тукай, Г. Камал, Г. Коләхмәтов, С. Рахманколый, «Болгар» номерларында татар артистлары белән очрашып, яңа оешкан труппага «Сәйяр» исеме бирәләр, артистларның иҗатын үстерү хакында сөйләшәләр.

1909 елның яз-җәй айларында, 1913 елның ноябрендә Гафур, Алафузов заводы идарәсе белән сөйләшеп, эшчеләр өчен «Сәйяр» труппасы спектакльләрен оештыра.

Коләхмәтовның «Шәрык клубы»ндагы эшчәнлеген тагын бер мөһим юнәлеш дип билгеләргә мөмкин. Ул «Шәрык клубы» старшиналары советына сайлана. Әмма, «Шәрык клубы» кәеф-сафа урынына әйләнде дип, протест йөзеннән 1909 елның 12 гыйнварында клуб идарәсеннән һәм әгъзалыктан чыга. Ә 1910 елның февраль-март айларында, «Шәрык клубы»н кабат мәдәни-агарту үзәгенә әверелдерү максатында, Г. Камал белән бергә оешмага әйләнеп кайта, аның идарәсе эшендә актив катнаша башлый. Шуңа күрә 1911 елның 20 декабрендә «Шәрык клубы»ның гомуми җыелышында, Г. Камал һәм Г. Терегулов белән берлектә, оешманың идарәсенә сайлана. 1912 елны Гафур Коләхмәтов җитәкчелегендәге һәм Ш. Әхмәров вә Ә.-Г. Хәсәни катнашындагы зәвык кичәләре комиссиясе тәкъдиме белән, клубка халыкны тарту, ешрак спектакльләр кую максатыннан, «Сәйяр» труппасы артистлары белән ике арада килешү төзелә. Гафур Коләхмәтов труппаның репертуарын яхшыртуга һәм артистларның матди хәлен кайгыртуга зур көч куя. Бу сезонда ул 25 мәртәбә идарә утырышында катнаша. 1914 елны кабат «Шәрык клубы» идарәсенә сайлана.

Гафур Коләхмәтов татар матбугатында милли мәсьәләләр турында язмалар да бастыра. «Казан мөхбире»ндә, милләттәшләренең кызларын укытудан куркулары, укыган кызларын надан, белемсез, ләкин бай егетләргә кияүгә бирүләре, яки, киресенчә, белемле улларын надан кызга өйләндерү кебек киң таралган күренешкә, тигез мәхәббәт белән кавышуларның юк дәрәҗәсендә булуына борчылуын белдереп, мәкалә нәшер итә. Ул «Татарин-театрал» псевдонимы белән рус газеталарында кайбер татар театр тамашалары һәм аерым әсәрләр турында бәяләмәләр дә бастырып килә. Ләкин 1912 елдан вакытлы матбугатта бөтенләй күренми башлый.

МАРКСИСТИК ӘДӘБИЯТ ҮРНӘГЕ

Гафур Коләхмәтов әтисе вафатыннан соң һәрчак акчасызлыктан интегеп яши.

1905 елның маенда туберкулез авыруыннан дәвалану өчен пособие сорап, Казан шәһәре һәм өязе халык училищелары инспекторына мөрәҗәгать итә. Җәй көне Урал ягына кымыз эчеп дәваланырга бара. 1906 елны «Ике фикер» драмасын язуы да авыруыннан дәва эзләү өчен акча кирәклектән була. Әйтергә кирәк, ул вакытта татар театр труппаларында яңа сәхнә әсәрләренә зур кытлык күзәтелә. «Ике фикер» драмасы беренче тапкыр «Г. Коләхмәтов мәҗмугасы»нда (Мәскәү, 1925) Ф. Агиев төзәтмәләре белән нәшер ителә.

Гафур Коләхмәтовның иҗаты зур түгел. 12 ел эчендә язганнары дүрт драма әсәре, берничә хикәя белән чикләнә.

Автор үзен пролетариат әдәбиятына нигез салган М. Горькийның шәкерте дип саный. 1908 елда Казанда Әхмәтгәрәй Хәсәнинең «Гасыр» нәшриятында басылып чыккан «Яшь гомер» драмасының титул битендә автор нәкъ шул хакта искәртә. Драма хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсенә багышланган. Әсәрдә татар әдәбиятында беренче булып революцион эшчеләр образы гәүдәләндерелә. Ләкин 1909 елның башында цензор В. Смирнов «Яшь гомер» драмасын, эшчеләрдә байлар сыйныфына карата дошманлык уятуда гаепләп, сәхнәгә куюны тыя. Пьеса 1917 елның Февраль инкыйлабыннан соң гына сәхнәгә менә.

«Ике фикер» XX гасыр башы татар әдәбиятында шартлы образлылыгы белән үк аерылып тора. Төп герой Давыт Кара һәм Кызыл фикерләр көрәше дөньясында яши. Ул үзенә хакыйкать юлы эзли. Кара фикер властьны югары күтәрә, кешене кол дип карый; Кызыл фикер кешене зурлый, аның көченә ышана – шуның белән Давытны үзенә җәлеп итә. Шул рәвешле, әсәрдә көрәш юлын сайлау проблемасы күтәрелә.

Коләхмәтовның «Ике фикер» һәм «Яшь гомер» әсәрләре, марксистик әдәбият үрнәге буларак, ТАССРда татар мәктәпләренең укыту программаларына кертелә.

Гафур, тарихи әдәбиятны, хәдисләрне һәм Коръәнне өйрәнеп, «Әбүҗәһил» исемле дүрт пәрдәле драма яза (1908). Әсәрдә Мәдинәгә күченгән Мөхәммәд пәйгамбәрнең ислам динен тарату өчен Мәккә мөшрикләре (мәҗүсиләр) арасында көрәш алып баруы, Әбүл Хәким ибне Һишам (Әбүҗәһил, гарәпчә: наданлык атасы) пәйгамбәргә каршы көрәшүе сурәтләнә. Ул 623 елны Бәдр сугышында үтерелә һәм коега ташлана. Галимнәр Мөхәммәд пәйгамбәр һәм Әбүҗәһил арасындагы көрәш вакыйгалары аша автор сыйнфый көрәшне сурәтләргә омтылган дип саный. Ләкин бу әсәр совет елларында да бастырылмый кала.

Гафур Коләхмәтовның 1912 елга кадәр «Кем гаепле» исемле, бүгенгәчә табылмаган биш пәрдәлек драма язганы билгеле.

1911 елны авторның «Ник уйгандым?» исемле динчеләргә каршы юнәлтелгән сатирик хикәясе дөнья күрә. Автор Габдеррәзак исемле мулланың кылган гөнаһлары өчен кыямәт көнендә тәмугка эләгүен тасвирлый; утта янудан котылып калгач, оҗмахка эләгүен, иң кызык җирдә йокысыннан уянып китүен бәян итә.

Коләхмәтов әдәбиятта рус телен дә иҗат теле буларак иркен файдалана. Әйтик, 1913 елның мартында татар һөнәрчеләре тормышыннан хатыннарның ирләреннән изелүе хакында «Развод» хикәясен яза.

«Сабах» китапханәсе белән килешеп, кешелек җәмгыятенең үсеш закончалыкларын беренче тапкыр татар телендә марксистик тәгълиматка таянып аңлаткан фәнни-популяр китапчыклар язарга алына. «Тарихтан әүвәл адәм балалары» (1908, 32 бит), «Әүвәлге мәмләкәтләрнең урыннары һәм халык» (1910, 16 бит), «Мисыр» (1910, 44 бит) исемле китапларны фәнни хезмәтләргә таянып яза.

1905 елдан башлап Коләхмәтов һәр җәйне диярлек туберкулездан дәваланырга Уфа ягына, Кырымга, Кавказга йөри башлый. Әмма бу вакытта әле бу чиргә дәва билгеле булмый. 1915 елны авыруы көчәя, ул 1916 елның февралендә Ялтага дәваланырга китә. Аннан табиб белеме алган сеңлесе Суфия һәм кияве Фәхрелислам Агиев яшәгән Пенза губернасы Юнә авылына килә. Укытуын туктатырга мәҗбүр була. 1917 елны кабат Ялтага барып дәвалана. Шул елның октябрь аенда Пенза губернасыннан Милләт мәҗлесенә депутат итеп сайлана, ләкин салкын тидереп, каты авыру сәбәпле, Уфага бармый кала.

Гафур Коләхмәтов 1918 елның 1 апрелендә Пенза губернасы Краснослободск өяз хастаханәсендә үпкә авыруыннан үлә. Җәсәде Юнә авылы зиратында дәфен кылына.

Гафур Коләхмәтовның күптармаклы эшчәнлеге тулысы белән татар халкы язмышын, милләт хәлен кайгыртуга багышлана. Татар театрын тудыруга, халык мәгарифен һәм мәдәниятен үстерүгә юнәлтелгән эш-гамәлләре хөрмәткә лаек. Ике тел – рус һәм татар телләрендә иркен язган егет милләтнең иҗтимагый аңын үзгәртү максатында әдәби, публицистик әсәрләр язып, тәрҗемәләр эшләп, татар дөньясындагы аерым күренешләрне рус телле матбугатта яктыртып, протест чараларында катнашып, авыр хәлгә тарыган кавемдәшләренә хезмәт итә. Гафур Коләхмәтов исеме халык язмышын үзенеке итеп яшәве белән татар тарихына кереп кала.

Гафур Коләхмәтов (сулдан дүртенче) һәм Газиз Гобәйдуллин (сулдан икенче) дуслары белән. 1913 ел.

«МИН АҢА «ЮК» ДИП ӘЙТӘ АЛМЫЙМ...»

Луиза Янсуар

Кайбер китаплар белән язучыларны, «боларны укымый калырга ярамый» дигән исемлеккә кертеп, киң җәмәгатьчелек урыннарында табличкалар элеп чыгарга кирәк. Чөнки аларның әсәрләре аша без тормышны тагын да ныграк кадерләргә, кешеләрне кичерергә һәм яратырга өйрәнәбез. Бу яратудан һәм кичерүдән башка Җир йөзендә берни дә булмас, корымланган калалар вә чүлләр генә торып калыр иде. Җир харап булмасын, ә чәчәк атсын, яшәсен өчен, безнең күңелләрне сугара алган искиткеч бер авторның иҗаты белән уртаклашасы килә бу юлы...

«ТОРМЫШ МИНЕ БЕР НӘРСӘГӘ ТӨГӘЛ ӨЙРӘТТЕ: ИГЕ-ЧИГЕ БУЛМАГАН ЯВЫЗЛЫК БАР УЛ ДӨНЬЯДА, ӘММА АНЫҢ БЕЛӘН БЕРГӘ, КУЛГА-КУЛ ТОТЫНЫШЫП, НАЗ ДА АТЛЫЙ... ҺӘМ СИН, ШУЛ НАЗГА СЫЕНЫП, ЯШИ АЛМАСТАЙ ЧАКТА ДА ЯШИСЕҢ».

Жан-Батист Андреа

Фотолар: polyandria.ru, bookmate.ru, goodfon.ru, livelib.ru

Жан-Батист Андреа – француз язучысы, сценаристы һәм режиссёры. 1971 елда Сен-Жермен-ан-Ле җирлегендә туа, балачак һәм үсмер елларын Канны шәһәрендә уздыра. Нәкъ менә Канныда беренче кино төшерү тәҗрибәләренә керешә – кыска метрда үзен сынап карый. Аннан Парижга юнәлә һәм югары белем ала: Парижның Сәяси тикшеренүләр институты белән Югары коммерция мәктәбен тәмамлый, политология һәм экономика буенча белгеч булып ирешә.

2003–2013 елларда режиссёр сыйфатында 3 кыска метрлы фильм чыгара – «Тупик» (2003), «Полный облом» (2006), «Братство слез» (2013). Дебют романы – «Моя королева» 2017 елда басыла һәм бер-бер артлы 12 әдәби бүләккә ия була. «Сто миллионов лет и один день» романын шулай ук бик җылы кабул итәләр. 2023 елда «Поляндрия» нәшрияты рус укучысына язучының өченче әсәрен – «Дьяволы и святые» китабын бүләк итте.

2023 елда Жан-Батист Андреа атаклы Гонкур премиясенә лаек дип табылды.

Жан-Батист Андреа исеме азмы-күпме рус укучысына моңарчы ук билгеле булса да, статистикага караганда, Гонкур премиясеннән соң аның рус телендәге укучылары саны күзгә күренеп арткан. Андреа романнарына һәрчак үзенә бертөрле җемелдәвек серле нурлар белән өретелгән сагыш, моңсу тиенкылык, затлы эстетика белән поэтик тирәнлек хас. «Дьяволы и святые» бу җәһәттән аеруча игътибарга лаек. Биредә язучы сюжетны да гаҗәеп нечкәлек, бер үк вакытта гадилек һәм тирәнлек белән кора, текст тыгыз булуга карамастан, укучыга фантазиясе өчен һава да калдыра.

Китапны инде аннотациясенә күз төшерүгә үк сатып аласы килә. Ул шунда ук йөрәкне алгысыта, ымсындыра.

Джо – вокзал белән аэропортларда виртуозларча Бетховенны уйный торган карт. Һәр көнне, ниндидер күзгә күренмәс көч тартып китергәндәй, битараф сәфәр кылучылар, үтеп-сүтеп йөрүчеләр төркеме арасында уйнавын дәвам итә ул. Әйтерсең, кемнедер көтә.

Тик кемне?

Нигә аның уены газап һәм наз тулы?

Ярты гасыр элек ни булган язмышында? Нигә ул һаман да уйнаудан туктый алмый?

Балачагыңны гаделсезлек белән шәфкатьсезлеккә күмеп, тамугка әйләндереп мәсхәрәләүчеләрне ничек кичереп була?

Һәм шуннан соң да ничек – ышанырга, өмет сакларга, яратырга?

Бу китап җимерелгән язмышлар һәм таптапган балачак, дөньяның катлы-катлы сүрүләре, югалту һәм гафу итү, музыка, әрнү белән газап аша туган иҗат көче турында.

Без аның белән нәкъ менә дөнья аэропортларының берсендә – музыкаль инструмент артында очрашабыз. Монда берәү дә аның уенын көтми һәм әллә ни теләми дә шикелле. Әмма ул уйный. Ул инде 50 ел буе менә шулай уйный – гадәттә, Лион вокзалында, Орли, Руассида.

Әсәр башында без Андреа каһарманының күз алдыннан меңәрләп узган кешеләрдән берәү – таныш түгел ханым белән эчке монологын тыңлыйбыз. Имештер, бу ханым аңардан сорый: «Мондый талант белән сез нигә зур вә мәртәбәле концерт залларында уйнамыйсыз?» Тик картлач Джо көлә генә: «Минме уйнамыйм? Бөтен дөнья – олы бер концерт залы түгелмени?!» «Әмма сез даһи башкаручы була алыр идегез...» – дип фаразлый ханым. «Юк, – ди Джо герое җавапка, – миңа акчалар да кирәк түгел, сезнең игътибарыгыз да...». Ул хәтта үзенең ничек картайганын да абайламый калуын искәртә... Без бу геройның тормышын белми кала алмавыбызны әнә шул әсәрнең беренче битеннән үк тоябыз.

Бар да мин авыргач башланды.
Бу инде терелә торган авыру түгел иде.
Тик шикләнмәгез – йогышлы түгел бу авыру.
Ул мине 1969 елның маенда аяктан екты.

Һәм минем монда бер гаебем дә юк иде. Аның белән чирләгән һәркем сезгә шулай әйтер.

Бу авыруның исемен медицина энциклопедияләреннән дә эзләп табып булмый.

Ә кызганыч.

1969 елның маенда 16 яшьлек япь-яшь егет әти-әнисен, кечкенә сеңлесен, ягъни бөтен гаиләсен бер көндә югалта – алар самолетта очканда катастрофага эләгеп һәлак була. Үсмерне Пиреней таулары арасында, атаклы Лурдтан ерак түгел генә урнашкан «На границе» дип аталган дини интернатка илтеп тапшыралар. Әнә шул көннән Джоның балачагы чәлпәрәмә килә.

Имин һәм мул киләчәге, әтисе бизнесына варис булып калачагы инде язылып куелган һәм моңарчы бер кайгысы да булмаган бу нечкә тоемлаучы яшь егетнең мондый шартларга җиңел генә иялләшә алмаячагы аңлашыла, билгеле. Башка берни дә уен-көлке, шаярулар, музыка дәресләре, укытучысы Ротенберг белән әңгәмәләр, «Роллинг Стоунз» пластинкалары... Әмма монысы әле иң куркынычы түгел, иң куркынычы – интернатны куркудан дер селкетеп һәм үзенә табындырып торган аббат Арман Сенак белән аның кансыз күзәтүчесе Лягух. Биредә балаларны һәм үсмерләрне кыйнап, җәзалап кына калмыйлар, ә психологик җәфаларга да дучар итәләр. Иң яман җәза – «Онытылу» дип аталган җир асты карцеры. Анда эләккән һәм атналар, айлар буе дөм караңгыда утырып чыккан бала инде элеккеге булып кайтмый, ә кайберләре кешелек сыйфатларын бөтенләй югалта. Аббат Сенак аерым сайлап алынган буйсынмаучылар белән якынайту-ерагайту, җәфалау уеннарын зур осталык һәм нечкәлек белән башкарырга ярата...

Биш яшьтән алып унҗиде яшькә кадәрге 43 бала. Һәрберсенең – үз фаҗигасе. Менә алҗирлы Момо, ул кулыннан йомшак уенчыгын – ишәген ычкындырмый, шуның белән ашый да, йоклый да, хәтта бәдрәфкә дә йөри. Бәлки, аңарда аутизм чаткылары да бардыр, анысын автор артык тәгаенләп тормый, булса да, биредә бу хакта әллә ни уйланмаслар иде. Интернатка Джо белән бер көнне бер машинада китереп ташланган Момо, мөлдерәмә күзләрен тутырып карап, бер сүз дә эндәшмичә шулай яши бирә. Джо аның турында: «Ул минем күз яшьләремә әверелде, ә мин – аның тавышына...» – ди. Чөнки интернатта күз яшен күрсәтергә берәү дә ашыкмый, ә менә «дивана» Момо һәммәсе өчен дә үртәлеп-үрсәләнеп елый ала... Тугыз яшьлек Безродный кушаматлы малай – аның иң төп хыялы Мэри Поппинс турындагы тарихның азагын белү. Әнисе чираттагы бер ир-ат белән яшәгәндә, очраклы гына кинотеатрга барып эләккән һәм бәхетеннән җиде кат күккә ашардай булган бу сабый төп хәсрәте турында сөйләми. Гәрчә, төп травмасы – нәкъ әнә шул кино сеансында килеп чыккан, аны ятим иткән фаҗига булса да... Юк, ул ниндидер могҗиза булып, шул киноның азагын карап бетерергә омтыла, аны караса, бар да җайланасына ышана. Сенегал малае Эдисон – биредә җыелган дуслар өчен радио ясап биргән «даһи». Аны көн дә мыскыл итәләр, түбәнсетәләр, тик Эдисон түзә, ул үз сәгате килеренә өметләнеп яши. Йә тагын берсе – Синатра. Аның кушаматы өлкәнрәк малайлар өчен – чын табыш, атаклы җырчы исемен йөрткән бу «килмешәк»не нинди генә җәзалар аша уздырмыйлар. Әмма Синатра үзенең чыннан да Фрэнкның улы булуына, аны кайчан да булса ак лимузинда (ярый, кара булса, тагын да шәбрәк, керләнми!) әтисе килеп алырына чын йөрәктән ышанып яши. Әтисенә бары тик тиешле анализлар гына ясатырга кирәк, аны шул гына тоткарлый...

Әти-әниләреннән, гаиләдән мәхрүм калу газабын уйларга аларның вакыты да, мөмкинлеге дә юк – биредә, интернатта, алар һәр мизгел уяу булырга тиеш. Югыйсә, вак кына нәрсәнең дә кыйналу, җәфалау һәм мыскыл итүгә әверелүе бик ихтимал. Әмма, хәлләре ничек кенә аяныч булмасын, балалар барыбер балалар булып кала. Кечкенә генә куаныч бөртеген дә күтәреп ала.

Тора-бара Джо биредә яшәүче берничә малай белән дуслашып китә, алар качып очрашу урыны табалар, «Дозор» дигән яше-

рен оешма оештыралар, үз куллары белән ясаган радиодан тапшырулар тыңлап юаналар, качу турында уйлыйлар, әмма качарга көчләре дә, рухлары да җитмәвен бик яхшы аңлыйлар. Интернатны 3 елга бер яр буеннан килгән циклон каплаган төндә, түбә читенә чыгып басып, бергәләп бөтен әрнүләрен һәм үзләрен тилмертүчеләргә карата булган ачуларын, каргышларын җилгә кычкыралар.

Миңа шундый төш керде: имештер, монда бөтенесе дә йоп-йомшакка әверелгән. Диварлар, баскычлар... Аларга килеп төртелсәң дә нindидер сәер, йомшак, җылы кочакка эләгәсең. Монастырьны төзүчеләргә шундыйны төзергә әйтәсем килә минем.

Әмма, Джо, диярсез, акылыңа кил. Синең ул йомшак монастырең, бер давылга да чыдамыйча, шунда ук җимерелеп төшәр иде. Ә аның урынында бары, йөзьяшәр тамырларын җиргә җибәреп, урман гына калкыр. Әйе, тып-тыныч урман гына утырыр.

Мин аның шулай булуын теләр идем.

Китапның буеннан-буена сузылган тагын бер линия бар: моңа кадәр булган барлык тәрбияләнүчеләр арасыннан качкан берданбер малай – Данни мифы. Бу хакта Джо биредәге «Дозор» дигән яшерен оешма әгъзасы булып алгач белә. Әмма Данни турындагы миф миф кына булып калса, аларның барысы өчен дә җиңелрәк буласы икән... Язучы укучыны да, үзен дә аямый – ул безгә чынбарлыкның асылда нинди була алганын аермачык күрсәтә.

Жан-Батист Андреа образларны гаҗәеп нечкә детальләрдән берәмтекләп җыя, сюжет линияләрен таслап үрә, төенли. Аның белән бергә китап буена сулышың кысылып, тамагыңа төер утырып, Сенак яки Лягух адымнарын ишеткәндәй, куркынып-сискәнеп, сыкраган сайгаклардан шомланып, тулы бер язмышлар галереясын кичәсең. Иң зур интрига интернатка учредительләрнең берсе үсмер кызы Розаны алып килгәч башлана. Бу очрашу Джо өчен киң дөньяга кабат тәрәзә ача – аның ничек рояльдә уйнаганын ишетеп алган затлы абзыкай малайны кызына музыка дәресләре бирер өчен чакыра. Һәм менә Джо, аларның затлы йортына килеп, онытылган тормышына кайткандай була – бармаклары клавишаларга орына да Бетховенны уйнарга керешә... Әмма бу – мәхәббәт тарихы да, дуслык тарихы да түгел. Моның өчен алар башка тормышта яки планетада уянсалар гына...

Әнә шул мизгелдән мин барлык мөмкин булган вокзал һәм аэропорт пианиноларында уйный башладым. «Әгәр син без беренче очрашкан көндәгечә уйнасаң, мин сине Җир шарының теләсә кайсы почмагыннан ишетермен...» Мин безнең тарихыбызны уйныйм: чемодандагы «Роллинг Стоунз» пластинкасы да бар анда, укытучым Ротенбергның таплар белән тимгелләнгән куллары да, мин тияр-тимәс орынган татлы иреннәрнең сулышы да, пульсы өзелгәнче йөгерүче Безродный да... Минем пианиноларым Нью-Йоркта, Мәскәүдә, Лондонда, Вальпараисода тора...

Жан-Батист Андреа белән әңгәмәләрдән:

- Мине балачактагы үз-үзеңне саклап калу инстинкты гаять кызыксындыра. Анда без олы тормыштагы үзебезгә караганда күпкә кыюрак һәм көчлерәк. Баланы бер кайгы, хәсрәт тә артык озак бимазаламый, һәлак итми, ул онытылырга сәләтле. Ул кечкенә генә шатлыкка да чатырдап ябыша, өзлексез үзгәрә, алышына, яңара. Балачакта Будда зирәклегенә тәңгәл нидер бар: менә хәзер, шушы мизгелдә яши белү.
- Мин газап турында түгел, ә ул газапның безне нәрсәгә өйрәтә алуы турында язам. Без газап төпкеленә батып үлә дә алабыз, аны яңа очыш өчен трамплин итә дә. Һәркемнең сайларга мөмкинлеге бар.
- «Дьяволы и святые» романы бер гаҗәеп сөйләшүдән туды. Ул кеше миңа үзенең приютта узган балачагы турында ышанып сөйләде, эчке кичерешләрен, серен ачты. Без бик аз сөйләштек, әмма ул бик тирәндәге истәлекләрен тартып чыгарды. Миңа бу истәлекләрдән нидер тудырыр өчен ел ярым вакыт кирәк булды... Һәм мин аны нинди ракурста язарга икәнлеген вокзалда торганда, теләсә кем килеп уйный ала торган рояльне күргән мәлдә аңладым. Әйе, ул менә шушындый рояльләрдә уйный ала бит, менә ничек төенләргә була, дип уйладым...
- Минем бик тә музыкант буласым килә, бигрәк тә – дирижер. Язучылыктан кала, мине бары тик үзем музыкант булган тормыш сценарие гына кызыктыра һәм канәгатьләндерә ала.
- Һәр яңа китапны тәмамлаганнан соң, мин үземне бушап калган хәлдә хис итәм. Батареяларны алыштырырга һәм яңадан үземне эшләтеп җибәрергә көч туплыйм. Яңа китапның миңа кайдан һәм кайчан киләчәген белмим. Нинди дә булса берәр тарих килеп «иярә», язуымны сорап ялвара икән, мин аңа «юк» дип әйтә алмыйм, – димәк, язам. Һәм иң кызыгы – мин беркайчан да тагын китап язачакмынмы-юкмы икәнемне белмим. Шуңа үзем турында: «Ул моңарчы өч китап язды, алга таба ни булыр, үзе дә белми», – дип кенә җавап бирә алам.



«Татарстан» журналы үз битләрендә яшь прозаикларның кечкенә күләмдәге әсәрләрен бастыра башлады. Без бу авторларның исемнәрен бик ишетеп-белеп бетермәскә дә мөмкин. Бу – табигый. Араларында әле вакытлы матбугат битләрендә тәүге басылучылары да булачак. Димәк, үзенә күрә сынау, укучы алдында җавап тоту дигән сүз.

Бу кызлар белән егетләрнең заманыбызга, бүгенге көн вакыйгаларына, вазгыятенә үз карашы, мөнәсәбәте бар. Үтә җитди, кискен иҗтимагый темаларга да мөрәҗәгать итә алар, мәңгелек сорауларга да җавап эзли, нечкә хиссияткә бирелеп, парча, нәсер кебек жанрларда да үзләрен сынап карый, юмористик рухта да иҗат итәргә омтылыш ясый.

Бүген сезгә үзгә тел һәм мәдәният мохитендә тәрбияләнеп, татарча каләм тибрәтергә алынган яшь авторның үзенчәлекле әсәрен тәкъдим итәбез. Әйдәгез, укып карыйк.

Алсу Зәйдуллина



Фото автордан

Автор турында белешмә:
Алсу Вадим кызы Зәйдуллина 2002 елның 21 мартында Сәмәрканд шәһәрендә туа. КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында татар филологиясен үзләштерә, хәзерге вакытта педагогика юнәлеше буенча магистратурада белем ала.
Проза әсәрләре яза, тәрҗемә итә, үзен әдәби тәнкыйтьтә сынап карый. «Йолдызлы көн вакыйгасы» парчасы белән Шәриф Камал исемендәге әдәби бәйгедә катнаша.
«Беренче тапкыр татар теле белән университетта таныштым. Телнең яңгырашы, хәреф-иҗекләре, төзелеше мине романнар дөньясына кертеп җибәрде. Аяз Гыйләҗев, Фатих Әмирхан әсәрләренә анализ ясадым. Әсәрләрне сүзгә-сүз тәрҗемә итү процессында татар теленә өйрәндем», – ди Алсу.
Гарәп графикасы белән кызыксына, йога белән шөгыльләнә.

ЙОЛДЫЗЛЫ КӨН ВАКЫЙГАСЫ

Күзләр очрашканда, дөньялар алышына, диләр...

Көз. Октябрь. Метро. 21:14. «Сак булыгыз! Ишекләр ябыла». Суык пәлтә кесәсе аша җылы куллар бер-берен җылыта. Мәңгелек. Каһвә исе... Тәмле йокыга бирелгәнмен икән. Метро тавышы. Адәмнәрнең карашы. Минем кулымда – сәхифәләр җыелмасы... Күзләр йомык. Ирексездән йомык күзләр чоры. Эрасы.

Көз. Октябрь. Метро. 21:27. «Сак булыгыз! Ишекләр ябыла». Адәмнәрнең тавышы. Берәү көлә. Башка берәү төшенкелеккә бирелгән. Депрессия. Әмма мине бу көз яшәтә. Йөрәгемә өмет кертә. Дәртләндерә. Тәмле йокыга бирелгәнмен икән.

Көз. Октябрь. Метро. 21:32. «Габдулла Тукай» станциясе. Алар минем бармакларым арасыннан оча. Сәхифәләр җыелмасы: «Бәхет», «Хыялларым», «Ага вакыт» һәм «Сагыну» юллары...

Шаша халык, халык шаша дөнья мәлләреннән. Вакыт чаба, юкка чыга. Бу мәңгелек йөрәгемне йомшарта. Шагыйрь юллар яза. Поэмалар. Әйе, дөрес, тормыш сынауларын кичкән кеше үзгәрә. Күзләр очрашканда, дөньялар алышына, диләр. Күзләр тормыш сынаулары белән очрашканда, дөньялар алышына. Елау хакыйкатькә төшенү дигәнне аңлата. Кеше – сүнә бара торган аппарат. Символ, деталь – әдәбият дөньясын биләп алган төшенчәләр.

Мин ялгыз. Бүлмә почмагында лампа янып тора. Ертык фотосурәт сары битләр арасында югалгандай тоела. Тәрәзә артындагы кар бөртекләре вальс әйләнә. Аяз абый* белән сөйләшеп алгач, курку хисе бераз югалды. Паралар вакытында берәр тарих сөйләү гадәти әйбергә әйләнде сыман. Каһвә исе һаман башны томалый. Ә соңгы парталар йокымсырыйлар. Сәхифә артыннан сәхифә йөрәк тамырына ябыша. Хәрефләрдән сүзләр барлыкка килә: «Кеше хакыйкатькә ирешә». Яисә ирешергә тырыша. Студентка кәгазь белән каләм җитә.

* Язучы Аяз Гыйләҗевка ишара.

Суык көннәр җанны җәзалый. Ә лимонлы чәй бөтен әрнүләрне дәвалый.

Студент кар бөртекләрендәге язуларны таный. Фотосурәт – кыстыргыч. Китап битен онытмас өчен. Фотосурәт – дәртләндерә, йөрәкне кузгата торган деталь.

– Дару кирәк? Кирәк табиб.

– Йөрәгемнең хәле начар. Сүнә йөрәк. Сүнә җанның моторы.

– Ә йөрәк кайчан авырый соң? Әллә чыннан да картаю йөрәккә шундый зыян китерәме икән? Куркыныч.

– Юктыр. Йөрәкнең авыруы безнең яраткан кешеләребезгә бәйле: никадәр күп рәнҗетә торган сүзләр ишетә, шулкадәр тизрәк эштән чыга. Йөрәк авыруы безне саташтыра, йөрәк авыруы кешене юк итә. Йөрәк тибә-тибә үзен эштән чыгара, йөрәкне авыр сүзләр сындыра, мескен итә, шуңа да карамастан, йөрәк тибүен дәвам итә.

– Ә ник шулай? Әллә йөрәк шулкадәр яшәргә яратамы икән?

– Юк бит, йөрәк кеше турында уйлый. Аны яшәтәм дип тырыша. Йөрәк кешенең уйларын ишетә, ә аның уйлары шундый чиста, саф.

– Ә йөрәк? Кемдер аны тыңларга уйлыймы? Кем йөрәккә булышырга тырыша? Ярдәменнән калдырмаска омтыла? Әллә йөрәк машинамы? Бәлки, башка берәр техник җайланмадыр ул? Ә нигә шулкадәр авыр соң йөрәккә? Каян килгән бу газап? Ник аны кеше әрли, кирәк булган вакытта гына аның турында искә төшереп, туктама дип үтенә...

– Кеше икейөзле театр сыман, кеше – сүнә бара торган аппарат.

– Табиб кирәк?

– Кирәк язу...

– Әллә шашамы соң. Гаҗәп. Хәле начар. Йөрәк авыруы. Тамырлары корый бара. Димәк, кирәк дару! Табиб кирәк! Ә ул хәрефләрдән сорый язуны.

– Язу кирәк! Хисләр ташкыны!

Үзе елый. Шаша. Диварларга барып бәрелә, хәтта тәнендәге тамырлары күренә.

– Шашты! Диагноз! Һичшиксез.

– Миңа кирәк хәрефләрнең җыелмасы. Сәхифәләрнең кыштыр-кыштыр килүе.

Тынычланды бераз. Матур кулларына каләм алды. Яза. Әллә нәрсә яза булыр. Беркем белән сөйләшмичә, февраль буе мичкә карап ята. Минем күзләремә карамыйча, күз яшьләрен әбиемнең румалы** белән сөртә. Гаҗәп. Елый, димәк, хакыйкатькә ирешергә тырыша. Көне буе елый. Яза. Туктамыйча яза. Илһамланып киткән кеше шикелле.

** румал – үзбәк телендә «яулык»

– Тукта. Аша. Синдә йөрәк авыруы. Табиб сиңа рецепт язып бирде.

– Нинди рецепт? Йөрәк үзе җайлаша.

– Каян беләсең? Нинди йөрәк үзе җайлаша?

– Йөрәк минем белән кеше кебек сөйләшә.

– Йөрәк сөйләшә белсә иде... Бәлки, шулчакта кешеләргә яшәргә җиңелрәк булыр иде.

– Ә ул дәшми, үз «хуҗасын» борчымаска, аның өчен җайлы булырга тырыша.

– Ә ни өчен ул шулай эшли?

– Ярата.

– Йөрәк үз хуҗасын ярата.

– Йөрәк хуҗасының хисләрен тоя белә. Бөтен авыруларын сизә. Йөрәк кешене туктамыйча ярата. Мескен йөрәк...

– Табиб сиңа рецепт язып бирде. Дару кирәк. Сиңа тынычлык кирәк.

– Нинди табиб? Нәрсәгә? Минем сүнә йөрәк. Йөрәк ташкыны.

– Димәк, амбулатор дәвалану кирәк.

Кар бөртеге тәрәзәгә бәрә. Лампа сүнә. Суык. Тышкы җилләр пәрдәләрне уйната. Мичтә соңгы күмер сүнә. Шәфәкъ сыман сүнә гомер агышы... Көннәр буе каләмне кулларында уйната. Бүлмә инде баткан кәгазьгә. Кабилият. Күз яшьләренең эзләре йөрәгемне тибрәтә. Калтыраган куллары. Талант. Яза. Актарына. Бармаклары имән кебек картая. Февраль яза. Март яза. Иртән, кичен – барыбер. Утыра. Елаганнан-елый бара. Һаман экзистенциягә аяк баса.

– Нәрсә булды? Әллә тагын йөрәгең авыртамы?

Ялгызлык – йөрәкнең дустыдыр. Кайвакыт ялгызлык белән йөрәк бәхәскә керә. Ялгызлык ачуланган саен йөрәкне эштән чыгара, ә йөрәк моны күрми шикелле. Юк, ул бу ялгызлыкны күрә, күрә генә түгел, сизә, тоя, тамырлары эченә кертеп җибәрә, әмма күзләрен йомып, елмаеп тора. Ялгызлыкны күрмәскә тырыша, юк, ул миңа зыян китерми дип, елмаеп тора, тибә бара, ә ялгызлык салкын куллары белән аны буа, кислород агымын кыса, ялгызлык йөрәкне шулкадәр мескен итә ки, хәтта кешенең тәненә курку хисен кертә.

– Әйе, йөрәк. Суларга да рөхсәт бирми кебек тоела.

– Әйттем бит, дару кирәк. Дару сине коткара.

– Булса иде шул дөньяда мине алдамаучы, ихлас хисләр дөньясына батыручы.

Тагын елый. Акыра. Йөрәгенә куллары белән суга. Бәрә. Әйтерсең, йөрәген бөтенләй туктатырга тырыша.

– Табиб ялган сөйләмәс. Бабай, ишет, зинһар, мине.

– Булса иде шул дөньяда мине алдамаучы, суынып беткән йөрәгемне дәвалаучы.

Бер бәрә. Ике бәрә. Үземе икән шул коткаручы? Йөрәген үзе эштән чыгара.

– Бабай, булды, тукта, табиб сине дәвалар.

– Бармы икән бу дөньяда әрнү хисләренә батмаучы?

– Һаман шигырь яза. Сүнә. Көне буе үзен бетерә.

– Бармы икән бу дөньяда минем йөрәк тамырларын ертмаучы?

– Бабай, тыңла, сиңа табиб кирәк. Йөрәк үлә. Коткар, зинһар, үзеңне.

– Бармы икән бу дөньяда мине үлеп-үлеп яратучы, күзләренә карыйм диеп сагынучы. Бармакларын үбәм дип торучы. Бармы икән бу дөньяда, күзләремә карап, дөреслекне генә сөйләүче...

Төшенкелеккә бирелү – начар гадәт. Кирәкле булуында шикләнү кешенең күңелендә курку хисен уята. Кешенең үз-үзенә куйган бәясе түбәнәя бара. Кирәкле булуда шикләнү кешене сындыра, кылган гамәлләрендә икеләнү уята.

Колак салмый. Үзсүзле. Мигалкалар сүнми. Бара. «Ашыгыч ярдәм» килә.

– Түзсәң иде, бабай, биш минут.

– Бармы икән бу дөньяда төннәр буе йокламыйча, минем янда кулларымны җылытучы...

– Йөрәк үлә. Сулыш бетә. Ә ул һаман шул хакыйкатькә ирешергә маташа.

Пөхтә күктән карлар ява. Балкый йолдыз. Булды. Тәмам. Аллаһның да кары бетте шикелле.

Соңгы сулыш соңгы кар бөртеге сыман. Язучыларның куллары матур була икән. Язучыларның куллары нечкә була икән. Илһамлану вакытында күз яшьләрен сөртер өчен.

Ә музыкант куллары? Фортепиано. Скрипка.Музыкантларның куллары нечкә була икән.

Закон. Әллә Аллаһ уйлап таптымы икән бу канунны?

Язучыларның куллары җылы була икән.

Төшкенкелек вакытында башкаларның йөрәкләрен җылытыр өчен.

Бармы икән бу дөньяда кешеләрнең күзләренә карап дөреслекне сөйләүче? Кабилият. Хакыйкатьне сөйләү – талант. Бармы икән бу дөньяда ихлас язучы? Йөрәген суык бүлмәгә бикләмәүче? Бармы икән бу дөньяда үз-үзенә дөреслекне сөйләүче?

Язучыларның карашлары тирән була икән. Уйга батып фикер җыю өчен.

Язучыларның күзләре матур була икән.

Ихлас уйлар укыр өчен.

Бармы икән бу дөньяда әрнү хисләренә батмаучы?

Язучының уе матур була икән.

Йөрәкләрне сүзләр белән дәвалаучы...

Кыш. Декабрь. Метро. 22:11.

«Сак булыгыз! Ишекләр ябыла...»

ОСТАЗЛАР ОСТАЗЫ

Айдар Шәйхин

Бер кешенең гади генә гамәле, игелеге, мәрхәмәте дөнья тарихын үзгәртергә сәләтле, диләр. Моның дөреслегенә инанмый булмый. Мәсәлән, күпләр өчен Нургали абзый булган укытучының Оренбург урамында Муса дигән малайны күреп тануы, аны урам тормышыннан йолып алуы һәм укырга урнаштыруы ил тарихын шагыйрьле һәм геройлы итте. Ә без белмәгән тагын нинди игелекләре булган икән бу укытучының? Остаз һәм остазлар остазы – Нургали Надиев язмышын барлыйк әле.

ШӘКЕРТЛЕК ЮЛЫ

Нургали Сибгатулла улының туган ягы – элеккеге Пенза губернасының (хәзерге Саратов өлкәсе) Селәү (Сөләй) авылы. Ул төбәктә әле хәзер дә Надиевлар фамилиясен хәтерлиләр. Бу зур һәм куәтле авылда әлеге нәсел вәкилләре берничә буын дәвамында имамлык иткән.

1882 елның 20 августында Сибгатулла хәзрәт гаиләсендә Нургали атлы ул туа. Тарихчылар соңрак бу егетнең туган елы хакында бәхәсләр оештырачак. Кайбер энциклопедияләрдә – 1883, кайберләрендә хәтта 1884 ел күрсәтеләчәк. Үзенең шәхси эшендә 1883 елның гыйнвары дигән мәгълүмат бар. Нургали мәгърифәтле әти-әнисеннән башлангыч белем ала, аннары Иске Карлыган һәм Пәлдәнге авылларында мәдрәсәләрдә укый. Билгеле ки, бу төбәк – бик күп татар җәмәгать эшлеклеләрен, сәясәтчеләр һәм әдипләрне биргән туфрак. Шушы якларда Шамил Усманов, Һади Такташ, Шәриф Камал үсә.

Имам-хатыйблар һәм мөдәррисләр нәселен дәвам итәргә тиешле Нургали Казанга, атаклы Күл буе мәдрәсәсенә килә. Укытуда традицияләргә тугры булуы белән дан тоткан, рус телен кертүгә озак еллар каршы торган мәдрәсә була ул. Әмма ни генә дисәң дә, әлеге мәдрәсә Казанда һәм, гомумән, татар-мөселман дөньясында барган үзгәрешләрдән качып котыла алмый. Шәкертләр арасында киң карашлы, яңа вакытка әзерлекле булып килгән егетләр күп була. Нургали – шундыйларның берсе. Аның хыяллары да бу дәвердә гади имам яки мөдәррис булу белән генә чикләнми. Ул халыкка хезмәткә омтыла.

1901 елда Күл буе мәдрәсәсен тәмамлагач, Нургали Казан татар укытучылар мәктәбенә укырга керә. 1876 елда оешкан укытучылар мәктәбе рус-татар казна мәктәпләре өчен укытучылар әзерләгән. Бу уку йортын тәмамлаган очракта, син дәүләт тарафыннан танылган укытучы буласың. Фәннәр русча укытыла, димәк, империя киңлекләрендә уңышка ирешер өчен кирәкле тагын бер телне беләсең. Карьера өчен башка мөмкинлекләр, башка белем дәрәҗәсе һәм милләткә хезмәт итүнең башка юллары ачыла. 1904 елда Надиев «дипломлы» мөгаллим дәрәҗәсенә ирешә.

МӨФТИЛӘР АВЫЛЫННАН – МИЛЛИОНЕРЛАР ШӘҺӘРЕНӘ

Татарстан Милли музее архивында Надиевның музейда хезмәт иткән чорыннан калган шәхси эше саклана. Анда галимнең хезмәт юлы җентекләп күрсәтелгән. Шуны тәгаен әйтә алабыз: 1904 елның 1 сентябреннән ул Уфа губернасы Минзәлә өязенең Мәчти (русча Мастеевка дип язылган) авылында эшли башлый. Вазыйфасы да нинди бит: мәдрәсәдәге рус сыйныфы мөдире һәм укытучысы.

25 балага исәпләнгән бу сыйныф 1877 елда ук ачыла. Хәзер Актаныш районы җирләренә караган, әмма ярты гасыр элек юкка чыгарылган Мәчти – атаклы татар дворяннары Солтановлар

Фотолар автордан алынды

нәселенең туган җире. Мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов та шушы нәселдән, шушы авылдан була. Шулай итеп, 22 яшьлек рус теле укытучысы Нургали карьерасын искиткеч уңышлы ноктадан башлый: ул бу вакытта Уфада мөфти булган Солтановның туган җирендә хезмәт итә.

Авылда 2 ел эшләгәннән соң, Нургалине ул вакытта Самара губернасына караган Бузулук шәһәренә чакыралар. Өяз үзәге, монда 15 меңләп кеше яши. Мәчти генә түгел инде бу, әлбәттә. Монда татар мәктәпләре дә эшли. Надиев казнага караган татар башлангыч мәктәбендә укытучы һәм мөдир була. Монда ул 1913 елга кадәр эшләячәк.

Зур губерна башкаласы булган Оренбургка күчүе 1913 елда була. Монда аңа ике вазыйфада эшләргә туры килә. «Хөсәения» мәдрәсәсендә ул рус теле һәм тарих укыта, шул ук вакытта земствоның татар әзерлек мәктәбен җитәкли. Мәдрәсәдә эшләве аңлашыла, бу юлдан үткән шәхесләрне беләбез. «Хөсәения»нең даны бүген дә саклана, анда укыган татар әдипләре, җәмәгать эшлеклеләре саны бик зур. Бу елларда кечкенә Җәлил дә – Надиев шәкертләреннән. Ә «приготовительная школа» дигәне нәрсә соң? Мондый прогимназия рәвешендәге мәктәпләрдә киләчәктә гимназиядә укырга тиешле балалар белем ала. Надиев татар малайларын шундый мәктәптә укыта.

Ә аннары – давыллы еллар, ком бураннары һәм шул гарасатлар арасында үзеңне, мәктәпләрне, милләт институтларын саклап калырга омтылу. Әмма аңа кадәр татар байлары, хәтта ки миллионерлары яшәгән Оренбургтагы кызыклы тормышы бар әле.

МАҖАРАЛАР ЭЗЛӘП...

Казанда укыган чорда ук Надиев үзен әдәбият өлкәсендә сынап карый. Ул Даниэль Дефоның «Робинзон Крузо маҗаралары»н татарчага тәрҗемә итә һәм беренче кисәген бастырып та чыгара. Бу 1904 елда була. 1909 елның 16 маенда ул үзе дә шундый сәяхәткә чыгып китә.

Надиевның «Сәяхәт хатирәләре» – татар сәяхәтнамәләре жанрына караган кызыклы текстларның берсе. Ул аны 1915 елда «Шура» журналында бастыра башлый, әмма ни өчендер бу сәяхәтнамә тулысынча дөнья күрми. Әмма булган өлеше дә гаять кызыклы.

«Бузулук шәһәрендә тыныч кына торганда Мәскәүдә булган сәяхәт комиссиясенең чит җирләргә сәяхәт итәргә теләүче учительләрдән группалар тәшкил кылып ятканын кулыма төшкән бер газетада укыдым. Мөгаллимнәрдән, тынычлыктан, бертөрлелектән бизеп беткән җаныма бу хәбәр кызу дәрт салды. Мәзкүр комиссия тарафыннан игълан кылынган йөрү тәртипләрен, программа һәм низамнарын таптым. Мәскәү, Одесса, Истанбул, Измир, Афина, Искәндәрия, Каһирә, Порт Сәгыйдь, Яффа, Коддес, Бәйрут, Солоники юлыны ихтияр иттем...»

Надиевның география һәм тарих белән кызыксынуы да табигый. Мәктәп-мәдрәсәләрдә ул тарих фәнен дә өйрәтә. Бу өлкәдә дәреслекләр җитмәве аны хафага салмый. 1909 елда «Русия тарихы» дәреслеген үзе язып, нәшер иттерә. Китап инкыйлабка кадәр биш тапкыр яңадан бастырыла. Әйе, цензура белән проблемалар булып ала, әмма дәреслекне барыбер кулланука рөхсәт итәләр.

Әкренләп педагогика өлкәсендә тәҗрибә туплана бара. Укытучылар мәктәбендә алган белеме дә, авылда, өяз шәһәрендә һәм губерна үзәгендә җыелган эш тәҗрибәсе дә хәзер инде башкаларны үстерер өчен кулланыла ала. 1910 елдан башлап, Нургали Надиев татар матбугатында даими яза башлый. «Шура», «Мәктәп», «Мөгаллим», «Мәгариф» журналларында аның мәкаләләре басыла.

КОМ БУРАНЫ, ОРЕНБУРГ УРАМЫ...

1917 ел инкыйлабы бөтен ил тормышын үзгәртә, Надиевның да үзгәрешләргә иярми чарасы юк. Ул халык мәгарифе идарәсендә мөселман бүлеген җитәкли башлый – бөтен Оренбург губернасы мәдрәсәләре һәм мәктәпләре өчен җаваплылыкны үзенә ала. Бу вазыйфаны 1920 елга кадәр башкара.

«Хөсәения» мәдрәсәсе исә 1919 елда эшен туктата. Яңа шартларда ул инде дини белем бирә торган уку йорты буларак эшли алмый. Әмма педагогик состав та, биналар да югалмый. Мәдрәсә татар халык мәгарифе институтына әверелә. Аның директоры итеп Нургали Надиев

Нургали Надиев (сулдан беренче) укытучылар белән. Бузулук шәһәре.

Гаиләсе белән. 1909 ел.

билгеләнә. 6 ел буена ул ТИНО (Татарский институт народного образования) директоры буларак хезмәт итәчәк һәм ком бураны хакимлек иткән елларда татар мәгарифен үстерергә тырышачак.

Корылык һәм ачлык елларында Надиевка да коточкыч сынаулар аша узарга туры килә. Мондый вакытта үзеңдә игелек, мәрхәмәт сыйфатларын югалтмау иң авыры булгандыр. Нургалигә мондый рух сынавын кичерергә Муса Җәлил ярдәм итә. 1921 елда 15 яшьлек Муса янәдән Оренбургка килә. Шәһәрдә моңарчы яшәгән булса да, бу вакытта аның туган-тумачалары таралышып бетә. Яшүсмер егет урам малайлары төркеменә кушыла. Лидерлык сыйфатларына ия чая егет караклар шайкасына кушыла яза. Яман эшкә кушылу куркынычы янаган малайны остазы шәһәр базарында күреп ала. Ул «Хөсәения»нең талантлы шәкерте Мусаны яхшы хәтерли. Остаз шәкертен өенә алып кайта, юындыра, тамагын туйдыра, хәрби-сәяси мәктәпкә курсант итеп урнаштыра. Соңрак Җәлил Надиев җитәкләгән институтта укып ала. Надиев Казанга күчкәч, аның башкаладагы фатирында да көтеп алынган кунак була. Алай гына да түгел, сугышка киткәндә Җәлилнең бер папка документлары Надиевлар гаиләсендә саклауга калдырыла, еллар үткәч, хатыны Әминә ханымга кайтарыла.

КАЗАН ШӘХЕСЛӘРНЕ ТУПЛЫЙ

1924 елда Надиевлар гаиләсе Казанга кайтып төшә. Надиевка элек сәүдәгәр Ивановлар милке булган йортның беренче катында фатир бүлеп бирәләр. Бу фатир хәзерге Островский урамының 15 нче йортында, татар әдәбияты тарихы музее һәм Шәриф Камалның мемориаль фатиры урнашкан бинага карый. 1920 нче елларда биредә Надиевлар, Шәриф Камаллар, Сафа Борһаннар яши.

Нургалинең хатыны Мөстәгыйзә, балалары Рөстәм, Назыйф, Сөембикә, Клара, Гыйффәт, Иркә – фатирга барысы да сыя. Гаилә башлыгы үзе әүвәл Казандагы татар педагогика техникумында, шул ук вакытта Академүзәк рәисе урынбасары да булып эшли. 1930 елдан педагогика институтында педагогика кафедрасы мөдире була. Гомумән, 1920–1930 нчы елларда Надиев – абруйлы педагог, шәһәрнең һәм республиканың горурлыгы, хөрмәтле шәхес.

Ул һаман яза, татар телендә педагогика фәннәрен үстерергә тырыша. 1920 елда ук аның «Педагогика конспектлары» исемле хезмәте басыла. Бу – вуз студентлары өчен татарча дәреслек. Ул шулай ук «Мәгариф» журналында мәкаләләр чыгара. Ә темалары шундый кызыклы була ки, кайберләре хәзер дә актуаль. Мәсәлән, 1928 елда чыккан бер мәкаләсен бүген дә укытучыларга һәм ата-аналарга укытырга була.

«Тәрбия мәктәп рамкасында гына калмый, аның гаилә, урам кебек башка факторлары бар. Без иске гадәт буенча тәрбия эшен мәктәп монополиясенә бирергә өйрәнгәнбез. [...] Бала мәктәпкә йөри башлагач, сөйләргә өйрәнер, мәктәпкә йөри башлагач, ярамас гадәтләрен ташлар, тәрбияләнер. [...] Безнеңчә, мәктәп балага бөтен нәрсәне бирергә тиеш: ул балага белем бирергә тиеш, ул баланы тәрбияле ясарга тиеш, ул баланы һөнәрле итәргә, тормышка яраклы итәргә тиеш; балабыз тәрбиясез булып чыкса, әхлаксыз, һөнәрсез, тормышка яраксыз, хәзерлексез, ялкау, дөньяга ялгыш карашлы надан булып чыкса, без, гадәттә, мәктәпне шелтәлибез, бөтен гаепне мәктәпкә аударабыз. [...] Бала мәктәптә көннең бары дүрт-биш сәгатен

Күл буе мәдрәсәсе шәкертләре. Беренче рәттә (уртада) – Нургали Надиев. 1890 нчы еллар ахыры.

Татар халык мәгарифе институты укытучылары. 1922–1923 уку елы. Икенче рәттә (уңнан дүртенче) – Нургали Надиев.

генә үткәрә, димәк, мәктәпкә йөргән вакытында бары 15–20 процент кына мәктәп тәэсирендә була».

НӘСЕЛ ДӘВАМЧЫЛАРЫ

Репрессияләрдән котыла алган Нургали Надиев 1940 елда вафат була. Ул Казанның Арча зиратында, университет профессорлары хозурында җирләнә. Исән чагында хезмәте югары бәяләнгән шәхес була ул. «Нургали ага кулыннан килгән кадәре татар халкына эшләп торды, намуслы кеше иде», – дип язган Бакый Урманче.

1983 елда Надиев яшәгән йортта мемориаль такта куела. 2022 елда бу такта реставрацияләнеп, яңадан куйдырылды, Татар китабы йортында Надиевларга багышланган чаралар үткәрелә башлады. Берничә ел элек Нургали Надиевка бәйле экспонатлар, кульязмалар һәм фотосурәтләр дә музейга тапшырылды. Алар арасында педагогның улы Рөстәмнең көндәлеге дә бар булып чыкты.

Нургали Надиевның балалары – зыялы, гыйлемле кешеләр. Улы Назыйф төзүче-инженер белеме ала һәм шул өлкәдә эшли, ә Бөек Ватан сугышы елларында әсирлеккә эләгеп, «Идел-Урал» легионы составына кертелә, әсирләргә татар теле укыта, Җәлил белән очраша. Клара исемле кызы ярдәме белән без аның мирасын саклый алдык. Кызы Сөембикәнең нәсел дәвамчылары хәзер дә Надиевлар исемен үҗәтләнеп саклый. Рөстәм улы исә шулай ук кызыклы язмышка ия шәхес булып үсә. Ул яшь чагында әдәбият белән мавыга, хәтта ки яшь язучыларның бөтенсоюз киңәшмәләрендә дә катнаша. Әмма, абыйсы кебек үк, архитектура һәм төзелеш инженерлыгы өлкәсендә укый. Тик гомере буена барыбер иҗатка тартыла. Аның тәрҗемәсендә чыккан фәнни-популяр китаплар да, үзе язган очерклар да бар. Ә көндәлегендә Рөстәм шундый нечкә күңелле, ихлас студент буларак ачыла. Надиевлар гаиләсендә бер-береңә хөрмәт һәм мәхәббәтнең ни дәрәҗәдә көчле булуын Рөстәмнең көндәлегендәге менә бу юллар раслый:

«Мине дә үземнең иң яраткан, иң сөйгән кешем озата төште. Ул – үзенең ак чәчле, ак мыеклы, ак бөртек-бөртек сакаллы йөзе белән, минем йөрәгемә, миңа тормыш биргән, безнең алтавыбыз өчен дә җанын-тәнен кызганмаган атам. Нургали абзый.

Мин сизәм: ул шат та, күңелсез дә. Ул ачык та, уйчан да. Аңа мине, үзенең сөйгән улын, озату бер яктан зур шатлык та, ә бер яктан зур кайгы да. Ул мине үзенең зур таянычы итеп хисаплый. Ул миңа ышана. Ул мине ярата.

Мине озаткан вакытта әнинең, күз яше түгеп, «Балам» дип елап калуы әле дә күз алдыннан китми. Ул көне буе күз яшенә тулып йөрде. Әш-мәш килеп, минем китәсе минутларны озайтырга, аларны ничек булса да сәгатькә әйләндерергә теләде. Кат-кат:

– Балам, үзеңне сакла, акчаңны кызганма, туйганчы аша, андый-мондый хәл булса, тилиграм сук, – дип әйтеп торды.

Рәхмәт, әнкәм! Мең рәхмәт! Тагын да озын гомер белән яшә. Синең чын аналык йөрәге белән януыңны мин гомеремдә дә оныта алмам. Бер мин генә түгел, синең бөтен балаларың да синең аналык мәхәббәтеңне исләреннән чыгара алмаслар. Мин үзем шулай уйлыйм».

Нургали Надиев – халкына хезмәт иткән, остазлар тәрбияләгән, кешеләргә ихтирам белән караган һәм балаларын мәхәббәт белән үстергән остаз.

Татарстан авыллары

ҖЫЛЫ КҮЗКӘЙ



Фото: Лилиана Вәлитова

КҮЗКӘЙ

Тукай районының Күзкәй авылына килеп җиткәндә, машина эчендәге термометр урамда егерме сигез градус суык күрсәтте. Туры мәдәният йортына кердек. Урамдагы суыктан соң, мизгел эчендә эчкә җылы йөгерде...

Руфия Фазылова

«ЭШКӘ ЙӨРГӘН КЕБЕК КИЛӘБЕЗ»

Күзкәй авылының уннан артык апасы махсус операциягә маскировка өчен ятьмә үрә иде. Бу эшне ике ай элек башлаганнар икән. Шимбә-якшәмбене санамаганда, көн саен мәдәният йортына килеп, ярты көн шулай эшлиләр.

– Материалны алып кайтып җиткерсәләр, туктамый үрәбез, – дип елмайды Илгизә апа Нуруллина. – Ике көнгә бер ятьмә әзерлибез, зурлыгы өч метрга алты метр. Әле менә ике ир-ат та кушылды, алар тукыманы кисеп тора. Күзкәйдә миһербанлы кешеләр яши, материалларны сатып алырга акча да бирәләр. Бер авылдашыбыз тукыма кисә торган машинка да алып бирде. Хәзер эшләргә җайлы инде, тиз дә була бит.

Күзкәй авылы мәдәният йортының тормышына көнләшерлек: биредә өч коллектив эшли! Берсе – халык театры, икенчесе – китапханә каршындагы «Хатирә» клубы, өченчесе – «Әллүки» фольклор ансамбле. Өчесе дә бик актив. Халык театрының фестиваль, конкурсларда җыеп алган диплом-грамоталары бер дивар тулган. Авылның мәдәният йорты зур булгач, коллективларга репетицияләр ясау, очрашу өчен урын җитәрлек.

1

Шимбә-якшәмбене санамаганда, көн саен мәдәният йортына килеп, ятьмә үрәләр.

2

Илгизә Нуруллина безнең өчен чын ачыш булды!

– Ә бу нинди зал? – дим эш белән мәшгуль апаларга.

– Ветераннар бүлмәсе, музей да монда. Ятьмә үрергә кирәк булгач, әйберләрне шулай артка-рак эттек әле.

– Мәдәният йортында эшләүче өч коллективның кайсына йөрисез?

– Монда нигездә «Хатирә» клубына йөрүчеләр, 60+ дип көләбез үзебездән, – диде Илгизә Нуруллина. – Өйдә генә бикләнеп ятасы килмәгәнгә шулай җыелышабыз. Китапханәдә бик еш чаралар үтә – яңа китап чыкса, бергәләшеп фикер алышабыз, язучыларның юбилейлары алдыннан түгәрәк өстәлләр оештырабыз. Бездә халык мәдәниятле, әдәбиятлы. Район күләмендә шашка, шахмат, йөгерү ярышларында катнашып, җиңүләр яулыйбыз. Аннары, халык кече күңелле дә: авылдашлар төркеменә игълан язу белән, унбишләп хатын-кыз ятьмә үрергә килеп тә җитте.

Апалар зыялы, шуның белән бергә җор телле дә. Ятьмә үрүдән бер бәйрәм ясаганнар: көн саен табын коралар икән. Кемдер коймак пешереп килә, кемдер салат ясый. Дүрт сәгать эшләгәч, чәйләп алалар.

Без килгән көнне ит бәлеше дә пешкән иде. Инде без танышып өлгергән, авылның уңган, юмарт апасы Илгизә Нуруллина аны иртән торып әзерләгән. Кызыл катык, корт – телеңне йотарлык бу ризыклар да аның хезмәте. Ике сыер, ике үгез, өч бозау, утыз каз, кырык үрдәк, тавыклар... Әле район күләмендә шашка, шахмат, йөгерү ярышларында катнашып, җиңү яулый. Авыллар буенча күп йөргәч, тырыш, уңган апалар еш очрый, ләкин Илгизә апа безнең өчен чын ачыш булды! Алтмыш алты яшендә мондый дәрт-дәрман, өлгерлек күреп, шагыйрь әйтмешли, тел шартлаттык.

– Илгизәсез авылда бер аш-су мәҗлесе дә узмый, төн йокламыйча булса да бәлешләр пешереп өлгертә, – диештеләр мәдәният йортына җыелган апалар.

«АГАЧ ЭШЕ ПӨХТӘЛЕК ЯРАТА»

Авылның хатын-кызлары гына түгел, ир-атлары да талантлы. Нәрсә турында сүз чыкса да: «Рөстәм булышты», – диләр. Рөстәм Ясәвиев – агач остасы, соңгы елларда тимерчелек белән дә мавыгып киткән. Мәдәният йортында ятьмә үрүчеләр арасында Рөстәм абыйның җәмәгате Дамирә апа да бар иде. Ул безне үзләренә алып китте.

– Рөстәм бик пөхтә кеше, үзенә берничә сарай – остаханә эшләде. Аларның барысында да тәртип, үзегез күрерсез, – диде.

Дамирә апа хаклы булган: останың эш урынында ник бер чүп булсын. Хуҗа аны көнгә бишәр тапкыр себереп чыгара икән.

– Пычрак булган җирдә эшнең рәте китә, иҗат итә алмыйм, холкым шундый, – дип елмайды Рөстәм абый.

Рөстәм Ясәвиев Кузкәй авылында туып-үскән. Урта мәктәпне тәмамлагач, Казан сәнгать училищесында укыган. Аннан исә Чаллыга кайтып, «Камгэсэнергострой»ның сәнгать-бизәкләү участогында эшләгән. Соңрак 47 нче һөнәр училищесында төзүче яшьләрне агач әйберләр ясау осталыгына өйрәткән. Шул чорда бер эшкуар белән килешеп, агач эшләнмәләрне сатуны да оештырганнар. Ун ел элек исә Рөстәм абый хәләл җефете Дамирә апа белән туган авылы Кузкәйгә күченеп кайткан.

– Ике кыз үстердек, – диде оста. – Берсе Чаллыда, берсе гаиләсе белән Казанда яши. Башта туган нигезнең күршесенә җәйге йорт салдык. Аннары ул йортны зурайттык. Иртә язда кайтып, кара көзгә кадәр монда яшәдек. Берсендә Дамирә әйтә: «Кышны да авылда чыгыйк, өйгә газы, суы кергән». Әнә шулай һич уйламаган җирдән бу йортта ел әйләнәсе яши башладык. Бик рәхәт. Хәзер шәһәргә баргач, тизрәк кайтасы килә.

Рөстәм абый кул эшләрен күрсәтте: чын сәнгать әсәре алар. Профессионал кулы икәнен күренеп тора. Төрле сыннар, савыт-саба, тартмалар, ни генә юк монда. Өч яклы йортын берүзе (!) салып чыккан. Әлбәттә, бер елда түгел. Сарай, мунчалар да шулай ук аның хезмәте. Монда һәр корылманың үз йөзе бар.

– Менә бу бизәкле шкафлар, караватлар – барысы да Рөстәмнең эше, – дип аерым бер горурлык белән әйтте Дамирә апа. – Мин аны күрмим дә, гел шул остаханәсендә мәш килә. Ашарга чакырырга чыккач, ясаган эшләрен сөенеп күрсәтә. Мактыйм инде үзен, чынлап та, кул эшләре искитәрлек бит. Чын иҗат кешесе ул, үзенчә, тыныч кына эшләргә ярата.

– Рөстәм абый, сезгә мондый талант кайдан килгән? – дим.

– Кечкенәдән рәсемнәр ясый идем. Әти дә безнең талантлы булган дип уйлыйм, тик ул чагында аңа үсәргә мөмкинлек булмаган. Ә мин менә гомерем буе яраткан эшем белән шөгыльләндем.

– Ә ул сезгә акча китердеме соң?

– Әлбәттә, шуның белән тормыш алып бардым. Миннән зур агач шахматларны бүләккә дип ясатып алдылар. Минтимер Шәймиевтә дә мин ясаган шахмат бар. Чаллыда яшәгәндә ТР Мәдәният министрлыгы белән турыдан-туры эшләдем.

Әйткәнемчә, Рөстәм абый бүген тимер эше белән дә шөгыльләнә: калайдан төрле сыннар, бизәкләр ясый. Заказлар ала. Димәк, пенсиягә өстәмә – иш янына куш.

3

Рөстәм Ясәвиев – агач остасы, соңгы елларда тимерчелек белән дә мавыгып киткән.

4

– Безнең максат – иманлы бала үстерү, – диде мәчетнең имамы Илнур Фәрхетдинов.

5

Янгын сүндерү бүлегендә тугыз кеше хезмәт куя.

6

Мәчетнең аерым аш бүлмәсе дә бар.

Ир белән хатынның бер-берсенә булган мөнәсәбәтенә игътибар иттем: Дамирә апа гомер иткән хәләл җефетенә бер соклану белән карый. Җәмәгате ясаган әйберләр турында тәмләп, бик яратып сөйли. Ун ел элек Дамирә апа Күзкәйдә үз кешегә әйләнгән. Мәдәният йортында булган чаралардан бер дә калмый.

«БАЛАЛАРНЫ УЕН БЕЛӘН ҖӘЛЕП ИТӘБЕЗ»

Күзкәй зур, төзек авыл. Бүген биредә 544 кеше яши, 345 хуҗалык бар. Чаллы шәһәренә утыз-кырык чакрым тирәсе, шәһәргә йөреп эшләүчеләр бик күп. Колхоз үзе булмаса да, элеккеге системада эшли: мөгезле эре терлек фермалары бар, игенчелек тармагы көчле. Монда тагын бюджет оешмалары күп: урта мәктәп, балалар бакчасы, сырхауханә, янгын сүндерү бүлеге, Тукай районының «Татэнерго»га караган бер бүлекчәсе эшли. Соңгысында биш ир-атка эш булган, янгын сүндерү бүлегендә исә тугыз кеше хезмәт куя. Кыскасы, эш урыннары белән зур проблема юк.

Авылның урта мәктәбенә кермәдек, салкын булу сәбәпле, укучылар өйдә, диделәр. Белем йортында илле ике бала укый икән. Аның каравы авылның тагын бер белем, тәрбия үзәгенә – мәчеткә кердек. Әйе, нәкъ шулай, Күзкәйдә мәчет балаларның яраткан урыны икән. Һәр җомга, дәресләрдән соң, алар монда җыела. Башта чәйләп алалар. (Балаларга дип, ризыкларны кафедан махсус китертәләр.) Аннан өстәл уеннары уйныйлар (иганәчеләр бүләк иткән). Соңыннан кырык биш минут әхлак дәресләре. Әле алай гына да түгел, мәчеттә Рөстәм Ясәвиев малайларны агач эшенә өйрәтә. Шуның өчен кисә торган станоклар алып куйганнар. Малайлар үз куллары белән нәрсә генә ясамый!



4

– Безнең максат – иманлы бала үстерү, – диде мәчетнең имамы Илнур Фәрхетдинов. – Әйе, аларны гарәпчәгә өйрәтеп, дини китаплар белән генә дә укытып була. Без алай да эшләп карадык. Нәтиҗәдә, мәчеткә йөри торган егерме биш баланың унысы гына калды. Әһә, болай ярамый икән, дип уйладым. Һәм әхлак дәресләрен яңача – уен белән

5

6

кушып алып бара башладым. Әлбәттә, аларга төрле догалар өйрәтәм, иман, тәрбияле булу турында сөйләшәбез. Мәчеткә йөргән баланың күңеле начарлыкка тартылмаячак, Аллаһ боерса. Минә шуның өчен дә максат – мөмкин кадәр күбрәк баланы җәлеп итү.

Совет хакимияте килгәнче, Күзкәй авылында өч мәчет булган. Кызганыч, ул биналарның берсе дә калмаган инде. Дистә еллардан соң, 1994 елда, авылда мәчет ачыла.

– Бу урында райпо конторасы булган, – дип дәвам итте сүзен Илнур хәзрәт. – Туксанынчы елларда бина бушап кала, һәм аннан картлар йорты ясарга уйлыйлар. Шулвакыт авылның бер төркем карты авыл җирлегенә килеп: «Бинаны мәчет итеп үзгәртик», – диләр. Авыл җирлеге башлыгы аларга шарт куя: имза җыегыз, әгәр халык риза булса, мәчет итәрбез. Әлбәттә, бу изге ниятне барысы да хуплый. Менә шулай итеп Күзкәйдә янә иман йорты пәйда була.

Тыштан караганда, Күзкәй мәчете тыйнак кына, ә эчтән бик нурлы, хәтта купшы дияр идем. Узган ел мәчеткә зур гына янкорма өстәп салганнар. Шунда ай дәвамында ифтар, Коръән ашлары уздырганнар. Ә бүген ул мәдрәсә бүлмәсен хәтерләтә, такта, заманча парталар тезелеп киткән.

– Янкорманы авылдашлар көче белән төзедек, – диде Илнур хәзрәт. – Нигезне бер-ике көн казырбыз дигән идем, көндезге унга эшне бетердек тә, бик күп кеше килгән иде. Бинаның үзен дә шулай тиз эшләдек. Авылда берничә егет бар, алар бик булыша. Тәрәзә кую, җылылык кертү, идән җәю кебек эшләрне фәкать иганәчеләр күтәрде.

Илнур Фәрхетдинов – Күзкәй авылы егете. Казан дәүләт авыл хуҗалыгы университетын тәмамлагач, Чаллыда «КАМАЗ» заводында эшли. Аннары үз эшен башлый – мунча мичләре сату белән шөгыльләнә. Намазга исә университетның соңгы курсында баса.

Шуннан бирле ислам кануннарын үтәп, Аллаһ кушканча яши.

– Олы кызым беренче сыйныфка барганда, Күзкәйгә күченеп кайттык, – диде Илнур хәзрәт. – Туган нигездә яңа йорт салып чыктык. Җәмәгатем Гөлнара белән өч бала үстерәбез. Авылда безнең кебек яшь гаиләләр бар әле. Күбесе шәһәрдә эшли. Безнең менә кибетебез бар, гаиләне алып барырга җитә.

«ТИРӘ-ЯКТАН ЙӨРЕП ДӘВАЛАНДЫЛАР»

Күзкәйдә 1921 елгы ачлыкка кадәр өч меңгә якын кеше яшәгән. XIX гасыр уртасында авыл волость үзәге булып торган. Күзкәйгә караган авыллар егерме икегә җиткән. Совет хакимияте елларында, төгәлрәге 1929 елда, авылда «Яңа тормыш» колхозы оешкан. Ике елдан соң аның исеме «Ярыш»ка әйләнгән. Шул чордан авылның яңа тормышы башланган: балалар бакчасыннан башлап хастаханәгә кадәр салынган. Күзкәй хастаханәсенең даны еракларга таралган була: күрше районнардан да биредә килеп дәваланганнар. 2001 елда хастаханә өчен яңа бина төзелә. Аның ишекләре бүген дә ачык. Дөрес, хәзер ул көндезге бүлек буларак кына эшли.

– Унбер авылга хезмәт күрсәтәбез, – диде биредә 1986 елдан бирле эшләүче шәфкать туташы Флера Габдрахманова. – Каравылчыны да кертеп, барлыгы ун кеше хезмәт куя. Мин физиотерапия бүлмәсе шәфкать туташы. Хәтерлим, эшли башлаганда хастаханәнең бинасы агачтан иде. Бер ягында аның амбулатория, бер ягында стационар иде. Яңа бина утыз җиде урынлы итеп эшләнде. Елына 500–600 кеше дәваланган чаклар булды.

– Ә хәзер? – дим.

– Хәзер алай түгел инде. Дөрес, көздән язга кадәр кеше күп була, нигездә, өлкәннәр. Үзебезнең лаборатория бар, анализларны шунда тапшыралар. Атна саен Чаллыдан табиблар килә, алар биргән күрсәтмә буенча без уколын кадыйбыз, башкасын эшлибез. Физиотерапиягә мәктәп балалары да килә, әле генә бер үсмер малай чыгып китте.

Башка шәфкать туташлары белән дә таныштык: барысы да тәҗрибәле. Эш урыннары якты, матур, шулай да алар хастаханәнең элеккеге чакларын сагынып искә алды:

– Әле менә теш табибы килергә тиеш, бераз вакыт булмый торды, – дип елмайды ак халатлы гүзәл ханымнар. – Яшьләрнең авылга бик кайтасылары килми, ә без хастаханәдә күбрәк белгечләр булуын телибез. Кеше күп булгач, эшләргә күңелле.

...Йөри торгач, һава температурасы утыз бер градуска төште. Әле авылда күрәсе кешеләр, социаль учреждениеләр тагын бар иде. Күзкәй авыл җирлеге башлыгы Эдуард Гәрәев машинасын сүндереп тә тормыйча: «Карап кына чыгыгыз», – дип, авыл буенча йөртеп чыкты. Шулай, күрсәтәсе урыннар булганда, кунаклар алдында да рәхәт бит. Күзкәйлеләр өчен сөенеп кайттык. Зәмһәрир суык та, озын юл да кәефне кырмады, чөнки авыл кешеләре белән аралашканнан соң туган рәхәт халәт юл буена җитте.

7 Күзкәй хастаханәсендә бүген ун кеше эшли.

8 – Унбер авылга хезмәт күрсәтәбез, – диде биредә 1986 елдан бирле эшләүче шәфкать туташы Флера Габдрахманова.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Безнең авылда дүрт зират бар. Аның берсе бик борынгы, Болгар чорына караган булырга тиеш. 1960 нчы елларда авылга археологлар килеп эшләгән. Аерым табылдыкларга таянып, VII–VIII гасырларда ук монда кешеләр яшәгән булырга мөмкин, дигәннәр. Тарихтан беләбез: XIII гасырның беренче яртысында дәһшәтле монгол яулары Бөек Болгар дәүләтен җиңелүгә дучар итә. Аның Идел буендагы халкы Чулман, Нократ, Ык, Агыйдел елгалары буйлап күчеп утыра. Менә безнең дә борынгы бабаларыбыз шулар арасында булган, дигән фараз бар.

Авылның атамасына килгәндә, бер риваять бар: янәсе, урман кискәндә, берәүнең күзенә ботак эләккән. Шуннан ул: «Ай, күзкәем, күзкәем», – дип кычкырган. Галимнәр исә аны Күзкәй дигән кеше исеменә бәйли. Авылга нигез салучы кеше хөрмәтенә шундый исем бирелгән булырга тиеш.

Рифкать Сәгыйдуллин, авыл тарихы белән кызыксынучы.

афиша

БАЛАЧАККА КИРЕ КАЙТУ? БУЛМАС ДИМӘ! (0+)

Аккургаштан ясалган солдат, йомшак аю баласы яки керфекләрен гел ачып-йомып тора торган курчак... Әлеге бәхетле балачагыбыз персонажларын хәтерлисезме? Кайсыбыз бу самими дөньяга бер мизгелгә генә булса да кайтырга хыялланмаган? Казанда ачылган күргәзмә шундый могҗиза эшләргә сәләтле кебек тоела. Экспозициядә – XIX гасыр ахыры – XX гасыр уртасындагы борынгы курчаклар һәм уенчыклар, алар Россия империясендә, Германиядә, Франциядә, АКШта, ГДРда һәм СССРда ясалган. Карнавал костюмнарындагы курчаклар, фарфордан «кесә» курчаклары һәм чүпрәк курчаклар... Программаның үзенчәлеге – атказанган совет курчаклары һәм полиэтилен, целлулоид, мамык, тукыма һәм хәтта агач-пычкы чүбе массасыннан ясалган уенчыклар. Ә бәхетле балачак кайту тәэсирләрәк булсын өчен, монда 1960–1970 нче елларны хәтерләткән балалар бүлмәсе дә ясалган.

Көн саен 10:00 дән 18:00 сәгатькә кадәр (җомга – 11:00-20:00 сәг.), дүшәмбе – ял көне
«Эрмитаж-Казан» үзәге, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

«КЫШКЫ ТЫЛСЫМ» ЧАГЫ ҖИТТЕ... (6+)

Бүгенге балалар бик кызыксынучан, аларны гадәти Яңа ел бәйрәме белән шаккатырып булмый. Күңелсез диячәкләр. Ә менә маҗаралы да, тылсымлы да квест – монысы бөтенләй башка! «Шәрык клубы» командасы һәм Камал театры артистлары балалар өчен театрлаштырылган Яңа ел квесты әзерләде.

Монда кызыклы яңа ел биремнәре, уеннар көтә. Һәр биремдә кечкенә катнашучылар үзләренең фантазия, логика һәм иҗади осталыкларын раслый алачак. Барлык биремнәр дә үтәлгәч, балалар, Кыш бабай белән очрашып, үз сәләтләрен күрсәтәчәк.

23-30 декабрь, 3–7 гыйнвар
«Шәрык клубы», Казан, Татарстан ур., 8

КАЗАН БАСМАСЫ ХОЗУРЫНДА (16+)

Казан – беренче басма Коръән дөнья күргән шәһәр. Ул «Казан басмасы» дип телгә кереп калган. Алга таба шәһәребездә мөселманнарның изге китабы гасырлар дәвамында меңләгән тираж белән бастырылып килгән. Казан басмасы киләчәктә изге китапны нәшер итүдә үрнәк булып торган.

Ислам мәдәнияте музеенда оештырылган күргәзмәдә КФУ Фәнни китапханәсе коллекциясеннән уникаль экспонатлар тәкъдим ителә. Алар арасында 1803 елгы беренче басма Коръән, XVIII гасырда кулланылган Коръәннең татарча кульязмалары, Шиһаб Мәрҗани, Риза Фәхретдин, Муса Бигиев кебек татар дин әһелләренең Коръәнне тикшерүгә караган кульязма хезмәтләре һәм китаплары бар. Күргәзмәгә килүчеләр Татарстанда иң зур Коръән коллекцияләренең берсенә ия булган «Казан Кремле» музей-тыюлыгы фондларында сакланган сирәк басмаларны да күрә ала. Экспозициядә совет Россиясендә басылып чыккан һәм Япониядә (1934) һәм Финляндиядә (1969) татар эмигрантлары тарафыннан нәшер ителгән Коръәннәр дә тәкъдим ителә.

2024 елның 29 февраленә кадәр көн саен 9:00-19:30 сәг., дүшәмбе – ял көне
Ислам мәдәнияте музее, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

Фотолар: Ислам мәдәнияте музее, tinchurinteatr.ru, tatar-inform.ru, russdramteatr.ru, kazan-kremlin.ru, karievteatr.ru, tatfil.ru сайтыннан



«ТЫЛСЫМЛЫ АРЕНА»ДА НИЛӘР БАР? (12+)

Көннәрнең берендә талантлы цирк җанварлары тормышында зур үзгәреш була. Аларны кара кайгыга салырлык көтелмәгән бер вакыйга килеп чыга... Театр репертуарына кертелгән, ачык төсләргә һәм бихисап фокусларга бай булган әлеге әкият, нигездә, дуслык, хыял һәм яхшылык кебек төшенчәләр хакында сөйли. Балалар гына түгел, олылар өчен дә бер үк дәрәҗәдә күңелле булачак бу әкият каһарманнары барысы да мавыктыргыч һәм ягымлы. Алар җырлыйлар да, бииләр дә, көлдерәләр дә!

23, 24 декабрь, 12:30 сәг.
26, 27, 28 декабрь, 13:00 сәг.
2 гыйнвар, 12:00 сәг.
Кәрим Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Казан, Горький ур., 13

АТА ТОРГАН БҮЛӘКЛӘР (16+)

Совет лидеры Леонид Брежневка Финляндия Президенты Урхо Кекконен бүләк иткән ау мылтыгын күрергә телисезме? Ә безнең генераль секретарьга Монголия халык-революцион партиясенең Генераль секретаре Юмҗагин Цеденбал бүләк иткән мылтыкны? Яки Куба Республикасы оборона министры Рауль Кастроның СССР маршалы Родион Малиновскийга бүләк иткән пистолет-пулеметын? Әлеге һәм башка уникаль экспонатларны Казанда РФ Кораллы көчләре Үзәк музее фондларыннан «Күренекле Россия һәм совет хәрби эшлеклеләренең бүләк кораллары» күргәзмәсендә күрергә була. Биредә шулай ук илебезнең күренекле хәрби җитәкчеләренең исемле пистолетлары, мылтыклары, салкын кораллары, шулай ук аларның шәхси әйберләре тәкъдим ителгән.

Көн саен 10:00 дән 18:00 сәгатькә кадәр (җомга – 11:00 – 20:00 сәг.)
Дүшәмбе – ял көне
Туп ишегалды музее, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

КҮҢЕЛЛӘРНЕ ҖИЛКЕНДЕРЕП... (6+)

Яңа ел килә... Ул шәһәр, авыл урамнарына якты утлар булып үтеп керә, кар бөртекләренә әверелеп җемелди, күңелләрне җилкендерә... Эстрадабыз йолдызлары да яңа елның беренче көннәрендә үк үзләренең иң шәп җырларын халыкка бүләк итә. Вил Усманов, Резидә Шәрәфиева, Алсу Әбелханова, Сөмбел Билалова, Рәсим Низамов, Алмас Хөсәенов, Гөлүс Хәбибрахманов, «Болгар кызлары» триосы, Айгөл Хәернасова, Булат Закиров, Салават Шәфыйков сезне Татар дәүләт филармониясе оештырган «Бәйрәм концерты» дип аталган тамашада көтеп кала.

2024 елның 2 гыйнвары, 18:30 сәг.
Г. Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе
Казан, Павлюхин ур., 73

«МАТУРЛЫК»НЫ КҮРМИ КАЛМАГЫЗ! (12+)

Туган туфрак... Барысы да шунда башлана һәм шунда тәмамлана. Ә менә кем булуыңны, кайдан икәнеңне онытту өчен күпме вакыт һәм ара ераклыгы кирәк? Балалар авыру әниләрен үлеп барган авылдан зур шәһәргә алып килә. Бар да дөрес шикелле: монда аны карыйлар, тәрбиялиләр, дәвалыйлар. Әмма берәүнең дә җан авазын тыңларга, васыятенә колак салырга вакыты юк. Бу васыять алар өчен – буш сүз генә. Балалар нигезне саклаудан баш тарта, ләкин оныклар өчен әбинең сүзләре, тәҗрибәсе үз нигезен белер, таныр өчен – соңгы мөмкинлек.

Мәрхүм булганчы Акъәбинең соңгы гозере бар. Ул гозерне үтәргә кем дә булса табылырмы? Оныклар – кечкенә нәселнең һәм зур халыкның якты киләчәге, алар дөрес адым ясый алырлармы?.. Һәм әбиләреннән бөркелгән Матурлыкны сакларга көчләре җитәрме?..

15, 16 декабрь, 18:30 сәг.
Кариев исем. Казан яшь тамашачы театры, Казан, Петербург ур., 55 Б

ай кәефе: тантаналы

ТЕАТРГА БҮЛӘК

Узып баручы ел республика өчен күркәм вакыйгаларга бай булды. Күптән түгел генә Буада яңартылган театр бинасын ачу шундыйлардан берсе. Яңа бина театр коллективы өчен зур бүләк булды.

Ремонт эшләре «Мәдәният» илкүләм проекты кысаларында алып барылды. Шунысын да әйтергә кирәк: соңгы елларда республикабызда инде дүртенче театр бинасы ачылды. Моңа кадәр Яр Чаллы шәһәрендә – ике, Түбән Камада бер театр бинасы яңартылды. Буа дәүләт драма театрының яңартылган бинасын ачу тантанасында ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов, ТР мәдәният министры Ирада Әюпова һәм башка мәртәбәле кунаклар катнашты.

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, эшләрнең сыйфатлы башкарылуын ассызыклап, катнашучыларга зур рәхмәтен җиткерде.

«Буада искиткеч коллектив, бик көчле җитәкче. Бу театр гына түгел, бәлки мәдәни үзәк тә. Ул Буа халкына гына түгел, күрше районнарга да хезмәт итә алачак», – диде ул.

Яңартылган бинада профессиональ артистлар һәм музыкаль коллективларның чыгышлары һәм репетицияләре өчен бөтен шартлар тудырылган. Гомуми мәйданы да 4 мең кв. метрга кадәр арткан, ә тамашачылар залы 400дән артык кешене сыйдара ала.

Тантана Буа дәүләт драма театры артистларының чыгышлары, кунакларның котлаулары белән үрелеп барды.

Нурислам Исмәгыйлев фотолары

Бәйрәмнәр котлы булсын!
Яңа елны каршы алганда “Татарстан” журналына да язылырга онытмагыз!
«Татарстан» журналы, 2000 ел.
Реклама 16+